Гөлфия Гайнуллина

# XX ГАСЫРНЫҢ 60–70 нче ЕЛЛАРЫНДА ТАТАР АВТОБИОГРАФИК ПРОЗАСЫ ҮСЕШЕ

Казан – 2012

Фәнни мөхәррир
*Филол.фән.докт., проф. Т.Н.Галиуллин*

Гайнуллина Г.Р. XX гасырның 60-70 нче елларында татар автобиографик прозасы үсеше. – Казан: Ихлас, 2012. – 107 б.

Китап – татар мемуаристикасын системалы өйрәнү юлында беренче омтылыш. Хезмәттә татар автобиографик прозасы үсешенең тарихын билгеләү, теоретик һәм тарихи–әдәби концепциясен булдыру, XX гасыр дәвамында аның үзгәрешен күзәтү, 60–70 нче елларда үсеш үзенчәлекләрен өйрәнү, жанрның матур әдәбияттагы урынын күрсәтүче төп критерийларын билгеләү күздә тотыла. Анализлана торган төп әдәби материал булып XX гасырның 60–70 нче елларында иҗат ителгән, үз укучысын тапкан, вакыт сынавын узган автобиографик әсәрләр, аерым алганда, Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек”, И.Газинең “Малайлыкта кунакта”, Ф.Хөснинең “Минем тәрәзәләрем”, Р.Төхфәтуллинның “Җиләкле аланнар”, чагыштыру өчен Ә.Еникинең “Соңгы китап”, С.Батталның “Баштан үткәннәр” дип аталган истәлек характерындагы әсәрләре алынды. Моннан тыш, Ш.Маннурның “Агымсуларга карап”, М.Әмирнең “Без бәләкәй чакларда”, “Үсә төшкәч”, “Казан” әсәрләренә тукталып үтелде.

**Эчтәлек**

Кереш сүз 4

Татар әдәбиятында автобиографик жанрның тууы, беренче тәҗрибәләр 8

XX гасырның 60–70 нче еллар татар прозасында автобиографик жанр үсеше 34

Татар автобиографик повестенең жанр үзенчәлекләре 70

# Кереш сүз

Мемуар һәм автобиографик жанрлар дөнья әдәбиятының җитди бер тармагын тәшкил итәләр. Биредә, сурәтләү объекты буларак, аерым шәхеснең кабатланмас кызыклы язмышы алына, аңа бәйле рәвештә чор вакыйгалары тасвирлана, фактик материал укучы хөкеменә сәнгатьчә югары дәрәҗәдә җиткерелә. Мемуар һәм автобиографик жанрларның кыйммәте, әһәмияте шул сыйфатлар белән билгеләнә.

Татар әдәбиятында автобиографик жанрга XX гасыр башында нигез салына, чор дәвамында ул җитди үсеш баскычлары үтә һәм гасыр ахырына тулысынча калыплана.

Гыйльми хезмәттә автобиографик жанр үсешенең тарихын билгеләү, теоретик һәм тарихи–әдәби концепциясен булдыру, XX гасыр дәвамында аның үзгәрешен күзәтү, 60–70 нче елларда үсеш үзенчәлекләрен өйрәнү, жанрның матур әдәбияттагы урынын күрсәтүче төп критерийларын билгеләү күздә тотыла. Максатка ирешү автобиографик әсәрнең әдәби һәм документаль хасиятен ачыклау, төп жанрлык билгеләренә күзәтү ясау, аның күп гасырлык татар әдәбияты тарихында тоткан урынын өйрәнү аша алып барыла.

Тәкъдим ителә торган тема соңгы елларда һәм язучылар, һәм әдәбият галимнәре даирәсендә зур кызыксыну уятты, китап сөюче зәвыклы укучы игътибарын җәлеп итте. Бу күренеш жанрның язучы һәм аның тормышы, ул яшәгән мохит, катлаулы һәм каршылыклы замана сулышы турында яңа мәгълүматлар алырга мөмкинлек тудыру хасияте белән аңлатыла.

Әлеге темага нисбәтән татар әдәбияты галимнәре тарафыннан тәнкыйди мәкаләләр, язмалар рәвешендә төрле фикерләр әйтелә, сүз кузгатыла. Шулай да бүгенге көндә автобиографик жанрны фәнни югарылыкта эшкәртүне, аңа системалы анализны күздә тоткан аерым хезмәт юк.

Татар әдәбиятында исә 30 нчы еллардан 60 нчы елларга кадәрге мемуаристика беркадәр икенче планда кала. Бу иҗтимагый–сәяси вакыйгалар белән бәйле иде.

Үткән гасырның 60–70 нче еллар тәнкыйтендә документаль прозаны тәфсилләп күзәтүгә омтылыш бу чорда тарихи-шәхси башлангычка игътибар үсү, халык һәм әдәбият узган юлны яңача бәяләргә тырышу белән аңлатыла. Чорның кырыс хакыйкатен эзләү барышында язучылар хыял белән тулыландырылган, баетылган шәхси биографияләренә мөрәҗәгать итәләр. Бу әсәрләр сугыштан соңгы прозаның мөһим

казанышына әверелә, шул сәбәпле әдәбият галимнәренең аерым игътибарын үзенә тарта.

Аурупа һәм рус әдәбиятлары мемуар һәм автобиографик жанрны фәнни юнәлештә өйрәнүгә күптәннән зур игътибар бирә, бу темага кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре эшләнә, монографияләр языла. Җөмләдән, Л.Я.Гинзбургның "Былое и думы" Герцена" исемле хезмәте мемуар әдәбиятның төп үзенчәлекләрен барлау юнәлешендә олы фундаменталь хезмәтләрдән санала. Кыскасы, жанрның үсеше галимнәр тарафыннан даими күзәтелеп барыла[1].

Фәнни хезмәттә анализлана торган төп әдәби материал булып XX гасырның 60–70 нче елларында иҗат ителгән, үз укучысын тапкан, вакыт сынавын узган автобиографик әсәрләр, аерым алганда, Г.Бәшировның "Туган ягым – яшел бишек", И.Газинең "Малайлыкта кунакта", Ф.Хөснинең "Минем тәрәзәләрем", Р.Төхфәтуллинның "Җиләкле аланнар", чагыштыру өчен Ә.Еникинең "Соңгы китап", С.Батталның "Баштан үткәннәр" дип аталган истәлек характерындагы әсәрләре алынды. Моннан тыш, Ш.Маннурның "Агымсуларга карап", М.Әмирнең "Без бәләкәй чакларда", "Үсә төшкәч", "Казан", әсәрләренә тукталып үтелде. Алда саналган авторлар – татар мемуаристикасын яңа үсеш баскычына күтәргән язучылар. Биредә, шулай ук, автобиографик әдәбиятның башында торган Г.Исхакыйның "Зиндан", Г.Тукайның "Исемдә калганнар", М.Гафуриның "Тәрҗемәи хәлем", Н.Думавиның "Тәрҗемәи хәл урынында", Г.Камалның "Минем персональный пенсионер булуымның тарихы" әсәрләре тикшерелә.

Татар автобиографик әсәре рус әдәбияты галимнәре күрсәткән классик таләпләргә җавап биргәнлектән, төп нәзари материал итеп, М.М.Бахтинның "Эстетика словесного творчества", Л.Я.Гинзбургның "О психологической прозе" хезмәтләрендә бирелгән концепцияләр алынды.

Шул рәвешле, жанр теориясен өйрәнү, татар әдәбиятында аның беренче үрнәкләрен күзәтү белән беррәттән, югарыда искә алынган берничә авторның әсәренә анализ тәкъдим ителә.

---

[1] См.: Елизаветина Г. "Былое и думы" А.И.Герцена. – М.:Худ.лит–ра, 1984; Дуров Б.Д. Мемуарный жанр в художественной прозе революционного народничества. Дисс. … канд.филол.наук. – М., 1980; Тарасова Г.В. Мемуары как литературоведческий источник. Дисс. … канд.филол.наук. – Душанбе, 1989; Кабдрахманов Б.Д. Художественная функция документальных источников в контексте мемуаров Герцена "Былое и думы". Дисс. … канд.филол.наук. – Алма–ата, 1985; Смольнякова М. О принципах классификации современной мемуарной литературы // Проблемы реализма. – Вологда. – 1979; Жиркова М.А. Исповеди в романе Ф.М.Достоевского "Братья Карамазовы". Дисс. … канд.филол.наук. – СПб., 1997; Алейникова З.Я. Жанровое своеобразие мемуаров и автобиографий 60–70 годов. Дисс. … канд.филол.наук. – М., 1981; Starobinsky J. The style of autobiography. – Zn.: Literaty style. – 1971; Pascal Roy. Die Aytobiographie Jehalt und Yestalt Stittgar – Berlin – Koln – Mainz, 1960 һ.б.

Кагыйдә буларак, һәр мемуар әсәрдә милләтнең бөек шәхесләре, чорның иҗтимагый–социаль йөзе сурәтләнә. Язучылар Г.Тукай, Һ.Такташ, Г.Ибраһимов һ.б. турындагы фикерләрен халыкның үткәне белән бәйләп тасвирлыйлар. Укучыны милләтнең йөзек кашлары белән горурланырга өндәү турындагы фикер максатчан рәвештә үткәрелә. Л.Фейербах: “Кеше табигатьтән  бары хәтере белән генә өстен”[2], – ди. Үз әсәрләрендә язучылар, буыннар турындагы хәтергә бәйле, кешенең әдәплелек дәрәҗәсе, гомум кабул ителгән әхлакый кыйммәтләр турында фикер йөртәләр.

Истәлекләр (француз теленнән мемуар (memoires) – документаль жанрның аерым бер канатын тәшкил итә. Жанр авторның үткәндә үзе катнашкан һәм кичергән вакыйгалары турында  сөйләүне күздә тота. Материалның конкрет фактларга корылуы, әдәби уйдырманың булмавы ягыннан, истәлек фәнни биографиягә, документаль–тарихи очеркка якын тора. Ике гасыр чигендә татар язучылары истәлек җанрына мөрәҗәгать итәләр. Киң катлам укучыга, соңгы елларда язылган бер төркем истәлекләр белән беррәттән, моңарчы төрле сәбәпләр аркасында бастырылмаган документаль характердагы әсәрләр дә җиткерелде. Шулардан Г.Тавлинның  “Афәт”, И.Сәлаховның “Колыма хикәяләре” аеруча игътибарга лаек. Моннан тыш, чор вакыйгаларын обьектив сурәтләүгә омтылыш ягыннан А.Гыйләҗевнең “Йәгез, бер дога”, М.Мәһдиевнең “Ачы тәҗрибә”, А.Расихның “Елларны чигерсәм” трилогиясе, Т.Галиуллинның “Замана балалары”, Т.Миңнуллинның “Утырып уйлар уйладым”, Р.Мөхәммәдиевнең “Утлы таба өстендә” әсәрләре зур кызыксыну уятты. Иң соңгы елларда Т.Галиуллинның “Гомер тәлгәшләре”, Ә.Баяновның “Минем кечкенә дөньям”, “Су өстендә пароход”, “Хыялда туган калам”, Л.Ихсанованың “Кемгә сөйлим серләремне”  автобиографик әсәрләре дөнья күрде. Язылу максатына һәм принципларына карап, истәлекләрнең җанр ягыннан төрләнүе дә күзәтелә (Ш. Галиевның “Минем беренче гомерем” роман–новелласы, М.Әхмәтҗановның “Белем баскычлары”, Р.Җәмдихановның “Сагыну”, Ф.Галиевнең “Әтнә–күңелем бишеге”, К.Латыйпның “Үр арты үр” һ.б. истәлек–хатирәләре). Мемуаристиканың эссе (М.Галиевның “Догалы еллар”, Ә.Кәримуллинның “Галим булу җиңелме”), сәяхәтнамә (юлъязмалар) (М.Юнысның “Юлда уйланулар”, М.Мәһдиевнең “Җир йөзендә алты кыйтга…” исемле китабына тупланган юлъязмалары, Т.Әйдинең “Кардәшләр кочагында”, “Йөртә безне язмышлар”,  ‘Елан угы”, “Оҗмах утравы”, “Аһ, туган кавемем газиз”, “Иблискә ришвәт”,

[2] Фейербах Л. Сочинения в 2 томах. Т. 1. – М., 1960. – С. 122.

“Заман һәм шәхесләр” һ.б.), документаль повесть (Г.Ахуновның “Тимерханның эзләнүләре”, Р.Фәизевнең “Узган гомер–янган күмер”, А.Вәлиевнең “Көйгән сакаллы мәхбүс”, “Истә, һаман да истә”, “Талантлар арасында” һ.б.). Публицистик язмаларның күпчелеге мемуаристикага тартымлыгы белән үзенчәлекле (Ә.Еникинең “Кояш баер алдыннан”).

Хезмәттә әдәби текстларга тарихи–функциональ, типологик һәм структур юнәлештә анализ бирү күздә тотыла. XX гасырның икенче яртысында жанрның үсешенә чорның социопсихологик фоны, ягъни әдәбиятта аерым шәхескә, аның тарихи аренадагы урынына игътибар артуы йогынты ясый. Алда билгеләп үтелгәнчә, чорның төп үзенчәлеге – сәясәт белән бәйле хакыйкатьне ачыктан–ачык тасвирлау мөмкинлеге булмауда. Язучыларны автобиографик жанрга мөрәҗәгать итәргә үткәнне бүгенге белән бер үремтәдә сурәтләү омтылышы этәрә. XX гасыр дәвамында үткәрелгән ил сәясәтенең шәхес психологиясенә, аның үзаңына, формалашуына тәэсирен күзәтү, шул рәвешле дөреслекне әйтүгә ирешү – өлкән әдипләрне берләштерүче уртак ният. Шушы нигездә бер–бер артлы алдынгы язучыларның автобиографик әсәрләре дөнья күрә.

Өйрәнү өчен чордаш әдипләрнең бер үк жанрдагы әсәрләре сайлап алынды, ягъни хезмәт типологик аспекттагы күзәтүләргә корылды. Биредә шулай ук татар автобиографик әсәренең структур моделен төзү күздә тотылды. Моннан тыш, әдәбият белемендә автобиографик жанрның тоткан урынын, кыйммәтен ачыклау максат итеп билгеләнде.

Югарыда күрсәтелгән методологик принциплар автобиографик жанрның үзенчәлекләрен системалы барлау, аның әдәби процесста, аерым алганда, XX гасырда үсеш–үзгәрешен күзәтү өчен кулай принциплар дип табылды.

Тәкъдим ителә торган фәнни эш – татар мемуаристикасын системалы өйрәнү юлында беренче омтылыш. XX гасыр ахырында мемуар әсәрләр күп язылды, документаль әдәбиятның моңарчы күрелмәгән үсеше күзәтелде. Әлеге эш мемуар әдәбиятның бер – автобиографик төрен тикшерүне күздә тота. Хезмәттә күрсәтелгән нәтиҗәләрне әдәбият теориясе, педагогик эшчәнлектә, аерым алганда, әдәбият фәнен, тарихын укыту өлкәсендә куллану мөмкинлеге бар дип исәплибез. Әлеге материал махсус курс укыту өчен дә нигез була ала.

Фәндә мемуар жанр теориясе бүгенге көнгәчә тиешле дәрәҗәдә эшкәртелмәгән. Аның теориясен гомумиләштереп, катгый системага салу – киләчәк эше. Әлеге хезмәт – күпмедер күләмдә шул максатка ирешү юлында бер омтылыш. Шул ук вакытта 60–70 еллар прозасын өйрәнү,

тәртипкә китерү, жанр ягыннан барлау өлкәсендә дә кайбер фикерләр әһәмияткә ия булыр дип саныйбыз.

## Татар әдәбиятында автобиографик жанрның тууы, беренче тәжрибәләр

Документаль әсәрнең нигез чыганаклары борынгы әдәбиятка барып тоташа. Рус әдәбияты галимнәре Аверинцев С.С. һәм Попова Г.А. әдәбият традицияләрен тәфсилләп өйрәнү барышында антик биографияне гипомнематик, риторик һәм әхлакый–психологик[3] дип исемләнгән өч төргә бүлеп күрсәтәләр.

Беренче төр – төп каһарманның туганнан алып үлгәнчегә кадәрге тормыш юлын төгәл итеп тасвирлау, әлеге шәхес турында тулы мәгълүмат бирү. Светонийның “Унике Цезарь тормышы” исемле биографик әсәре – бу төрнең классик мисалы. Риторик төр, тулаем алганда, биографиядән ерак тора, ул каһарманга бәя бирүне генә күздә тота. Бу очракта биографик материал бәянең нинди булуын исәпкә алып сайлана һәм автор шәхесенең гамәлләренә, тормышына хисси яссылыкта якын килә. Каһарманны идеаллаштыру, яисә киресенчә, аны шәхес буларак түбәнсетү бу төр биографиядә еш күзәтелә. Исократның “Эвагор” һәм Ксенофонтның “Агесилай” әсәрләре – риторик төрнең классик мисаллары. Әхлакый–психологик дип исемләнгән өченче төр шәхеснең теге яки бу уңай якларын, өстенлекләрен бөек кешеләр үрнәгендә күрсәтүне максат итеп куя. Бу төрнең беренче мисалы булып Плутархның “Параллель биографияләр” әсәре тора[4].

Биография каһарманнары итеп, нигездә, бөек кешеләр сайлана. Мондый атаклы шәхесләр рәтенә фәйләсүф, шагыйрь, музыкантлар керә. Шул ук вакытта биография авторы үзе, гаиләсе, үзенең эшчәнлеге турында иркен сөйли, хәтта урыны–урыны белән мактанып та ала.

Шунысы мөһим: антик биография һәм автобиография әдәби әсәр булудан бигрәк, реаль кешеләрне ачыктан–ачык данлау рухындагы сәяси гражданлык акты, яисә кешенең шәхси хисабы төсен ала[5].

---

[3] Аверинцев С. Плутарх и античная биография: К вопросу о месте классика жанра в истории жанра.–М., 1973. – С.119–125; Попова Г. Античная биография и византийская агиография / Античность и Византия. – М., 1975. – С. 222–223.

[4] Аверинцев С.С. Указ.соч.– С.47; Грабарь—Пассек М.Е. Дион Хрисостон // История греческой литературы. Т. 3. – М., 1960. – С. 214., Козаржевский А.Ч. Античное ораторское искусство. – М.,1980. – С.33–44.

[5] Бахтин М.М. Формы времени и хронотопа в романе/ Литературно—критические статьи.–М.– Худ.лит–ра.– С.168.

Автобиографиянең барлыкка килүе шәхеснең үз эшчәнлеген, күп очракта сәяси хезмәтчәнлеген акларга омтылуы белән бәйле.[6] Биографик жанр белән ораторлык сәнгатенең үзара якынаюы, хәтта берләшүе шуңа нигезләнә. Мисалга, Энкомий – монарх–полководец һәм сәяси эшлекленең идеаль образы. Энкомийда образны идеалга якынайткан бөтен уңай сыйфатлар гәүдәләнеш таба, тискәре сыйфатлар максатка яраклы рәвештә төшерелеп калдырыла[7].

Беренче антик автобиографияләр суд чыгышларында гәүдәләнеш ала. Борынгы грек ораторлары Исократ, Демосфенның аклану характерындагы чыгышларын моңа мисал итеп китерергә мөмкин.

Бүгенге автобиографиягә охшаш беренче әсәр буларак, Либанийның “Тормыш, яки Үз язмышым хакында” дип исемләнгән әсәре билгеләнә. Биредә атаклы оратор үз шәхесен аклау белән беррәттән, аның эшчәнлеген инкарь итәргә омтылучыларга протест белдерә. Либаний үзе турында, һичшиксез, югары фикердә: ул ачыктан–ачык үзенең казанышлары белән мактана. Шул ук вакытта бу автобиография бала һәм үсмер психологиясен сәнгатьле тасвирлавы белән үзенчәлекле һәм хәтта “кешенең тулы портретын бирүдә беренче омтылыш” [8] булып тора.

Шулай итеп, антик мәдәният шәхескә үз–үзен яклау мөмкинлеген бирә, хәтта еш кына прообраздан ерак торган идеалны сурәтләүне күздә тота. Антик әдәбият шәхесне үсеш–үзгәрештә күрсәтүне максат итеп куймый, киресенчә, әсәрнең төп каһарманы һәр очракта формалашкан шәхес, тулы характер буларак гәүдәләнә. Әсәрдә үткәрелгән идеянең ышандыру көчен арттыру өчен әлеге алым һичшиксез уңайлы. Антик мәдәниятнең соңгырак чорында шәхесне үсеш–үзгәрештә тасвирлау тенденциясе күзәтелә (Мисалга, Марк Аврелийның “Үз–үзем белән” исемле уйланулары).

Татар әдәбиятының күп гасырларга сузылган үсеш юлында автобиографик әсәр элементлары борынгы төрки язмачылыкка барып тоташа. Автобиографик әсәрнең нигезе булып торган чыганакларны хронологик тәртиптә өйрәнү максатка ярашлы булыр:

- борынгы төрки язмаларда документаль фактның урыны һәм әһәмияте;
- ислам дине кабул ителгәннән соңгы урта гасыр әдәбиятында биографик һәм автобиографик жанр элементгары;

---

[6] Соболевскиий С.И. Ранняя латинская проза / История римской литературы – Т. 1. – М., 1959. – С.129.

[3] Миллер Г.А. От поэзии к прозе. Риторическая проза. Горгия и Исократа / Античная поэтика. Риторическая теория и практика. – М., 1991. – С.97.

[8] Грабарь–Пассек М.Е. Либаний / История греческой литературы. – Т. 3. – М., 1960. – С. 283–293.

- XIX гасырга документаль характердагы әдәбиятның киң колач җәю, биобиблиографик жанр туу чоры;

- автобиографиянең аерым жанр буларак формалашу давере.

Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән борынгы төрки язмалар шартлы рәвештә икегә бүленә: руник язулы тарихи–этник һәм уйгыр язуындагы этник дидактик ядкярьләр[9].

Автобиографик әсәргә конкрет тарихи фактик материал кертелү үзлеге хас. Ул һәрвакыт билгеле документка нигезләнә һәм шуны әдәби әсәр кысаларында сәнгатьчә эшкәртүне күздә тота. Руник язма истәлекләреннән Кече язма Күлтәгин истәлегенә куела һәм каһарманның үзе турындагы сүзе белән башлана. Үз–үзеңне мактауның шул чорда яшәп килгән сөйләм традицияләренә (бәлкем, язма традицияләренә) таянып булса кирәк, Күлтәгин үзен күккә охшаш һәм күктә яратылып патшалыкка утырган зирәк төрки каган дип бәяли[10]. Үзе яулап алган илләрне һәм үз хөкеменә буйсындырылган халыкларны, А.Н.Бернштам фикеренчә, беркадәр арттырып сурәтли[11].

Күренгәнчә, арттыру алымы антик әдәбиятта да, борынгы руник язмачылыкта да урын ала. Кабатлап үтик, мондый күренеш сурәтләнгән вакыйгаларның, үткәрелгән идеянең эчтәлеген баета, ышандыру көчен арттыра. “Ташъязмалар халыкка кат–кат мөрәҗәгать итеп: “Ишетегез, без әйткәннәрне колагыгызга киртләп куегыз, без сөйләгәннәрне ахырына кадәр тыңлап бетерегез!” – дип ялваралар... Ә ышандыру көчен тагын да арттыру өчен, үзләрен зирәк һәм гадел хөкемдар, Тәңренең туганы ук булмаса да, һәрхәлдә, якын дусты итеп күрсәтәләр,” – дип нигезли А.Г.Яхин борынгы төрки язма истәлекләр авторларының халыкка нәсыйхәтләрен[12].

Шул ук ядкярдә конкрет географик мәгълүматлар, төрки каганатларның чикләре турында тарихи фактлар күзәтергә мөмкин. Бу да язманың документаль хасиятенә басым ясый, аның нигезендә төгәл фактларның булуы әсәрнең ышандыру көчен арттыра. Зур язма исә Кече язмадан “тасвирлау тәэсирлерәк, сәнгатьчә тәэсирлерәк һәм эпоска тартымрак”[13] булуы белән аерылып тора. Биредә шулай ук җитәкче урыннарны биләүче Бумын каган һәм Истәми каган, ягъни авторның ата–бабалары атап кителә. Автор зур горурлык хисе белән аларның һәр

[9]Күроглы Х.Г.Борынгы төрки язмачылык / Татар әдәбияты тарихы. Алты томда.Т.I. – Казан:Тат.кит.нәшр., 1981.–35 б.

[10] Күроглы Х.Г. Борынгы төрки язмачылык . – 37 б.

[11] Бернштам А.Н. Социально–экономический строй орхоно–енисейских тюрок. У1–УП вв. – С. 36.

[12] Яхин А.Г. Осталык, батырлык, акыл / Ул дәрья да бу дәрья: Борынгы әдәбият. – Казан: Мәгариф, 1999. – 7 б.

[13] Күроглы Х.Г. Борынгы төрки язмачылык. – 40 б.

фәрманының төпле булуын, берсүзсез үтәлүен билгеләп китә. Алардан соңгы каганнарның “белексез” (“билгисиз каган”) һәм юньсез (“әринч”) булулары аркасында илнең җимерелүен күрсәтә.

Күлтәгин биографиясе җиде яшь тулганда этисенең үлемен сурәтләүдән башланып китә. Уналты яшендә агасының дәүләтен киңәйтеп, дошманны җиңүе, егерме бер яшьтә Чага сәңүнгә каршы көрәше, егерме алты яшендә кыргызларга каршы яу чабуы тасвирлана.

Тоньюкук хөрмәтенә язылган ядкяр “Билгә Тоньюкук бән өзүм” дигән сүзләр белән башлана (тәрҗемәдә: Мин үзем зирәк Тоньюкук). Кагыйдә буларак, автобиографик әсәрнең герое – аның авторы – шулай ук сүзне үзе белән таныштырудан башлап җибәрә. Соңга таба герой үзенең табгачлар илендә тәрбияләнүе турында хәбәр итә.

Тоньюкук – Орхон ядкярендә безнең көннәргәчә сакланып калган иң беренче төрки акыл иясе һәм сугыш остасы. Бу хакта Фирдәүси үзенең атаклы “Шаһнамә”сендә дә әйтеп үтә. Әлеге ядкярдә Тоньюкук сирәк очрый торган яу башлыгы итеп күрсәтелә, мактау ала. Тоньюкук үз хезмәтен югары бәяли, бу хакта аерым басым ясап: Түн удыматы,

Күндүз олурматы.
Кызыл каным төкти
Кара тәрим йүкүрти.
Исит Кучнг бәртим өк
бән өзүм узун йәлмәг йәмә ыт (т)ым ок (93).

(Төн йокламадым,
Көндез утырмадым.
Кара тиремне агызып,
Үзем үк хезмәтемне һәм көчемне бирдем,
Үзем үк һөҗүмнәрне еракларга юнәлттем.)[14], – ди.

Енисей буенда (Бегре, Алтын күл, Элегеш һ.б. урыннарда) табылган руник язмаларда сүз мәрхүмнең үз исеменнән алып барыла. Бу очракта биографик детальләр башка герой сөйләме аша бәян ителә, шул сәбәпле, әсәрнең лирик–эмоциональ эчтәлеге байый, уйдырмага һәм һәр төрле сәнгатьчә бизәкләргә зур урын бирелә.

Әлеге ядкярләрнең нигез материаллары бик тә конкрет, сүз билгеле тарихи шартлардагы конкрет шәхес турында барган[15]. Автобиографик әсәрдә тарихи шәхес ролен автор үзе башкара, һәр вакыйга аның шәхес

[14] Күроглы Х.Г.Борынгы төрки язмачылык . – 45 б.
[15] Күроглы Х.Г.Борынгы төрки язмачылык . – 60 б.

буларак формалашуын, күңел дөньясын, эчке кичерешләрен үсеш–үзгәрештә күрсәтү өчен хезмәт итә.

Шул рәвешле, борынгы төрки язмаларда ук автобиографик элементлар шактый чагылыш таба. Аерым алганда, әсәр башында авторның үзе белән таныштыруы, сөйләнәчәк вакыйгаларның тарихи җирлеген билгеләп үтүе, географик мәгълүматлар булуы, теге яисә бу вакыйгага мөнәсәбәттә авторның хисләре сурәтләнүе, ягъни лирик башлангычның өстенлек алуы – моңа дәлил. Шулай ук, шәхеснең үз–үзен югары бәяләү, үз хезмәтен күтәреп, бу хакта әсәрдә как–кат искәртү, өлешчә мактану рухы – һәм антик әдәбият, һәм борынгы төрки язмачылык өчен уртак сыйфат. Шәхеснең тормыш юлын сурәтләүдә идеаль образ тудыру өчен кулай яклар күпертелеп тасвирлана, ә тискәре күренешләр автор игътибарыннан читтә кала. Бу әсәрнең дидактик характерын билгели, аның тәрбияви әһәмиятен арттыра. Автобиографик әсәр автор шәхесенә яңа күзлектән бәя бирергә ярдәм итә. Язма истәлекләрдә тасвирланган шәхесләр турында күп очракта шул әсәргә таянып кына фикер йөртеп була, чөнки аларга кагылышлы башка мәгълүматлар сакланмаган диярлек.

ХШ йөздә гарәп–мөселман илләрендә Мөхәммәд пәйгамбәр с.г.в.нең тормыш юлын сурәтләүгә багышланган мәүлидләр язу киң тарала. Мәүлид (гарәп теленнән туган мәгънәсендә) – пәйгамбәрләр тормышын яктыртуны күздә тоткан әдәби жанр. ХШ йөздә яшәп иҗат иткән Сөләйман Чәләбинең мәүлиде аеруча яратып укыла, төрек, татар, грек, көрд һ.б. халыклар өчен 1200 тапкыр күчерелә[16]. Шулай ук Мөхәммәд Чәләбинең "Мөхәммәдия" исемле мәүлиде билгеле. Димәк, ХШ гасырда ук гарәп илләрендә автобиографик әсәргә якын торган язмалар иҗат итү гадәти хәл була. Бу факт безгә жанрның нигезләрен мөселман халыкларының әдәбиятыннан эзләргә мөмкинлек бирә.

Автобиографик жанрның кайбер хасиятләре Урта гасыр әдәбиятында тагын да киңрәк гәүдәләнеш таба. Бу чорда иҗат ителгән әсәрләрнең күпчелеге Коръән нигезенә корылган. 922 елда ислам дине рәсми рәвештә кабул ителү вакыйгасы татар әдәбиятына бик зур йогынты ясый. Күп идеаллар үзгәрә, аларны укучыга ирештерү чаралары, яңарак һәм үтемлерәк формалар булуы таләп ителә. А.Г.Яхин бу күренешне түбәндәгечә нигезли: "Ташъязмалар, каһанга ышаныгыз, ул ни әйтсә, шуны үтәгез дип, халыкка мөрәҗәгать итсәләр, бу чор әдипләре кешеләргә мөрәҗәгать итәләр: "Аллага ышаныгыз, аның сүзләрен, үз сүзләрегез итеп, күңелләрегезгә урнаштырыгыз", – диләр. "Алар бөтен

[16] Mevlid – Dog. Pr.Necla Pekol cay. Ankara, 1993.

эш–гамәлләрегезгә бәя биреп торучы әхлак кагыйдәләренә әйләнсеннәр”, – дип үгетлиләр”[17]. Борынгы әдәбиятның Коръән белән турыдан–туры бәйләнеше кешеләргә җәмгыятьтәге урыннарын билгеләү мөмкинлеге тудырды. Бу чор әдәбиятында автобиографик жанрның хасиятен билгеләүче элементларның артуы һәм әдәбиятның юнәлеше үзгәрүе аны аерым этап итеп күрсәтергә нигез бирә.

Урта гасыр авторлары турында белешмәләр сакланмаган, булганнары исә күпмедер күләмдә әдәби әсәрләрнең эчтәлегендә урын ала. Бу чор әдәбиятының йөзен билгеләүче, аның рухи куәтен күрсәтүче Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәрендә дә автобиографик детальләр чагылыш таба. Мисалга, әсәр ахырындагы юллар авторның үзе белән танышырга мөмкинлек бирә:

Буни дүзән зәгыйфь бәндә ады Гали,
Йегерми дүрт рәкъм эчрә салды йули...[18]

һәм:

Рәхмәт кыйлгыл, рәхим кыйл, Кол Галийә,
Кайгулу нәфсем мөфәррик кыйлгыл имди[19], – диелә.

Шул рәвешле, әсәргә автор образы килеп керә. Язучы үзенең теләк–ниятләрен, укучыга әйтер сүзен түбәндәге юлларда белдерә:

Тәүфикъ виргел хикмәт таба кайытмагә,
Гакыйль коллар хатерине байытмагә;
Йосыф сәүчи әхвалени айытмагә.
Гыйлмем камил, телем фәсих кылгыл имди[20].

Моннан чыгып, авторның укучысын тәүфыйклы, әдәпле, гакыллы итеп күрергә теләвен әйтә алабыз. Шулай ук ул әсәр белән танышучы кешене күз алдына китерә. Аныңча, һәркем автор әйтергә теләгән фикерне бөтен тирәнлегендә күрә, сиземли алырга сәләтле түгел. Шул ук вакытта автор, әсәрне укып, аның мәгънәсенә төшенгән укучы һичшиксез акыллы булыр, дип фикерли:

Гәүһәр даш, вә–ләйкин гәүһәр (даш) улмаз,
Дикмә кеши гәүһәр кадрен киас кыйлмаз,
Бу нәзъмнең кадрени ахмак белмәз, –
Гакыйль кеши дыңлар, аңлар, белүр имди[21].

Шул рәвешле, автор белән укучы арасында үзенчәлекле мөнәсәбәтләр формалаша. Югарыда китерелгән строфа укучыны әсәргә кат–кат мөрәҗәгать итәргә өнди, аңлашылмаган яисә игътибарга алынмаган

---

[17] Яхин А.Г. Татулык / Ул дәрья да бу дәрья. – 16 б.
[18] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1983. – Б.292.
[19] Шунда ук. – Б. 294 .
[20] Шунда ук. – Б. 50.
[21] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1983. – Б.292.

кайбер өлешләрне яңадан укып чыгарга мәҗбүр итә. Автор–укучы мөнәсәбәтләре автобиографик әсәрнең нигезен тәшкил итә. Еш кына автор укучыга турыдан–туры мөрәҗәгать итә. Шулай итеп, хәзерге мемуаристикада бик отышлы һәм еш кулланыла торган бу алым Кол Гали әсәреннән үк килә икән.

Алтын Урда чоры әдәбиятының иң күренекле әдипләреннән саналган Котбның тәрҗемәи хәле турында мәгълүматларны да аның әсәренә таянып кына белергә мөмкин. Әмма ул тәрҗемә иткән “Хөсрәү вә Ширин” дастанында авторның тормышына кагылышлы факт–детальләр гаять аз, хәтта аның исеме дә төгәл генә билгеле түгел. Әдәбият галиме Х.Й.Миңнегулов “Котб иҗаты” исемле хезмәтендә болай дип яза: “Чыннан да, “Хөсрәү вә Ширин”не укып чыккач, Котб безнең күз алдыбызда хис–фикерләргә бай, акыллы, эрудицияле кеше булып килеп баса”[22]. Галим аның үз әсәрен иҗат иткәндә инде өлкән яшьтәге мөгътәбәр кеше булуын фараз кыла, моны ул Алтын Урда ханы Тынибәккә аталарча үгет–нәсихәт бирүенә таянып дәлилли:

Ганимәт тот бу дәмне кем табулмаз,
Нитәк кем йилдим уш һич таш йабулмаз.
Ышаныч йук бу җиһанга йахшы түгел,
Йегетлекне ганимәт тот, кичәр бел.
Фәләк мәхкяр ирүр, зинһар, инанша,
Бу кач көн хуш тереклекдин учанма (14 б.).

Дөрес, автор күпмедер дәрәҗәдә үзе турында да хәбәр итә:

Морадым ирде ул кем бу капугда
Килеп йөр тапсаман тик бу тәпугда.
Сәфәр рәнҗеп күрдем үзем кач әйтәм
Тәпугка йиттем уш сәрәнҗәм (18 б.)[23].

Моннан чыгып, без Урта гасыр әдәбиятына нисбәтләнгән әсәрләрдә автобиографик детальнең әһәмиятен күз алдына китерәбез. Әдәби әсәрдә автор турында аерым мәгълүмат булу яки аның теге яисә бу мәсьәләгә карашын белдерү еш кына тәрҗемәи хәлен фараз кылырга мөмкинлек бирә. Димәк ки, бу әле тарихи әһәмияткә ия булып тора.

XIV йөз урталарында Идел буендагы Сарай Бәркәдә яшәгән шагыйрь Хәрәзминең “Мәхәббәтнамә” әсәрендә дә автобиографик детальләр урын ала:

“Мәхәббәтнамә” сүзен монда йиттем,
Камугын Сыр якасында битидем...

[22] Миңнегулов Х.Й. Котб иҗаты. Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбияты курсыннан студентлар өчен уку ярдәмлеге. – Казан, 1976. – Б.12–13.
[23] Ananiasz Zajaezkowski Najstarza wersia. Czescii, Faksimile, Wazsaka 1958.

Бу дәфтәр, кем булубтур Мисыр канди,

Йитте йөз илли түрт ичрә төкәнди[24].

Әсәр соңында китерелгән хикәяттә Хәрәзми үзе турында сөйли. Биредә ул әсәрнең тарихын бәян итә, Алтын Урдага караганда Сырдәрьяның түбән агымындагы төбәк белән идарә иткән Мөхәммәдхуҗага багышлануын күрсәтә. Мөхәммәдхуҗа аны үзе янында кышларга калдыра һәм шунда үзенә атап әсәр язуын үтенә. Хәрәзми үтенечне кире какмавын белдерә:

Кабул кылдым, йир үптеп, әйдем: и шаһ,

Ишекең тубрагы, дәүләтем дяргяһ;

Көчем йитмичә күп хезмәт кылайын,

Җиһанча тү атыңны йайа–йын. (232 а)

Алай да бу гамәле аны тирән борчуга сала. Ул үз теләгенә бәйсез рәвештә хөкемдарны мактарга мәҗбүр булуын рухи фаҗига кебек кабул итә. Әсәрнең ахырында үз шәхесен яклап, рухи бәйсезлеген раслап болай ди:

Ай айын имди бер кыйтга, ишткел,

Нәчүк мин, хәл вә әхвалемне белгел.

Тәмәгъ дамында калур кош имәс мин,

Тәмим әйван үзә очкан һома мин.

Кылыч тик тел бикә тоттум җиһанны,

Канәгать мөлке ичрә падишаһ мин.

Хәрабәт ичрә, мәсҗеддә йирем бар,

Кем уж һәм ринд мин, һәм парса мин.

Нәчә хишмәтле солтан булса булсын,

Әйтмән мал өчен мәдхе–сәна мин. (311 б.)

Шулай автор укучы алдында намусы керсез булуга басым ясый, үзен акларга омтыла. Аның күңеле каршылыклы хисләр белән тула, укучы бу турыда белергә хаклы дип саный. Автобиографик әсәрдә автор укучыны үзенең рухи халәте белән даими таныштырып бара, теге яисә бу вакыйгага бәйле хисләрен тасвирлый. Әсәрнең үз теләгенә каршы килеп язылуы Хәрәзмине борчый, бу турыда ачыктан–ачык әйтү укучыга авторга бәя бирү өчен ярдәм итә.

XIV йөз төрки–татар әдәбиятының игътибар үзәгендә торган шагыйрь Сәйф Сараи (1321–1396) “Йадкярнамә” исемле җыентыгында үзенең тормыш юлына кагылышлы түбәндәге фактларны күрсәтә:

Камышлы йорт бәнем туган илем(и)иде,

Белең горбәткә килтергән – белем(и)иде.

---

[24] Хорезми. Мухаббет–наме. Факсимиле, Л. 312 а / Татар әдәбияты тарихы. Алты томда.Т.I. – Б. 199.

Килеб улдым Сарайда шийр фидае,

Сарайның шагыйре – илнең гидае[25].

Шунда ук Идел буен калдырып китүенә бәйле хисләрен тасвирлап яза:

Үсеб туфрагым үзрә нәйзәләр, бән өвдин айрылдым,

Ватандин бинишан улдым да үзгә, йортка әврелдем.

Ничук фәләк җәүр әйладе, кандай гөнаһым вар?!

Илаһа әйлә кем җәүрең, бән илгә садикъ ул ир(и)дем[26].

Биредә автор йортыннан аерылудан туган хәсрәт хисенең дәрәҗәсен сөйләм интонациясен үзгәртеп ассызыклый.

XVI йөз шагыйре Мөхәммәдъярның тормыш юлы турында шигырьләрендә булган аерым детальләргә нигезләнеп кенә фараз кылып була. “Төхфәи мәрдан” (“Егетләр бүләге”, 1540) әсәрендә әдип исеменең Мәхмүд Хаҗи углы фәкыйрь Мөхәммәдъяр булуы искәртелә, ике урында ул үзен Ярмөхәммәд дип атый. “Нуры содур” (“Күңелләр нуры”, 1542) поэмасында шагыйрьнең Мөхәммәд Әмин каберендә мөҗәвир – сакчы булып торуы хәбәр ителә:

Атымны кем тиб сурсаң, и шәһрийар:

Мәхмүд Хаҗи углы фәкыйрь Мөхәммәдйар...

Уш бу “Төхфә” тарихын гәр сурсалар,

Тукыз йөз кырык алтыдыр белсәләр[27].

Бу мотив атаклы суфи шагыйрь Мәүлә Колый, ХУШ йөздә яшәп иҗат иткән Габди, Габдессәлам шигырьләрендә дә урын ала. Мәүлә Колый күңелендәге бар борчуларын, уй–фикерләрен шигырьләрендә бәян итә. Күп очракта автор үз–үзе белән сөйләшә, сорау куя, җавап эзли. Автобиографик әсәргә ике “мин”нең үзара әңгәмә коруы хас. Язучы тормыш юлы турында өлкән, мөгътәбәр әдип буларак фикер йөртә, яшь “мин”нең кылган гамәлләренә бәя бирә. ХУП йөз суфи шагыйренең шәхси тормышы турында уйланулары – аның үз–үзенә бәя бирүе ул. Мисал өчен:

Мәүлә Колый, ата–анаң белдең микән,

Хушнуд кылып, изгү дога алдың микән,

Йугса хушнуд булмай аңлар үтте микән?

Каны бу көн кулдин китте, нитмәк кәрәк[28].

Йомгаклап әйткәндә, ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгәннән соң татар әдәбиятында автобиографик детальләр урын алу язучыларның

---

[25] Сәйф Сараи. Ядгярнамә / Гөлестан. Лирика. Дастан. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1999. – Б.275.

[26] Шунда ук. – Б.274–275.

[27] Абилов Ш. Мөхәммәдьяр иҗаты / Татар әдәбияты тарихы. – Т.I. – Б.296.

[28] Абилов Ш., Дәүләтшин К. Мәүлә Колый иҗаты / Татар әдәбияты тарихы. –Т.1. – Б.370.

киләчәк буыннарга үз шәхесләре турында ишеттерергә теләве белән аңлатыла. Биредә карап үтелгән хезмәтләрдән күренгәнчә, авторлар үзләре хакында никадәр кирәк санаса, шул күләмдә мәгълүмат бирәләр, аерым урында хис–кичерешләрен, укучыга мөнәсәбәтләрен бәян итәләр. Борынгы әдәбияттан аермалы буларак, Урта гасыр әдипләре автобиографик материалны бирүдә алдан максат куеп арттыру алымын файдаланудан ераклашалар, төгәлрәге, үз шәхесләре турында тыйнак кына, сөйләм интонациясен үзгәртеп, кайбер чигенешләр ясап сүз кузгаталар. Ни кызганыч, аерым әдипләр тормышына кагылышлы мәгълүмат бөтенләй сакланмаган, бу исә бүгенге көн укучысына язучы турында биографик материалга таянып фикер йөртергә ирек бирми.

Х1Х йөз татар әдәбияты яңа юнәлешләр, әдәби жанр, тематикада үсеш–үзгәрешләр белән характерлы. Бу чорда проза һәм шигъри жанрлар аеруча активлаша. Прозада фәнни–публицистик юнәлеш калкып чыга. Урта гасыр татар әдәбиятының нигезен тәшкил иткән дини мотив беркадәр арткы планга күчә. ХУШ гасырда яшәгән Г.Курсави, Г.Утыз Имәни, Х1Х йөз шагыйре Һ.Салихов кебек әдипләр шулай ук татар әдәбиятының яңа үсеш баскычына күтәрелүен әзерли. Әдәбиятта аерым кешегә, шәхескә игътибар итү Х1Х йөзгә кадәр бөтенләй диярлек күзәтелмәсә, яңа дәвер сәнгате кешене шәхес буларак тәрбияләүгә, әхлак мәсьәләләрен яктыртуга йөз тота. Әдәбият та шул максатка хезмәт итә. Автобиографик жанр формалашу өчен, бу чорда уңайлы җирлек барлыкка килә. Шул факторларны күздә тотып, жанр формалашуның өченче этабы буларак, ислам дине йогынтысында иҗат ителгән әдәби әсәрләрне аерып карарга була.

Кайбер тарихи сәбәпләргә бәйле рәвештә, документалистика нык кына үсеп китә. Әлбәттә, Урта гасырдан килгән аерым традицияләр дәвам иттерелә, әсәр эчендә фактологик–биографик материал булу әһәмиятен югалтмый. Мисал өчен, Х1Х гасырның күренекле шагыйрьләреннән Әбелмәних Каргалыйның 1845 елда “Тәрҗемәи Хаҗи Әбелмәних...” исемле ун шигырьле хикәятне үз эченә алган китабы басыла. Өченче хикәяттә автор үзенең Якын Көнчыгышка сәяхәте, Мисыр патшасы Мөхәммәтгали хакында материаллар туплый. Шәһре Каргалы – фәкыйрьнең мәүлиди, өммәте Әхмәт, рогъяти – Мәскәви, – дип, шагыйрь үзенең “Мәскәү гражданы” булуына басым ясый[29].

XIX йөзнең 30 еллар татар әдәбиятында аерым урын тоткан Гомәр Мөхәммәт улының “Сәфәрнамәи шаһзадә Александр” исемле әсәрендә автобиографик детальләр зур урын ала. Шагыйрь үзенең тормыш юлы

турында белешмә бирә, төп иҗат принципларын билгеләп үтә. Әлеге авторның “Тәзкирәи Габдессәлам мөфти” язмасы татар әдәбиятында биографик жанрдагы әсәргә якын тору белән үзенчәлекле. Гомәр Мөхәммәтнең төп максаты булып, чәчмә әсәрдә чор кешесе образын тудыру тора. Шуның белән беррәттән, ул “Болгар илендә һәм Казан тирә якларында, Әстерхан, Оренбург ягында, шулай ук башка аймаклардагы әһле ислам арасында күп кенә шәригать галимнәре, тарикать ияләре”, аларның хәлләре, йөреш–торышлары турында хәбәрләр язарга ниятли[30]. Урта гасырның тәзкирә (истәлек, искә алу) жанрында язылган бу әсәрдә Габдессәламның Оренбургка мулла итеп чакырылуы, патша Александр 1 Оренбургта тору дәверендә аны кабул итүе, шәһәрне төзекләндерү күренеше һ.б. вакыйгалар тасвирлана. Моннан тыш, авторның Габдессәламгә шәхси мөнәсәбәте, аның кылган гамәлләрен хуплавы ачык күренә, ягъни әсәрдә авторның бәясе урын ала. Истәлек, нигездә, шигъри жанрда языла, аерым урыннарда прозага күчү дә игътибарны җәлеп итә. Гомәр Мөхәммәт үз хезмәтенең кыйммәтен алдан ук билгели: “... белем иясе булган һәр кеше, бигрәк тә галимнәр, камил белемлеләр, үзләре хакында һәм белгән кешеләре хакында язып калдырырга тиешләр...”[31] Кагыйдә буларак, истәлекләр авторы шәхси биографиясен яңадан барлауның тарихи әһәмиятен күздә тотып эш итә, аның кыйммәтен алдан белеп, хезмәтенә аеруча җитди карый.

Әсәрдә тормыш–көнитеш вакыйгалары гадәттән тыш географик киңлекне колачлап тасвирлана. Сөйләм Оренбург – Петербург – Таганрог – Уфа – Оренбург күчеше белән алып барыла. Патша, министр, губернатор, Көнчыгыш сәүдәгәрләре образлары аша әсәрдә шул чорның мөһим мәсьәләләре калку чагылыш таба. Бу исә – татар әдәбиятының көнкүрешкә якынаюы, тормыш турында мәгълүмат бирүе, укучының танып–белү дәрәҗәсен күтәрү функциясенең ачыла баруына дәлил.

Әдәбиятта чынбарлыкка игътибар арту, яңа жанрлар туу үзгә иҗат юнәлешләре барлыкка килү өчен этәргеч була. Х1Х йөзнең 80 елларыннан мәгърифәтчелек реализмы әдәбиятның төп иҗат методына әверелә. Мәгърифәтчелек әдәбияты, әхлакый проблемаларны киң җәмәгатьчелек алдына кую өчен, публицистик жанрга мөрәҗәгать итә. Бу жанрның фикерне ачыктан–ачык тасвирлау мөмкинлеген әдипләр иркен файдаланалар. Урта гасырдан ук популярлык казанган сәяхәтнамә жанры Х1Х йөздә күп язучыларның игътибар үзәгендә тора. Язучылар Россиянең

---

[29] Гайнетдинов М. Әбелмәних Каргалый / Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т. II. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1985. – 126 б.

[30] Гайнетдинов М. Гомәр Мөхәммәт улы / Татар әдәбияты тарихы. Т. II. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1985. – Б.139.

[31] Шунда ук . – Б.143.

төрле өлкәләрендә булулары, чит илләргә сәяхәтләре турында, шуңа бәйләп төрле ил–халыклар тормышы, татар дөньясының мөһим мәсьәләләре хакында фикер йөртәләр. Бу жанр мәгърифәтчел идеяләрне үткәрү өчен иң кулай жанрларның берсе дип табыла. 1874 елда Гали Чокрыйның “Хаҗнамә”, Заһир Бигиевнең “Мавәраэннәһердә сәяхәт”, 1902 елда Фатих Кәриминең “Европа сәяхәтнамәсе”, 1904 елда “Кырымга сәяхәт” әсәрләре дөнья күрә.

Сәяхәтнамә жанры документаль әдәбиятның башында тора дисәк тә хата булмас. Тарихта Ибне Фадлан (X йөз), Ибне Батута (1304–1377), Әүлия Чәләби (1611–1683) һәм башка күпләгән шәхесләрнең сәяхәтнамәләре билгеле. Сәяхәтнамә автобиография һәм мемуар кебек үк чәчмә формада языла һәм анда хикәяләү беренче заттан алып барыла. Әлеге жанрларның тагын бер уртак ягы – авторлар үзләре күргән, кичергән вакыйгалар турында язуда, әсәрләрдә чынлык, объективлык өстенлек итү, уйдырмага чагыштырмача аз урын бирүдә. Болардан тыш, итальян сәяхәтчесе Джованни дель Плано Карпининың (1182–1252) һәм француз Гильом де Рубрукның XШ гасырда монголларның хан урдасына сәяхәте турында язылган “Путешествие в Восточные страны Плано Карпини и Рубрука”, Марко Полоның “Книга Марко Поло”, Мөхәммәд Әмин Гомәр углының “Мөхәммәд Әмин сәяхәтнамәсе” (1780), Исмәгыйль сәяхәтнамәсе билгеле.

Х1Х гасыр шагыйре Гали Чокрыйның “Хаҗнамә” әсәре (1873–1874), беренче хаҗ сәяхәтеннән кайткач, авылдашлары, дус–ишләре үтенече белән языла. Биредә шагыйрь хаҗга баручы диниятле галим тормышын объектив бәяләүгә игътибар бирә. Әсәрдә ватанпәрвәрлек рухы өстенлек ала, шагыйрь туган илен сагына, туган җиренә мәхәббәт хисләрен иң югары дәрәҗәдә тасвирлый. Сүз беренче заттан алып барыла, анда лирик башлангыч, аһәңле шигъри тел лирик геройның хисләрен үтемлерәк тасвирлауга ярдәм итә.

Шул рәвешле, XIX гасырга сәяхәтнамә жанрының һәм тарихи, һәм әдәби әһәмияте арта, язучылар бу өлкәдә зур хезмәтләр башкарып, үз фикерләрен халыкка җиткерү өстендә эшли башлыйлар. XIX йөзнең икенче яртысында яшәп иҗат иткән Заһир Бигиев сәяхәтнамәсе язучының иң күренекле әсәрләреннән санала, татар әдәбиятының кыйммәтле мирасы булып тора. “Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә” (1887), “Гөнаһы кәбаир” (1890) романнары белән беррәттән, “Мавәраэннәһердә сәяхәт” (1893) әсәре дә әдипнең мәгърифәтчелек карашларын һәм омтылышларын чагылдыра. Язучы сәяхәтнамәдә 1893 елның җәй–көз айларында Мавәраэннәһергә (Урта Азиягә) сәфәрен тасвир итә. Юлга чыгуның төп максаты “ул тарафтагы дин кардәшләребезне хәзерге хәлләрен әүвәлге хәлләре белән

чагыштырып, гыйбрәт алу була”[32]. Биредә язучы үз чорының мөһим мәсьәләләрен яктыртуга ирешә. Бохарадагы мәдрәсә тәртипләре, аларда укучы Русия шәкертләренең аянычлы тормыш хәле, ниһаять, бүгенге чынбарлыкны үткән заман белән чагыштыру рухы әсәрнең нигезен тәшкил итә. З.Бигиев юлъязмада урнаштырган бөтен материалга үз фикерен, бәясен биреп бара. Аның “язу стиленең эмоциональ кайнарлыгы”[33] сәяхәттән туган борчылу, халкы турында хәсрәтләнү хисенең иң югары дәрәҗәдә булуы белән аңлатыла.

Кагыйдә буларак, автобиографик әсәрнең бер катламын информация өлеше тәшкил итә. Анда укучы язучының балачагы турында хатирәләре белән таныша, ул яшәгән мохит хакында мәгълүмат ала. Ә инде сәяхәтнамә жанры тулысы белән информациягә корыла. Әдип укучыга сәяхәте узган җирләрнең географиясе, ул җирләрдә яшәүче халыклар, кирәк тапса, аларның үткәне, тарихи язмышлары, гореф–гадәтләре, дини йолалары турында күргән, белгән, ишеткәннәрен җиткерә. Шул ук вакытта тупланган гыйльми материалга авторның шәхси мөнәсәбәте дә ачыклана. Бу үзенчәлек сәяхәтнамә һәм автобиографик жанрларын беркадәр якынайта.

XIX йөзнең соңгы елларында әдәбиятка килгән Фатих Кәрими 1899 елда алтын приискасы хуҗасы Шакир Рәмиев белән берлектә Аурупа илләренә сәяхәткә китә. Мәскәү, Петербург аша үтеп, Германия, Бельгия, Франция, Италия һ.б. Аурупа илләре аша дүрт ай дәвамында сәфәр кылып, алар Төркия аша Оренбургка кайталар. 1902 елны шәхси көндәлегендә тупланган тарихи материал, истәлекләр “Аурупа сәяхәтнамәсе” дигән исем астында Петербургта дөнья күрә. Татар җәмәгатьчелеге беренче мәртәбә Аурупа илләрендәге мәдәният учаклары, әдәбият, сәнгать музейлары турында күзаллау булдыра.

З.Бигиев һәм Ф.Кәрими – ялкынлы публицист буларак танылган әдипләр. Ф.Кәрими, ил, халык тормышы турында шәхси фикерләрен бәян итү өчен, документаль жанрга берничә мәртәбә мөрәҗәгать итә. 1904 елны аның “Кырымга сәяхәт” исемле күләмле хезмәте басыла. Биредә 1903 елда “Тәрҗеман” гәзитенең егерме еллык бәйрәменнән кайткач туган фикерләр урын ала. Жанр таләбе буенча, гадәттә, автор игътибарын үзе кирәк тапкан объектларга юнәлтү белән чикләнә. Мисал өчен, Ф.Кәрими “Аурупа сәяхәтнамәсе”ндә немецларның – гыйлемгә, бельгиялеләрнең – сәүдәгә, французларның әдәбият һәм сәнгатькә хәерхаклы мөнәсәбәтләрен хуплый. Моннан тыш, Мәскәү һәм Петербург китапханәләре, аларда фәнни–әдәби хезмәтләрнең күплеге турында яза, сәнгать музейларының

[32] Бигиев З. Мавәраэннәһердә сәяхәт / Зур гөнаһлар. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1991. – Б.132.

искиткеч бай булуын билгеләп үтә. “Кырымга сәяхәт” әсәрендә Оренбург мөселманнары, ислам дөньясындагы яңалыклар һ.б. хакында бәян итә.

Фатих Кәриминең “Морза кызы Фатыйма” (1901) әсәрендә реаль тормыш–көнкүреш материалына нигезләнгән вакыйгалар тасвирлана. М.Гайнетдинов аны “әдәбиятбызның тәүге документаль–биографик әсәрләреннән дип хисаплап була”[34], ди. Әсәр Исмәгыйль Гаспралының этисе Мостафаның морза кызына өйләнү вакыйгаларыннан торган сюжетка корыла. Димәк ки, әдәбиятыбызны фактик материалларга таба бору – Ф.Кәрими иҗатының бер үзенчәлеге дия алабыз.

Автобиографик жанрның нигез чыганагы булып торган биобиблиографик жанр формалашу XIX гасыр әдәбияты тарихында зур әһәмияткә ия күренеш иде. “Әдәби энциклопедик сүзлек”тә әлеге жанрга түбәндәге билгеләмә бирелә: “Биобиблиографик әдәбият – язучылар, тәнкыйтьчеләр, публицистлар, әдәбият галимнәре турында биографик һәм библиографик характердагы белешмә. Мондый белешмәләрнең иң киң таралган төре – язучыларның сүзлекләре, шул ук вакытта аерым язучыларга багышланган персональ библиографияләр дә очрый”[35].

Татар әдәбиятында әлеге жанрның башлангычы XIX гасыр әдәбияты тарихында тирән эз калдырган мәгърифәтче галим Шиһабетдин Мәрҗани эшчәнлегенә барып тоташа. Бу акыл иясе үзенең хезмәт юлын татарның югала башлаган тарихын, хәтерен барлауга багышлый. Аның фикеренчә, “милләтнең үзаңы формалашу өчен үзеңнең “мин”еңне белү, тарихи–мәдәни традицияләр булдыру һәм аларны Көнбатыш традицияләре белән берләштерү зарур”[36]. Тарихчы галимнәр Ш.Мәрҗанинең Көнчыгыш мөселманнары рухи культурасына керткән зур өлешен билгеләп үтәләр. Ул Көнчыгыш мөселманнары турында беренче татар энциклопедиясе авторы буларак билгеле. Галим, мондый характердагы эзләнүләрнең бөтен әһәмиятен аңлап, бер халыкның башка халык турында белемнәрен арттыру максаты белән эшләп чыккан.

Ш.Мәрҗанинең “Вафият әл–әсләф вә тәхият әл–әхләф” (А.Юзеев хезмәтне “Подробное о предшественниках и их приветствия потомкам” дип тәрҗемә итә) дип исемләнгән биобиблиографик жанрдагы хезмәте татар, рус, Көнчыгыш галимнәре тарафыннан югары бәяләнә. Әлеге китап – татар әдәбияты тарихында биобиблиографик жанрның тәүге үрнәге. Хезмәт тулысы белән гарәп телендә языла. Структур яктан ул ике кисәктән – 1833 елда нәшер ителгән “Мөкаддимәте китаб “Вафият–әл–

---

[33] Даутов Р. Заһир Бигиев / З.Бигиев. Зур гөнаһлар. – Б.370.
[34] Гайнетдинов М. Мәгърифәтче әдип // Мирас. – 1995. – № 7. – Б.70.
[35] Литературный энциклопедический словарь. – С. 618.
[36] Юзеев А. Мировоззрение Ш.Марджани и арабо–мусульманская философия. / Ш.Марджани: Наследие и современность. Материалы международной научной конференции. – Казань, 1998. – С. 58.

əсләф вә тәхиятәл–әхләф", ягъни "Кереш" һәм кульязма өлештән тора. 2000 елда кереш тәрҗемә ителеп дөнья күрә. Алты томнан торган кульязма өлешенең бердәнбер нөсхәсе КДУ фәнни китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

А.Мөхәммәтҗанов фикеренчә, Ш.Мәрҗани бу энциклопедияне төзегәндә, ике максаттан чыгып эш итә: "1) татар мөселман мәдәнияте гомум мөселман мәдәниятенең бер өлеше икәнен күрсәтү һәм аның эчтәлеген ачып салу; 2) Урта гасырларда милли мәдәниятнең үзенчәлекләрен, ә Яңа вакытта – аңа гына хас үзенчәлекләрен күрсәтү һәм бөтен дөньяга татар халкы, аның үзенең мәдәнияте, исеме, теле, дине, шул халыкның киләчәге бар икәнен исбат итү"[37]. Әлеге хезмәтне анализлап, аны тарихи аспектта бәяләгән галим М.Х.Юсупов "Мөкаддимә ..."нең фәнни характерда булуын ассызыклый. Бу фикерен ул хезмәттә авторның фәнни методологик карашлары урын алуы белән нигезли[38].

Көнчыгыш мөселманнарында биобиблиографик жанр XIV гасырда ук формалаша һәм үсеш ала. Мисалга, гарәп галиме Ибн Халдунның (1332–1406) "Китаб әл–ибар вә диван мөбтәдә вә–л–хабр фи әйам әл–гарәб вә–л–әдҗам вә–л–барбар" (Гарәпләр, фарсылар, бәрбәрләрнең тормышы, эшләре турында башлангыч җыентык) билгеле. Биредә җәмгыятьнең икътисади, сәяси, мәдәни хәле, бәгланышлары турында мәгълүмат урын ала. А.Юзеев билгеләп үткәнчә, Ибн Халдун стиле, гомумән, Урта гасыр энциклопедистларына хас. Ул цивилизация, ыруглар, дәүләтләр, шәһәр һәм авыллар, алардагы һөнәрчелек, фән һәм башкалар турында яза[39]. Философ һәм тарихчы буларак, ул XIX гасырда Ауропада танылa. Россиядә беренчеләрдән булып аның хезмәтенә Ш.Мәрҗани игътибар итә. Ибн Халдун китабыннан тыш, гарәпләрдә күп кенә галимнәр биобиблиографик жанр үрнәкләрен бирәләр. Шулардан әш–Шахрастаниның "Китаб ал–милал ва–н–нихал" (Дин һәм секталар турында китап), Якут әл–Хәмәвинең "Мөдҗәм әл–булдан" (Илләр сүзлеге), Ибн Халиканның "Вафаят әл–әйан" (Атаклы кешеләрнең үлемнәре турында), Таки әд–дин әл–Мәкризи "Әд–дурар әл–каминә фи әйан әл–миа әс–самина" (800 (1398) елда туган атаклы кешеләр турында яшерен энҗеләр), Ибн Хәҗәрнең, Ибн Надимның һ.б.ларның әсәрләре аеруча киң тарала.

---

37 Мөхәммәтҗанов А.А. Ш.Мәрҗанинең "Вафийәтел–әслаф..."ы һәм Р.Фәхреддиновның "Асар"ы. / Ш.Марджани: Наследие и современность. Материалы международной научной конференции. – Казань, 1998. – С. 187.

38 Юсупов М.Х. "Вафият ал–аслаф ва тахият ал–ахлаф" Шихаб–ад–дини Марджани как источник по истории мусульманского Востока. – М., 1979. – С. 191–194.

39 Юзеев А. Мировоззрение Ш.Марджани и арабо–мусульманская философия. / Ш.Марджани: Наследие и современность. Материалы международной научной конференции. – Казань, 1998. – С. 59.

Биографик сүзлек жанрын дәвам итеп, Ш.Мәрҗани аны беркадәр гомумиләштерә. “Вафият әл–әслаф...”та, традицион рәвештә фән эшлеклеләре белән бәррәттән төрле хаким династияләр турында да материал туплый. Моннан тыш, автор фактик материалны иҗади эшкәртә, Көнчыгыш мәдәнияте җәүһәрләрен анализлый, аларга бәя бирә. Биредә Ш.Мәрҗәнинең мәгърифәтче галим буларак карашлары гәүдәләнеш ала. Моңа А.Юзеев, Н.Гәрәева аерым игътибар бирәләр. Н.Гәрәева Ш.Мәрҗәнинең теге яисә бу мәсьәләгә карашын хезмәткә таянып билгеләргә мөмкин дигән фикер әйтә[40].

Энциклопедиядәге фактик материал Урта гасыр мөселман мәдәниятенең үсешен тасвирлауны күздә тота. Биографияләр белән танышканда, Ш.Мәрҗанинең Көнчыгыш мөселманнары турында, аларның тарихы хакында киң мәгълүматлы булуы ачыклана. Ш.Мәрҗани төзегән энциклопедия Ибн Халдунның җыентыгы белән аваздаш. Аерым алганда, фәнни классификация мәсьәләсен Ш.Мәрҗани гарәп галиме тәкъдим иткән система буенча алып бара. Ләкин хезмәтләр композиция һәм материал бирелеше ягыннан аерыла[41].

Ш.Мәрҗани хезмәтендә VIII–XIX гасырларда яшәп иҗат иткән мөселманнардан 6057 галим, язучы, фәйләсүф һәм җәмәгать эшлеклесе хакында биографик материал туплана. А.Юзеев әлеге хезмәтне үзенең төзелеше белән биографик энциклопедия характерында дип билгели. Аның төп өлеше сүзлек итеп төзелгән, атаклы шәхесләрнең тормыш юлына караган мәгълүмат, аларның үлгән елларыннан чыгып, алфавит тәртибендә урнаштырылган. Хезмәтнең жанр үзенчәлекләрен барлап, күп галимнәр аның уникальлеген билгеләп үтәләр. Н.Гәрәева фикеренчә, бу хезмәт татар һәм гарәп биографик традицияләрен берләштерүе белән әһәмиятле[42].

Ш.Мәрҗанинең “Вафиятел–әслаф ...” китабы белән бәррәттән, татар библиографик жанр үсешендә Р.Фәхреддиннең “Асар” дип исемләнгән хезмәте игътибарга лаек. Аның галим булып өлгерүендә Ш.Мәрҗанинең йогынтысы бәхәссез. Әле мәдрәсәдә укыган чорында ук, Р.Фәхреддин, галим белән танышырга ниятләп, Казанга килә, аның өендә була, бай этнографик китапханәсенә соклана. Соңрак үзенең һәртөрле эшчәнлегендә остазының өйрәтмәләреннән файдалана. Хезмәтенең бер кульязма томында Ш.Мәрҗанинең нәсел шәҗәрәсе турындагы материаллар

[40] Гараева Н. Источник “Вафият ал–аслаф ва тахият ал–ахлаф” Ш.Марджани. / Марджани: ученый, мыслитель, просветитель. – Казань, 1986. – С.104.
[41] Юзеев А. Мировоззрение Ш.Марджани и арабо–мусульманская философия. – С. 59.
[42] Гараева Н. Источник “Вафият ал–аслаф ва тахият ал–ахлаф” Ш.Марджани. / Марджани: ученый, мыслитель, просветитель. – Казань, 1986. – С. 94.

урнаштыра. Шунда ук Г.Тукайның, Йосыф Дастанинын, Г. Чокрыйның Ш.Мәрҗанигә багышлап язган мәрсияләрен кертә.

А.Мөхәммәтҗанов фикеренчә, “Асар” – фундаменталь тикшеренүләрне сорый торган фәнни хезмәт[43]. Аның исеме бүгенге көнгәчә төгәл тәрҗемә ителмәгән. Ф.Н.Баишев “асар” сүзен “эзләр” яисә “һәйкәлләр” дип тәрҗемә итә[44]. А.Мөхәммәтҗанов хезмәтнең исемен “Гамәлләр” дигән мәгънә белән тәрҗемә итү дөресрәк булыр дип аңлата[45]. Ш.Мәрҗани ниятләрен тормышка ашыруны дәвам итсә дә, Р.Фәхреддин, энциклопедиягә материал биргәндә бөтен мөселман дөньясын иңләми, ә татарларның тарихи шәхесләрен тикшерү, аларга бәя бирү белән чикләнә. Форсаттан файдаланып, Р.Фәхреддиннең шәхси хатларга аерым игътибар бирүен билгеләп үтәргә кирәк. Ул шәхси хатларны ташларга ярамаганлыгын, аларның иҗтимагый әһәмияткә ия булуларын ассызыклый[46]. А.Мөхәммәтҗанов Р.Фәхреддиновның туган теленнән тыш гарәп, фарсы, төрек һәм рус телләрен белүен һәм энциклопедиядә Петербург университеты галимнәре Самойлович, Бартольд, Крачковский һ.б.ларның материалларын файдалануын искәртә. Р.Фәхреддинов үз хезмәтенең кыйммәтен аңлый, “Асар” милли тарихны язуда яхшы китаплар чыкканчы бер чыганак булып торыр”, – дип күрсәтә[47].

Автобиографик жанрның нигезен язучы тормышыннан алынган фактик мәгълүматлар тәшкил итә дигән идек. Татар мемуаристикасының башлангычында аерым катлам булып торучы биобиблиографик жанрның туу чоры, һичшиксез, документаль әдәбият үсешендә зур сикереш буларак бәяләнергә хаклы.

Татар автобиографик әсәре тууына Көнбатыш Аурупа, рус әдәбияты да уңай йогынты ясый. 40–50 нче елларда рус әдәбияты реализм иҗат юнәлешенә йөз тота. Повесть, очерк, роман жанрлары белән беррәттән, биографик һәм мемуар әдәбият үсеш кичерә. Ф.В.Булгарин, М.А.Дмитриев, С.Г.Аксаков, Ф.Ф.Вигель, С.С.Уваров, А.И.Иванчин–Писарев кебек язучылар истәлек жанрына мөрәҗәгать итәләр. Пушкинга, Дельвигка багышланган әсәрләр дөнья күрә, Якушкин “Биографические записки” дигән исем астында журнал чыгара. Шул чорда П.А.Вяземский болай язып чыга: “Мин һәммә кешене записка (язма), биографияләр язарга

[43] Мөхәммәтҗанов А.А. Ш.Мәрҗәнинең “Вафийәтел–әслаф...”ы һәм Р.Фәхретдиновның “Асар”ы. – С. 185.
[44] Баишев Ф.Н. Общественно–политические и нравственно–этические взгляды Ризы Фахретдинова. – Уфа, 1996. – С. 5–6.
[45] Мөхәммәтҗанов А.А. Күрсәтелгән хезмәт. – Б.186.
[46] Баишев Ф.Н. Күрсәтелгән хезмәт. – С. 58.
[47] Мөхәммәтҗанов А.А. Күрсәтелгән хезмәт. – Б.189.

үгетлим. Бу – безнең эш: без материал туплый, җыйный алабыз, ләкин нәтиҗәләр ясарга иртәрәк әле"[48].

Шул рәвешле, XIX гасырда истәлекләр иҗат итүнең аерым кануннары формалаша башлый. Язучылар сүзне нәсел шәҗәрәсен сөйләүдән башлап, хронологик тәртиптә үз тормышларындагы иң мөһим вакыйгаларга тукталалар. Кагыйдә буларак, язучы үзенең иҗтимагый эшчәнлеген, гаилә хәлен, атаклы кешеләр белән очрашуларын, аларның шәхси портретларын тасвир итә. Сөйләм еш кына өченче зат исеменнән алып барыла.

Рус әдәбиятының йөзен билгеләүче олуг әдип А.С.Пушкинның шәхси истәлекләр язуы билгеле. Н.Е.Мясоедова Пушкинның биографик һәм автобиографик текстларын өч төркемгә бүлеп өйрәнә: художестволы биография ("Байрон", "Арзрумга сәяхәт"); әдәби биография (С.т.Кольридж китабы үрнәгендә язылган); документаль биография ("Автобиография башы"). Болардан тыш, язучының "Дневники 1833–1835" дип исемләнгән көндәлекләре бар. Пушкинның мемуарлары шәхеснец үз тормышы белән шул чорның иҗтимагый атмосферасын бәйләп тасвирлауны күздә тота. Нәсел шәҗәрәсе, гаилә хәле турында сөйләүдән тыш, ул үзенең шәхес буларак формалашуын да бәян итә. "Иртә сөю" һәм "Минем күңелсез хатирәләрем" бүлекләрендә, беренче чиратта, күңелендә авыр тәэсир калдырган мәхәббәт тарихын сурәтли. Шуның белән беррәттән, Пушкин автобиографиясе рус әдәбиятында беренче мәртәбә балачак темасына мөрәҗәгать итә.

XIX гасырның икенче яртысы рус әдәбиятында "күчеш чоры" буларак билгеләнә. 30 еллардагы аерым шәхескә игътибар тенденциясе әдәбиятта туа килүче яңа иҗат методы – реализм кысаларында психологизм алымын куллануны таләп итә. Әдәбиятның үзенчәлекле дәверендә мемуар, автобиографик очерк һәм башка жанрларга игътибар бермә–бер арта. 1852 елда Л.Н.Толстой өч кисәктән уйланылган "Балачак", "Үсмерчак", "Яшьлек" әсәренең беренче кисәген тәмамлый. Шул ук елны Герцен "Үткәннәр һәм уйланулар" әсәренең беренче кисәген язу эшенә алына. Л.Гинзбург бу ике әсәрнең бер чорда языла башлавын тарихи закончалыклы күренеш дип аңлата[49].

Аерым кешегә, замана героена игътибар итү XIX йөз башы татар әдәбиятында ук күзәтелә. "XIX йөз башындагы татар әдәбиятын алып карасак, анда мәгърифәтчелек реализмы, критик реализм һәм романтизм юнәлешләренең аеруча кыска аралыкта, хәтта берьюлы мәйданга килеп,

---

[48] Вяземский П.А. Записные книжки. – М.–Л., 1963. – С. 205.
[49] Гинзбург Л. "Былое и думы".Герцена. – С. 13.

аралашып һәм тыгыз бәйләнеш–мөнәсәбәттә торуын очратырбыз”[50]. Моның җитди сәбәпләре булып “иҗтимагый–тарихи барышның гадәттәгедән күп мәртәбә көчле, интенсив” хәрәкәте, әдәбиятның бай традицияләре, алдынгы әдәбиятлар тәҗрибәсен уртаклашу, алардан үрнәк алу ихтыяҗының үсеп китүе тора.

XIX гасырның икенче яртысында киң колач алган мәгърифәтчелек реализмы татар әдәбиятының үсешендә хәзерлек баскычы ролен үтәсә, рус һәм Ауропа әдәбиятларына йөз белән борылу, аларга игътибар арту милли әдәбиятны яңа рухта үстерүгә этәргеч була. Озак гасырлар буена Көнчыгыш әдәбиятлары белән тыгыз бәйләнештә яшәгән татар әдәбияты XX гасыр башында Көнбатышка ориентация ала.

Милләтне мәгърифәтле итү өчен көрәш дәвам итә, хәтта үзәк идеянең берсенә әверелә. Билгеле, бу көрәш әдәбиятта тәнкыйди тенденцияләрне көчәйтә, шул рәвешле мәгърифәтчелек реализмына алмашка тәнкыйди реализм методы килә. XX гасыр башы әдәбиятының тагын бер үзенчәлеге – аерым шәхесне бәхетле итү идеясе шулай ук милләтне икътисади һәм мәдәни яктан үстерерү проблемасына барып тоташа. Милләтне үстерү мәсьәләсе бу чор татар әдәбиятында лейтмотивка әйләнә, шәхес бәхетен милләт язмышы белән бәйләп карау гасыр башы әдәбиятының бер үзенчәлеге, иң әһәмиятле сыйфаты төсендә аның киләчәк үсеш юлын билгели.

Тизләтелгән үсеш сәбәпле, әдәбиятта һәр метод бер–берсе белән тыгыз бәйләнештә яши. Кеше характерын аңлау, күңел кичерешләрен бәяләүгә мәгърифәтчелек реализмы гомумилек, типиклык күзлегеннән караса, шәхси башлангычка игътибар итү – романтизм иҗат методының үзенчәлеге иде. Тәнкыйди реализм исә шәхес холкының һәм психологиясенең индивидуаль һәм типик бөтенлеген сурәтли. XX башында иҗат иткән әдипләр инде әхлак кагыйдәләрен кешеләрнең табигый асыллары дип исәпләделәр. Кешеләрнең эчке дөньясы реаль тормыш вакыйгалары кебек үк иҗат объектына әйләнде. Шуңа күрә татар әдәбияты XX гасыр башында асылда реализм иҗат методына йөз тота.

Бу чорда татар әдәбияты үзеннән алгарак киткән әдәбиятларның традицияләренә мөрәҗәгать итә. X1X гасыр рус әдәбиятында формалашкан автобиографик жанр үрнәкләре XX гасыр татар әдәбиятында да күзәтелә башлый. 1907 елда Г.Исхакыйның “Зиндан” повесте, 1909 елда Г.Тукайның “Исемдә калганнар” әсәрләре тәүге документаль–автобиографик әсәрләрдән саналалар. Болардан тыш, Ф.Әмирхан “Фәтхулла хәзрәт” повестеның 1911 елгы басмасында

---

[50] Халит Г. Әдәби процессның төп юнәлеше / Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.Ш. – Казан:

26

укучыларга ирония белән көлү катыш язылган “Минем тәрҗемәи хәлем” әсәрен тәкъдим итә. Г.Исхакыйның “Зиндан” повестеннан соң, төрмә темасын яктырткан тагын берничә әсәр дөнья күрә. Шулардан, Й.Акчураның “Мәүкуфият хатирәләре” (“Тоткынлык хатирәләре”, 1907) әсәрен, З.Шаһгәрәевнең “Төрмәләр хатирәсе”, 1913) исемле әдәби документаль повестен билгеләп үтәргә мөмкин.

Г.Исхакыйның “Зиндан” әсәре структур яктан, автобиографик повесть булудан бигрәк, көндәлек формасына якынрак килә. Көндәлек документалистикада иң күптәнге калыпларның берсе булып тора. Ләкин озак еллар дәвамында әдәбият белеменең көндәлеккә мөнәсәбәте гадәти мәктәп сочинениесенә мөнәсәбәткә тиң була. Ул әдәби текст буларак кабул ителми.

Әдәби көндәлек гадәти көндәлектән укучы өчен язылуы белән аерылып тора. Көндәлектә “мин” образы үз фикерләрен укучы хөкеменә тапшырырга тели. Г.Исхакый “Зиндан” (1906) повестенда татарларга үзенең сәясәт, иҗтимагый тормыш турындагы фикерләрен җиткерү максаты куя. Әсәрнең хатимә өлеше – көндәлек рәвешендә алып барылган язмаларга нәтиҗә ясау урыны. “Мин” үзенең төрмәдә утыруын, эзәрлекләнүләрен бәян итә һәм, моңа бәйле рәвештә, көчле шәхес концепциясен үткәрә. “Зиндан” повестеның төп герое милләт азатлыгы өчен утка керә һәм сәяси мәхбүс сыйфатында империя читлегенә ябыла”[51]. Автобиографик характердагы бу әсәрнең төп герое, вәхшилек һәм золым корбаны булса да, үз идеалына хыянәт итми һәм нык рухы белән инкыйраз ялчыларыннан өстен чыга. Хатимәдә автор үз идеяләренә тугры булып калуын ачык белдерә, төрмә газаплары аның шәхесен юкка чыгармыйлар, аның уй–теләкләре, кайбер фикерләре төрмәдән чыкканнан соң үзгәреш кичерә. Шул рәвешле, Исхакый милләтне инкыйраздан коткару юлында мөһим шарт булган шәхес азатлыгы мәсьәләсен күтәреп чыга.

Г.Тукайның “Исемдә калганнар” (1909) язмалары – бүгенге автобиографик әдәбиятка якын торган тәүге әсәр. Кагыйдә буларак, бу жанрга язучы олы гомер юлының аерым бер этабында мөрәҗәгать итә. Әсәрнең мөкаддимәсендә Г.Тукай болай ди: “Исемдә калганнар”ны язуыма башлыча сәбәп берничә нәширләрнең миннән тәрҗемәи хәлемне язып бирүгә үтенүләре булды. Мин аларга туганымнан алып хәзерге яшемә кадәрле тәрҗемәи хәлемне кыскача гына рәвештә бирү нияте илә кулыма каләм алган идем, әллә ничек сүз озынга китте”[52].

---

Тат.кит.нәшр., 1986. – Б.34.

[51]Сәхәпов Ә. Исхакый иҗаты. – Казан: Мирас, 1997. – 368 б.

[52] Тукай Г. Исемдә калганнар / Сайланма әсәрләр. Т. 4. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1996.– Б.15.

Автобиографик әсәрнең бер үзенчәлеге – аның сөйләм агышы ике “мин” исеменнән алып барылуы. Авторның үткәне исеменнән яшь “мин” сөйли, кылган гамәлләренә алдан үзе, аннары өлкән “мин” бәя бирә. Шулай итеп, “әсәрдә бәя бирүчеләр икәү: кечкенә Тукай һәм автор – вакыйгаларга да, кечкенә Тукайга да бәя бирүче зур Тукай”[53]. Әдип үткән гомерен хәтерендә яңартып, аны бүгенге белән бәйләнештәербөтен итеп сурәтләргә омтыла. Әсәрнең мөкаддимәсендә олы шагыйрь яшь Апушның “шактый ямьсез, шактый караңгы, шуның белән бергә кызык кына үткән” балачагы турында язачагын искәртә. Алдан ул әсәрне ике өлешкә бүлеп язарга ниятли, әмма, белүебезчә, икенче кисәк гамәлгә ашырылмый кала.

Истәлек характерындагы әсәрләргә хас булганча, Тукай әсәренең беренче бүлегендә үзенең нәсел шәҗәрәсенә игътибар итә, әтисе Мөхәммәтгариф, бабасы Мөхәммәтгалим, аларның Кушлавычка килүләре, шулай ук, әнисе Мәмдүдә, әнисе ягыннан бабасы  Зиннәтулла хәзрәт турында мәгълүмат биреп үтә. Моннан соң яшь Апушның чиктән тыш авыр гомер агышы әсәрдә кырыс чынбарлыкны сурәтләгән манзаралар аша тасвирлана. Ире үлгәч, Мәмдүдә апа күрше авыл мулласына кияүгә чыга һәм улын Шәрифә карчыкка биреп калдыра. Зур Тукай бу чорны хәтерләмәсә дә, авылдагы карчык, хатыннар сөйләвеннән чыгып, әбинең үзенә карата һичбер шәфкать күрсәтмәгәнен искә ала. Шул ук вакытта зур Тукай әбигә карата күңелендә ачу сакламый, киресенчә, аны бәхилләп: “Алла аңа рәхмәт әйтсен”, – дип әйтә. Нинди генә авырлыклар, газаплар күрсә дә, лирик герой зарланмый. Үзенә яхшылык эшләгән кешеләрне ул зурлап искә ала, үзен тәрбияләгәннәргә карата да игелекле: аларга “әти–әни” дип эндәшә. Балачак хатирәләреннән күңелендә сакланган кайбер шатлыклы, күңелле вакыйгалар турында да сүз алып бара. Шундыйлардан, Саснага килгәч, үги әтисенең малайны чәй янында кәрәзле бал яккан ак күмәч белән сыйлавы, Зиннәтулла бабасы йортында Сажидә апасының башкалардан яшереп иркәләве,  Кырлайдагы әтисенең үз баласыдай якын күрүе, андагы Сабан туе бәйрәмнәре һ.б.ны олы Тукай балачагының якты истәлекләре итеп сурәтли. Билгеле, бу санаулы шатлыклы мизгелләр аның күргән газап–михнәтләре янәшәсендә гаять сүрән тоелалар. Моннан шагыйрь тасвирлаган ямьсез тормышының кызыгы килеп чыга да инде. Кеше бу фани дөньяда никадәр күбрәк сыналса, шулкадәр сизгеррәк була, һәр кечкенә шатлыкны олы бәхет итеп кабул итә. Бу – әсәрдә үткәрелә торган фәлсәфи фикер.

Тукай кечкенәдән үк укуга, белемгә омтылышын, бертуктаусыз гыйлем эстәвен ассызыклап яза. “Укуда зур уңышка ирешкән Габдулла

---

[53] Яхин А.Г. 5 сыйныфта татар әдәбиятын укыту. – Казан: Мәгариф, 1996. – Б.101.

“программа” таләп иткән китаплар белән генә чикләнмәгән. Ул чакта китабы юк өй авылда сирәк булган. Коръәннән кала иң күп очрый торганнары – “Бәдәвам”, “Кисекбаш”лар белән бергә, “Йосыф китабы”, “Бүз егет” һәм “Таһир илә Зөһрә кыйссасы”[54]. Уку – аның тагын бер зур шатлыгы. Әсәрдә иҗтимагый мәсьәләләр дә игътибарга алына (Камалетдин хәзрәтнең шәкертләрен бер сәбәпсезгә эт урынына кыйнаганын күргәч, малайда мәдрәсәдәге тәртипләргә каршы ризасызлык хисе уяна). Шул рәвешле, Г.Тукай бүгенге автобиографик әсәргә якын торган “Исемдә калганнар” язмалары белән әдәбият мәйданына яңа жанр алып керә.

1923 елда М.Гафури “Тәрҗемәи хәлем” әсәрен иҗат итә. Бу әсәрне без шулай ук автобиографик жанрга нисбәтләп карыйбыз. Язучы “гомеренең кырык ике басмасын үтеп, кырык өченче басмасына күтәрелгән вакытында, хәятның артта калдырып киткән эзләрен әрчеп, анда утыртылып киткән маякларны яңартып, хәтер дәфтәрендә сызылып килгән тәэссоратларны бер урынга теркәп, пракәндә ятлап, кәгазьләрне бер җиргә җыйнап куярга” ниятли[55]. Әсәрне ике өлешкә бүлеп карарга мөмкин. Бер яктан, ул үз тормышын, шәхес буларак үсеш–үзгәрешен сурәтли, икенче яктан, апасы, туганнары, якыннары образлары аша, халык язмышы турында сүз алып бара. Әсәрдә бирелгән пейзаж – көз вакытының сурәте – халыкның ирек яуларга омтылышына ишарә булып тора. Кошларның ирекле булуларын, “үзләре теләгән якка очуларын күреп кызыгуы” лирик каһарманның халык тормышы өчен борчылуын күрсәтә.

Нәтиҗә ясасак, егерменче гасыр башы татар әдәбиятында документаль жанрның яңа төре – автобиографик жанр барлыкка килә. Без, бүгенгә кадәр бөтен Урта гасыр һәм аннан соңгы чордагы әдәби чыганакларның билгеле булмавын исәпкә алып, жанрның нәкъ шул чорда формалашуын дәлилли алмыйбыз. Хәзергәчә мәгълүм булган әсәрләрдән югарыда санап үтелгәннәре – тәүге автобиографик язмалар.

30 нчы елларда, әдәбият галиме З.Рәмиев сүзләре белән әйткәндә, “фактик яктан зур әһәмияткә ия булган”[56] автобиографик язмалар иҗат итү эше аерым язучылар тарафыннан уңышлы дәвам иттерелә. 1932 елда Н.Думавиның “Тәрҗемәи хәл урынында”, 1934 елда Г.Камалның “Минем персональный пенсионер булуымның тарихы” әсәрләре мәйданга чыга. Шул елларда авыру Г.Ибраһимовның Совет органнары өчен мәҗбүри рәвештә рәсми автобиография язуы билгеле.

---

[54] Нуруллин И. Габдулла Тукай. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1979. – Б.29 .
[55] Гафури М. Тәрҗемәи хәлем / Әсәрләр. 4 томда, IV т. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1981. – Б.352 .
[56] Рәмиев З. Н.Думави үзе турында / Әдәби мирас. I китап. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1991. – Б.73.

Н.Думавиның “Тәрҗемәи хәл урынында” әсәре – илле яшьлек атаның балаларына нисбәтләнгән язмалары. Әдипнең вафаты сәбәпле, әсәр тәмамланмый кала[57]. Автор “12 битле мәктәп укучысы дәфтәре һәм зуррак форматлы рәсем дәфтәре” күләмендәге әлеге язмада җиде–сигез яшьлек чорыннан башлап 1917 елгы инкыйлабка кадәрге тормышындагы үзе иң мөһим санаган вакыйгаларга туктала. Аерым алганда, туган авылы Яңа Думадагы балачак тормышы, анда мәктәпкә йөреп, этисе – мулладан белем алуы, “иман шартын” өйрәнүе, намазга басуы, сабыйчак шуклыклары, “искелекнең иң искесе булган” Кизләү ишаннары мәдрәсәсендә, аннары Казанның Габдулла Апанаев мәдрәсәсендә укып йөрүе, алардагы уку тәртибе һәм башкалар турында мәгълүмат бирә. Әсәр “балаларым өчен” дип билгеләнгән. Әсәрнең керешендә автор ни турында сүз барачагын искәртә: “Мин шул яшемә кадәр башыма, фикер вә уйларыма нәрсәләр килеп киткәнен язмакчы булам. Чөнки мин уйлау, хыяллану, фикер йөргезү эшендә … үземне башкарак күрәм”[58]. Кайбер урыннарда укучыга үзе сайлап алган вакыйгаларның әһәмиятле булуын да ассызыклый: “Монда сезгә әһәмиятле ягын – кай дәрәҗәдә түбән бер фикер башыма килгән, башыма килгән нәрсәләрнең түбән яктагы очын күрсәтүдер”[59].

Әсәрдә, гадәттәгечә, автор образы ике планда гәүдәләнеш ала: кечкенә малай теге яисә бу күренешкә үз фикерләрен белдерә, өлкән әдип шул карашларга бүгенге мөнәсәбәтен ачыклый. Мисал өчен, малайның намазга басуы, дингә мөнәсәбәте тасвирлана. Кечкенә вакытта Алладан куркуы турында язып үтә, соңрак, төрле мәктәпләрдә белем алганнан соң, тормыш барышында дингә карашы үзгәрүен искәртә. Шунда ук, балаларына мөрәҗәгать итеп, сабый чакта Ходайдан куркуының, ләкин алай да балаларына дини сабак бирмәвенең сәбәпләрен ачыклый: “... бу эш миндә зиһен ким булганнан түгел, бәлки зиһенем бигрәк табигый юлда вә камил юнәлгәннән икән... Мин сезгә, бер авыз булсын, дин өйрәтмәдем. Моның өчен бәлки рәнҗемәссез”[60]. Г.Апанаев мәдрәсәсендә күргән ору–сугулар малайда уку дәртен тәмам юкка чыгаралар. Казанга килгәч, Һади Максудидан гарәп телен бик яхшы өйрәнеп, малайда гыйлем эстәү теләге яңадан уяна. Шунда ук әдип һәр мәдрәсәдә нинди фәннәр укыганлыгын әйтеп үтә. Н.Думави үзенең белемен, иҗади мөмкинлекләрен киң дип исәпли. Сигезьеллык мәдрәсәне дүрт елда үзләштерү үз–үзенә ышаныч тудыра, моны ул “татарда сирәк күренеш” дип бәяли[61].

---

[57] Шунда ук. – Б.73.
[58] Думави Н. Тәрҗемәи хәл урынында / Әдәби мирас. I китап. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1991. – Б.74.
[59] Шунда ук. – Б.75 .
[60] Думави Н. Тәрҗемәи хәл урынында. – Б.77.
[61] Шунда ук. – Б.76 .

Язманың калган өлешләрендә Н.Думавиның төрле фәннәргә, дингә, революцион идеяләргә, марксизмга мөнәсәбәте, карашлары ачыклана. Биредә ул укучысы белән бәхәскә керү юлын сайлый. Шул урында әдип фәннәрнең әле бик түбән дәрәҗәдә булуын,үз сүзләре белән әйткәндә, “әлифба укуын” ассызыклый, кешедәге асыл сыйфатлар, аерым алганда, шәхеснең үзбилгеләнүе өчен әһәмиятле “мин–минлек”не югары куя. Шунда ук үзенең кайбер характер сыйфатларын, вакытлар узу белән шәхесендә булган үзгәрешләрне күрсәтә. Шунысы кызык: кайчак ул фикерләренең барышыннан куркып та куя кебек: “Кара инде, мин соң нигә мондый нәрсәләрне язам, боларны бит балаларым укып беләчәкләр[62]. Балаларының ул бирә торган гыйлемне мәктәптә үк алырга мөмкинлекләре турында әйтә, шул аны кайбер әйберләр турында язмаска да мөмкин икән дигән уйларга этәрә.

Н.Думави үз карашларын шактый эзлекле рәвештә, дәлилләр белән тасвирлый. Иң мөһиме, әдип бу карашларның әле соңгы хакыйкать булмавын ассызыклый. Әсәр композицион корылышы, лирик герой һәм автор мөнәсәбәтләре ягыннан автобиографик жанрга якын тора.

Г.Камалның “Минем персональный пенсионер булуымның тарихы” язучы дусларының тәкъдиме белән дөньяга килә. Бу хакта Гомәр Галинең аңлатма язуы бар: “1932 елның җәендә Г.Камал агага берничә язучы һәм бигрәк тә Татгосиздатның матур әдәбият секторында эшләүче иптәшләр тарафыннан менә мондый тәкъдим ясалган иде: “Хәзергәчә чаклы татар совет әдәбиятында мемуар төсендә язылган әсәрләр бөтенләй юк. Әгәр, Галиәсгар ага, син шундый бер эшкә тотынсаң, кыйммәтле бер әсәр бирә алыр идең, – диелгән иде. Галиәсгар Камал бу тәкъдимне бик яхшы каршы алды һәм шул характерда русча язылган кайбер әсәрләр белән дә махсус таныша башлады... Ләкин үзе исән чакта конкрет рәвештә бу эшкә керешү турында ишетергә туры килмәде. Болай да шаянрак табигатьле Галиәсгар ага бу эшне тәмам итеп, аның бу эшен көтеп йөрүчеләрне әзер факт алдында калдырырга теләгән булса кирәк”[63]. Шунда ук Г.Гали бу әсәрне язучының соңгы елларындагы әдәби эшчәнлеген күрсәтү өчен әһәмиятле документ буларак билгеләп үтә.

Язманың кыскача эчтәлеге әдип тормышындагы “һич онытылмый торган вакыйгалардан” гыйбарәт. Шулар арасында пич алдында уйнап утырганда көлмәгенең яна башлавы, яңа фатирга күчү, Масра авылында белем алуы, авыл кешеләре белән мөнәсәбәте, Сабан туе вакыйгалары,

[62] Думави Н. Тәрҗемәи хәл урынында. –Б. 84.
[63] Гали Г. Аңлатма язуы / Г.Камал Әсәрләр. Өч томда. Т. Ш. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1982. – Б.374.

прәннек чәчү һ.б.лар тасвирлана. Өлкән әдип бала чактагы күп вакыйгаларны сагынып искә ала, шул вакытта ук тормыш турында уйлануларын, авылларның тарихы белән кызыксынуын билгеләп үтә. Кешеләрнең кайбер гадәтләрен, аерым алганда ялагайлануын, баерак кеше алдында баш ияргә ячратуларын ирония белән бәяли.

Бу әсәрдән тыш, Г.Камалның Г.Тукай турында истәлекләре билгеле. Биредә автор замандашына тирән хөрмәтен белдерә, аның белән танышу вакыйгасын сурәтләп яза.

Ватан сугышы елларында автобиографик язмаларның аерым бер төре – очерк үсеш кичерә. Гомумән, бу чорда иң актив, әйдәп баручы җанрлар булып, хикәя һәм очерк тора. Аеруча, хәрби заман тормышының кызу агымын тиз арада күрсәтергә мөмкинлек бирү ягыннан реаль сугыш күренешләрен, конкрет вакыйга–геройларны сурәтләгән бу жанрлар укучы өчен әһәмияткә ия иде. “Сугыш эпизодлары, информацион документаль дөреслек һәм романтик күтәренкелек, геройларның диалоглары белән автор монологларының үзара аралашуы, керешүе проза жанрларының үзенчәлекле синтезына китерде”[64]. Истәлек характерындагы әсәрләрдән, авторның уйланулары үзе катнашкан сугыш вакыйгалары турындагы көндәлекләр, язмалар аеруча күп языла. Аерым алганда, Г.Әпсәләмовның “Көндәлек дәфтәреннән”, Ш.Мөдәррикнең “Кайнар көннәр”, Ш.Маннурның “Журналист блокнотыннан”, сугышка кадәр техник булып эшләгән Җ.Х.Хәбибуллинның “Белоруссия урманнарында” истәлекләрен билгеләп үтәргә мөмкин. Гомумән, бу чорда күп хикәяләр үзләренең конкретлыклары белән очеркка якын торалар. Г.Бәширов, А.Шамов, И.Гази, А.Әхмәт хикәяләренең жанрын күп вакытта тәгаен билгеләү дә мөмкин түгел. Хәрби очеркларның эчтәлеге сугыш чорының типик үзенчәлекләрен чагылдыралар. Язучы сайлаган кешеләр үз чорының иң характерлы типик күренешләре белән конкрет гәүдәләнеш ала. А.Шамовның “Снайпер сүзе”, “Җыр тавышы”, “Нәфрәт көче”, “Ике дус”, А.Әхмәтнең “Онытма син аны!”, “Күзәтүче Мостафа”, “Өч егет”, Г.Насрыйның “Минометчы Нуретдин”, “Үлем күпере”, “Зарыгып көтелгән минутлар”, Х.Госманның “Гвардия егете”, “Ярсу”. Ш.Маннурның “Мәхәббәт атавында”, И.Газиның “Тупчы егет”, Г.Иделленең “Ерткыч эзе буйлап”, “Парторг Мотыйгуллин”, Г.Әпсәләмовның “Хәнҗәр” һ.б. авторларның очерклары автобиографик характерда булулары белән игътибарга лаек.

Йомгаклап шуны билгеләп үтәргә кирәк: XX йөз башында шәрык рус әдәбияты йогынтысын тоеп формалашкан автобиографик жанр

гасырның беренче яртысында беркадәр үсеш кичерә, ләкин әдәбият мәйданында киң колач җәя дип әйтеп булмый. Моның сәбәпләрен төрлечә аңлатырга мөмкин. Беренчедән, жанр үсеше өчен тиешле иҗтимагый–сәяси җирлек булу кирәк. Язучылар теге яисә бу вакыйгага мөнәсәбәттә шәхси фикерләрен ачыктан–ачык белдерү өчен публицистик стильгә мөрәҗәгать итәләр, халыкка үз сүзләрен матбугат битләре аша җиткерәләр. Икенчедән, XX гасыр башы классикларының күпчелеге яшьли вафат була, алар шул сәбәпле үзләре турында истәлек язарга өлгерми калалар, чөнки, кагыйдә буларак, мемуар жанрга мөгътәбәр яшьтәге өлкән язучы мөрәҗәгать итә. Ахыр килеп, жанр язучылар арасында киң таралмаган, үсеш кичермәгән, шуңа бәйле рәвештә, күпчелек әдипләр үзләренең тормыш юлын аерым әсәр итеп формалаштыруны мөһим дип санамыйлар булса кирәк.

[64] Гыйззәтуллин Н. Проза / Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.V. – Казан:Тат.кит.нәшр., 1989. –

## XX гасырның 60–70 нче еллар татар прозасында автобиографик жанр үсеше

Үткән гасырның 60–70 нче еллар әдәбиятында документаль прозаның үсеш алуы Ватан сугышыннан соң илдәге катлаулы вакыйгалар белән бәйле. 1941–1945 еллардагы сугышта җиңгәннән соң, 1937–1938 елгы фаҗига – Сталин репрессияләре – янәдән колач җәя. Төрмә–лагерь газапларын кичергән, Аурапа илләрендәге тормыш–көнкүрешне үз күзләре белән күргән кичәге солдат илнең яшерен сәясәте барлыгын аңлый. "Рәсми хакыйкать янында яшерен рәвештә кешеләр аңында чын хакыйкать яши башлый"[65].

60 нчы елларга кадәрге әдәбиятта билгеле сәяси сәбәпләр аркасында чын хакыйкать яктыртылмый. Әдәбиятның төп темасы булып, Ватан сугышы фаҗигасе тора. 1945 елдан соң хәрби – документаль материалларга нигезләнгән әсәрләр иҗат итүгә аерым игътибар бирелә.

Рус әдәбиятында Б.Полевойның "Чын кеше турында повесть", А.Бекның "Волоколамск шоссесы" әсәрләре, татар әдәбиятында Г.Әпсәләмовның "Ак төннәр" повесте, "Алтын йолдыз", "Газинур" романнары, А.Шамовның "Агач башмаклы кыз", М.Әмирнең "Якташ", Ф.Хөснинең "Берәү һәм без", А.Расихның "Бәхет орлыклары" хикәяләре, Г.Гобәйнең "Замана балалары", Г.Бакирның "Партизан малай" повестьлары, Ш.Маннурның "Казан кызы", С.Хәкимнең "Дала жыры", Т.Гыйззәтнең "Изге амәнәт", М.Әмирнең "Тормыш жыры", Н.Исәнбәтнең "Муса" һ.б. әсәрләр шундыйлардан. Сугыш батырларын әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрү бу чорның аерым идеологик ихтыяҗларга барып тоташа.

А.Моруа: "Портретист һәм пейзажист кебек, биограф бөтен материалдан сурәтләү өчен иң мөһимен сайлап ала белергә тиеш"[66],– дип күрсәтә. И.Янская, В.Кардин истәлекләр жанры турында: "Жанр слишком

---

Б.109.

[65]Яхин А.Г. Хакыйкать тудырган фажига / Әдәбият. 11 сыйныф өчен дәреслек–хрестоматия.– Б. 56 .

[66] Моруа А.О биографии, как о художественном произведении / Писатели Франции о литературе. Сборник статей. – М.: Прогресс, 1978. – С. 125.

субъективен, слишком зависим от текущего литературного процесса”[67], – дип белдерделәр. Батырлык фәлсәфәсен тулы яктырту максатында татар язучылары биографик материалны сәнгатьчә югары дәрәҗәдә үзләштерергә омтылдылар. Сугыш батыры Г.Гафиятуллин язмышы Г.Әпсәләмовның “Газинур”(1951) романында, каһарман шагыйрь М.Җәлилнең һәм аның дусларыннан тиңдәшсез батырлыгы Н.Исәнбәтнең “Муса”(1957), Р.Ишморатның “Үлмәс җыр” (1955) драмаларында, Ш.Маннурның “Муса” (1959–1964) романында, моннан тыш, Ш.Мөдәррис, Г.Хужи, Ә.Давыдов, Н.Арсланов поэмаларында гәүдәләнә. Шулай итеп, Ватан сугышына багышланган әдәбиятта документ, тарихи факт, биографиянең әһәмияте арта бара, документаль юнәлеш көчәйгәннән–көчәя.

Моннан соңгы еллар татар әдәбияты халыкның үткәнен, инкыйлаб, милли азатлык өчен көрәшне чагылдырган һәм шуңа бәйләп көрәшчеләрнең тормыш юлын яктырткан әсәрләр белән баеды. И.Газиның “Онытылмас еллар” трилогиясе, К.Нәҗминең “Язгы җилләр” романы һәм Ә.Фәйзинең “Тукай” исемле биографик романы бу төр әсәрләр арасында иң күренеклеләрдән исәпләнә, иҗади тарихлары сугышка кадәрге елларга барып тоташа. “Аларның авторлары озак вакытлар буенча күпләгән документаль һәм фактик материал туплап киләләр, әсәрләрнең төп проблемаларын һәм геройларын ачыклыйлар. Ләкин әле утызынчы еллар ахырында әсәрләрен тәмамлау өчен, бер яктан, алар өйрәнә торган чорның фәнни тарихы ныклап эшләнеп житмәгән булуы, икенче яктан, татар прозасында эпик жанрларның поэтикасы ачыкланмаганлыгы да комаучалый иде. Ватан сугышы елларында исә бөтенләй башка шартлар һәм таләпләр иде. Сугыш афәтләре артта калып, тыныч төзелеш чорына күчкәч кенә, зур әсәрләргә тотыну мөмкинлеге туа. Нәкъ шул чорда, гомумән, татар халкының тарихы һәм бигрәк тә аның революцион көрәш тарихы ныклап өйрәнелә башлый; татар әдәбиятының Тукай кебек вәкилләренең күп томлык әсәрләре фәнни нигездә төзелеп чыгарыла; әдәбият галимнәре тарафыннан тормыш һәм иҗат юллары турында яңа хезмәтләр языла”[68],– дип аңлата бу күренешнең барлыкка килү шартларын әдәбият тарихы галиме Н.Гыйззәтуллин.

Язучы Ф.Хөсни “Бер мәсьәлә тирәсендә” мәкаләсендә документаль юнәлешнең үсешен “бик вакытлы күренеш” дип билгели һәм аның сәбәпләрен түбәндәгечә аңлата: “Беренчедән, буыннар белән буыннар

---

[67] И.Янская, В.Кардин. Объективные и субъективное в мемуарах / Пределы достоверности.– М., 1986. – Ñ. 377.

[68] Гыйззәтуллин Н. Проза. – 315–316 б.

арасындагы багланышның тоташа баруы, бүгенге буынның яшәп киткән буыннар тәҗрибәсеннән үрнәк алырлык якларны үзенә күчерергә омтылышы гәүдәләнә монда. Икенчедән,... берәүдән дә яшерен түгел, берара аерым язучылар тарафыннан халыкка хезмәт дигән төшенчәне үтә дә шәрәләндереп аңлап, ялган пафоска, риторикага авышу фактлары да булмады түгел. Бу факт укучыларда яки аларның бер өлешендә әдәбияттан беркадәр суынуы, аңа ышанып житмичәрәк карауны китереп чыгарды. Шуның антитезасы рәвешендә укучы документаль материалга нигезләнеп язылган әдәбиятка ташланды. Хәрби полководецларның зур тиражлар белән чыгарылган мемуарларының тиз арада таралып бетүе шуны күрсәтә торган фактларның берсе түгелме соң! Аерым алганда, безнең татар әдәбиятында Гани Сафиуллин, Фатих Булатов кебек генералларның публицистик әсәрләре дә шундый ук бәхетле язмышка тап булды, дисәк тә хата түгел. Өченчедән, ә бусы иң әһәмиятлесе булса кирәк, халык үзенең тарихка эз салып киткән улларын онытырга теләми, аларны һәрдаим барлап тора һәм киләчәктә дә барлап торыр”[69].

Бу елларда әдипләр үз әсәрләрендә тормыш фажигасенә әверелгән хакыйкать темасын ачуны да максат итеп куялар. Рус әдәбиятында шәхес культы фаҗигасе Е.С.Гинзбургның “Текә маршрут”, А.И.Солженицинның “Иван Денисовичның бер көне”, “Гулаг архипелагы”, А.Рыбаковның “Арбат балалары”, А.Кестлерның “Сукырайткыч караңгылык”, В.Шаламовның “Колыма хикәяләре” һ.б. әсәрләрдә гәүдәләндерелде.

Афәтне үз башларыннан кичергән Х.Туфан, И.Салахов кебек язучылар фаҗигане бөтен тулылыгында яктыртырга омтылыш ясыйлар. Исәпсез–хисапсыз шәхес культы корбаннары арасында әлеге ике язучы–исән калган бик сирәк аксакалларыбыздан. Алар үзләре яшәгән заманны аңлап, үз күзләре белән күргән вакыйгаларга гадел бәя бирергә тырышалар. Х.Туфан поэзиясе, И.Салаховның “Колыма хикәяләре” роман–хроникасы шәхес һәм ил фаҗигасен гаять эчтәлекле, документаль төгәллек белән тасвирлауга омтылыш булып тора. Ә.Сәхәпов хаклы рәвештә “Тайгак кичү” әсәрен реалистик рухы белән Х.Туфанның лагерьда әрнеп язган шигырьләренә аваздаш, дип билгеләрде[70]. Әйтергә кирәк, шәхес культы елларындагы гаделсезлекне И.Салахов үзенең “Күкчәтау далаларында” романында (1965) ук күтәрә. Төп герой – Сәет Батталовның прототибы – язучы үзе. Билгеле, 60 нчы елларда ук әдип шәхси кичерешләрен бөтен тулылыгында яктырта алмый, шулай да хакыйкатьне өлешчә чагылдыруга ирешә. 1956 елның көзендә, акланганнан соң, И.Салахов “тәрәзә капкачларын ябып, пәрдәне төшереп,

[69] Хәсни Ф. “Бер мәсьәлә тирәсендә / Карурманга керәм. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1985. – Б.175.

ишекне бикләп", "Тайгак кичү" әсәрен яза башлый: "Үзем язам, үзем берәрсе сагалап йөрмиме, дип колак салам"[71]. 1957–1981 елларда иҗат ителгән "Колыма хикәяләре" ("Тайгак кичү" – беренче исеме) әсәрен язучы фаҗига–хроника дип күрсәтә. "Хроника дип күргән–белгәнне, ишеткәнне бер тәртипкә китереп язылган мәкаләгә әйтәләр. Хроникада автор пассив сурәтләүче, читтән күзәтеп торучы кеше"[72].

Әсәрнең фаҗига өлеше – хакыйкать буларак билгеләнә. А.Яхин фикеренчә, романда өч төрле фаҗига сурәтләнә:

"1.Хакыйкатькә ирешү шәхес фаҗигасенә әверелә.

2. Бер гаепсез кешеләрнең көн дә исән калу өчен тырышуы һәм меңәрләп, миллионлап үтерелүе–халык фаҗигасе (социаль фаҗига).

3. Ил фаҗигасе (сәяси фаҗига). Күпме генә интектермәсеннәр, асыл ирләр тоткында да асыл булып калалар"[73].

И.Сәлаховның бу әсәре автобиографик материалга нигезләнгән. Язучының төп максаты – күргән–ишеткәнне яисә хакыйкатьне ачып бирү, дөресрәге, үзенең аны аңлауга килү юлын күрсәтү. Автобиографик әсәр шәхеснең үсеш юлын, дөньяга карашлары формалашуны, ягъни эволюциясен күзәтүне максат итеп куя. Бу мотив И. Салахов әсәрендә чагылыш таба. Шулай да аның төп максаты – үз шәхесе тирәсендә эзләнүләре дип билгеләү дөрес түгел. Язучы бер үк вакытта хаклы да, хаксыз да булган кешеләрнең фажигасен тасвирлауны, ягъни хакыйкать проблемасын ачуны күздә тота. Гомумән, язучы үзе алдында торган бурычның бөтен җаваплылыгын тоеп эш итә: "... ул – синең язмышың гына түгел, ә меңләгән, йөз меңләгән хаксыз һәлак булган фидакарьләрнең фаҗигасе"[74]. Г.Ахунов хаклы рәвештә бу әсәрне И.Сәлахов тарафыннан шәхес культы корбаннарына куелган һәйкәл, дип белдерде[75].

"Колыма хикәяләре" жанры турында әдәбият белгечләре тарафыннан шактый кызыклы фикерләр әйтелде. А.Гыйләҗев әсәр "формасы белән дә, эчтәлеге белән дә моңарчы без белгән әдәби калыпларга сыймый, аңа үзгә бәя, яңа үлчәү кирәк", – дип күрсәтте[76]. Г.Ахунов әсәрне документаль жанрдагы повесть дип билгеләсә, Ф.Миңнуллин "повесть–истәлек" дип төгәлләштерүне кирәк таба[77]. И.Салахов үз әсәрен роман жанрына нисбәтләп карый һәм югарыда

---

[70] Сәхәпов Ә. Алтын тамырлар. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1990. – Б.116 .
[71] Сәлахов И. Киләчәк буыннар белсен // Соц.Татарстан. – 1988. – 4 декабрь.
[72] Яхин А. Әдәбият. 11 сыйныф өчен дәреслек–хрестоматия. – Б.87.
[73] Шунда ук. – Б.98 .
[74] Сәлахов И. Күрсәтелгән хезмәт.
[75] Ахунов Г. Язмыштан узмыш // Соц.Татарстан. – 1991. – 9 сентябрь.
[76] Гыйләҗев А. Җан авазы. Кереш мәкалә. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1988. – 5 б.
[77] Ахунов Г. Язмыштан узмыш // Соц.Татарстан. – 1991. – 9 сентябрь; Миңнуллин Ф. Затлылык. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1989. – 75 б.

күрсәтелгәнчә, китап вариантында фаҗига–хроника дип бирә[78]. Бу әсәрне автобиографик жанрдагы роман итеп билгеләү беркадәр кыенлык тудыра. И.Салаховның “Колыма хикәяләре” әсәре, һичшиксез шул чорның иң күренекле документаль әсәрләре рәтендә тора. Л.Минһаҗева язучы иҗатына багышланган монографиясендә “Колыма хикәяләре”н татар әдәбиятында шәхес культы елларын “ачык текст” белән яктырткан беренче әсәр, дип күрсәтте[79].

60 нчы елларда ил сәясәтендә, шуның белән беррәттән әдәбият мәйданындагы үзгәрешләрнең күпчелеге И.Сталинның үлеме белән бәйле. Шәхес культы тиешле бәясен алганнан соң, сәяси тоткыннарның күбесе гаепсез дип табыла. Шуңа карамастан рәсми хакыйкатьтә җитди үзгәрешләр күзәтелми. Илнең зыялылары, фән эшлеклеләре, үз хезмәтләрен намуслы башкаручы зур төркем кешеләр ямьсез юллар белән эзәрлекләнә. Чор сәясәте ифрат каршылыклы, бер яктан, кичәге тоткыннар чын хакыйкатьне ачу мөмкинлеге алалар, бу максатка бөтен көчләрен, егәрләрен багышлыйлар. Икенче яктан, идеологиягә каршы чыгучы һәркем төрле ысуллар белән халыктан читләштерелә, юк ителә.

60–70 нче еллар әдәбиятында хаклык, хакыйкать темасының иң актуаль тема булып торуы очраклы түгел. “Хаклыкны ачыктан–ачык сөйләргә ярамаган бу елларда да әдипләр үз сүзләрен әйтергә жаен таптылар. Идеологиягә каршы чыгу булмаса да, аны кабатлаудан качу юлларының берсе–үткән заман вакыйгаларын язу иде”[80]. Әлеге шартлар язучыларның документаль жанрга мөрәҗәгать итүләренә сәбәпче булды. Мисалга, Э.Касыймовның “Гомер ике килми” (1962–1963), М.Хәсәновның “Язгы аҗаган”, Г.Ахуновның “Идел кызы”, В.Нуруллинның “Шинельсез солдатлар” (1964–1966), Ә.Баяновның “Яшьлегемне эзлим” (1968), М.Мәһдиевнең “Без – кырык беренче ел балалары” (1968) – ярым документаль характердагы әсәрләр.

60 нчы еллардан башлап бүгенгәчә бу төр әдәбиятның автобиографик дип исемләнгән төре аерым үсеш ала. Язучыларның үз алларында куйган максатларын Ф.Мусин һәм М.Әмир түбәндәгечә аңлаталар: “Әсәрдә ике максат тормышка ашырыла: бер яктан, автор балачакта кичергәннәренең табигый рәвештә күрсәтелүенә ирешә, икенче яктан, әдип әсәрдә сөйләгәннәргә бүгенге көн тәҗрибәсеннән чыгып бәя бирә”[81].

---

78 Сәлахов И. “Колыма хикәяләре” турында // Соц.Татарстан. – 1989. – 27 август.
79 Минһаҗева Л. И.Салахов (тормышы һәм эшчәнлеге). – Казан: Матбугат йорты нәшрияты, 1999. – 72 б.
80 Яхин А.Г. Әдәбият. 11 сыйныф өчен дәреслек–хрестоматия. – Б. 98.
81 Мусин Ф., Әмир М. Чор белән аваздаш / Әдәбият фәне һәм тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1983. – Б.216 .

Татар әдәбиятында жанр буларак XX гасыр башында формалаша башлаган автобиографик әсәр үрнәкләре булып нигездә өйрәнелгән чорда иҗат ителгән Фатих Хөснинең “Минем тәрәзәләрем” (1962–1964), Ибраһим Газиның “Малайлыкта кунакта” (1966), Гомәр Бәшировның “Туган ягым–яшел бишек” (1965–1968), Рафаил Төхфәтуллинның “Җиләкле аланнар” (1969), Салих Батталның “Баштан үткәннәр” (1972), Шәйхи Маннурның “Агымсуларга карап” (1970–1973), Мирсәй Әмирнең “Без бәләкәй чакларда”, “Үсә төшкәч”, “Казан” (1978–1979), Ә.Еникинең “Соңгы китап” (1981) әсәрләре торалар. Биредә искә алынган һәр әсәрдә язучы үзенең тормыш юлын, шәхес буларак формалашуын халыкның шул чор язмышына бәйләп тасвирлый. Гомумән, XX йөз ахырында татар язучылары яшәешнең төп кануннарын аңлау, гасырның хәлиткеч вакыйгаларында аерым шәхеснең урынын билгеләү максатында автобиографик материалларга даими мөрәҗәгать итәләр.

Әдәбият теориясендә бу жанрның үзенчәлекләре, аны башкалардан аерып торучы билгеләр әле тулысынча яктыртылмаган. А.А.Ахматова мемуарларны “непроявленный жанр” дип атады. Н.Шайтанов, аның фикерен куәтләп, “ускользающий жанр” [82] итеп күрсәтте. И.Л.Фейнберг автобиографик язмаларның өч поэтик үзенчәлеген ачыклады. Беренчедән, автобиграфик язмалар “мин”нең эчке һәм тышкы дөньясын бөтен нечкәлекләре белән тасвирлауны күздә тоталар, икенчедән, әлеге язмаларда автор үзенең сәяси, фәлсәфи, тарихи, көнкүреш мәсьәләләренә карата фикерләрен бәян итә һәм әле формалашып кына килүче тормыш позициясен башка персонажларының фикерләве, тормышка карашлары белән турыдан–туры бәйләнештә бирә. Ләкин автобиографик язмалар ачыктан–ачык бәхәс, полемика рәвешендә була алмыйлар. Язучының максаты – үзе яшәгән яисә яши торган чорның, күргән–белгән кешеләренең, вакыйгаларның төсле манзарасын тәкъдим итү булып тора. Өченчедән, автобиографик язмаларның структурасы персонажларның үзара әңгәмәләреннән фрагментларга һәм язучы тормышында очраган шәхесләр һәм сюжетларга корылырга тиеш[83].

Биредә күрсәтелгән үзлекләр тулысы белән татар автобиографик әсәренә туры киләләр. Язучылар тормышка шәхси позицияләрен яктырту өчен иң кулай тема – балачак темасын сайлыйлар. Әдип күзлеге аша ике төрле мөнәсәбәт үткәрелә: иң элек кечкенә герой үз гамәлләренә, аннары автор–өлкән “мин” кечкенә “мин”гә, ул катнашкан вакыйгаларга бәя бирә. Икенче яктан, ул үзе яшәгән чорның “төсле манзарасын” күрсәтүгә ирешә,

[82] Шайтанов Н. “Непроявленный” жанр или литературные заметки о мемуарной форме // Вопросы литературы. – 1979. – № 2. – С. 53–54.
[83] Фейнберг И.Л. Читая литературу Пушкина. – М., 1985. – С. 98.

шуңа бәйләп фәлсәфи, сәяси һ.б. рухтагы фикерләрен укучыга җиткерә. Шәхесне бөтен тулылыгында күз алдына китерү өчен, аның балалык чоры, үсмер еллары, нинди шартларда тәрбияләнүен белү әһәмияткә ия.

Әдәбиятта психологизм кешенең кечкенә вакыттагы үсеше тирәсендәге уйланулар, эзләнүләрдән башланып китә. Билгеле һәр автобиографик әсәрдә балачак бөтен тулылыгында яктыртыла дип әйтү дөрес түгел. Мисал өчен, Г.Исхакыйның “Зиндан” повестенда башка иҗтимагый максатлар күздә тотыла. Аурупа әдәбиятында әлеге тема документалистикага беллетристика аша килеп керсә, рус әдәбиятында исә документалистика белән беллетристика янәшә туа. Мисалга, Л. Толстойның “Балачак”, “Үсмерчак”, “Яшьлек” трилогиясен, М.Горькийның шулай ук өч кисәктән торган “Балачак”, “Малайлыкта”, “Минем университетларым” әсәрен күрсәтергә мөмкин. Татар әдәбиятында охшаш күренеш: әдәбиятка балачак темасын Тукай “Исемдә калганнар” дип аталган автобиографик язмалары белән алып керә.

60–70 нче еллардагы автобиографик әдәбиятта балачак – кеше тормышының иң мөһим этабы буларак сурәтләнә башлый. Шәхес язмышын тасвирлаганда, теге яисә бу сорауларга җавап табу өчен, иң элек аның балачагына мөрәҗәгать итү кызыклы һәм дөрес табыла. Ә.Еники үзенең “Соңгы китап” дигән истәлекләренә кыска гына керештә болай ди : “Уналты яшемә чаклы мин туган–үскән җиремдә, атам–анам канаты астында яшәдем. Менә шушы чорым мине кызыксындыра һәм тарта. Бу минем гөнаһсыз, саф чагым. Сүз дә әнә шул бик кадерле, бик кыска, әмма ни хикмәттер, шактый озын булып тоелган балачак турында барачак. Үзем турында да, мине чорнаган тормыш һәм кешеләр турында да мин бары чын дөресен генә язарга тырышачкмын. Бу исә бик озынга сузылган, әмма үтеп киткәне сизелми дә калган гомернең дәвамын аңларга да ярдәм итәр дип ышанам”[84]. Рус язучысы В.С.Печеринның фикере дә кызыклы: “Менә кайда минем тормышымның үзәге! Менә язмышымның серләре. Менә грек трагедиясе!”[85] – ди ул балачагында күргән газап–михнәтләрне күзәтеп.

Без игътибар иткән һәр автобиографик әсәрдә балачак темасы аерым гәүдәләнеш ала. Язучы үзенең психологик эволюциясен күзәтүне бала вакыттагы күңел кичерешләреннән башлый, кайчак башка чорга игътибар бирүне кирәк санамый. Г.Бәширов, Ә.Еники., И.Гази әсәрләренең нигезен бары кечкенә вакыттагы һәм үсмер чордагы күргән–ишеткәннәре тәшкил итә. Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” әсәрендә әдипнең

[84] Еники Ә. Соңгы китап. – Б.5.
[85] Печерин В.С. Замогильные записки. Русское общество 30–х годов XIX в.в. Люди и идеи. Мемуары революционеров, 1989. – С. 150–151.

балачагы турындагы хатирәләре тасвирлана. Бу повестьның нигез өлеше – документаль фактларга корылган информация өлеше. Монда авыл тормышы, татар халкының милли гореф–гадәтләре, гыйбрәтле язмышлы кешеләре һ.б.ны кертергә мөмкин. Һәр вакыйгага карата, автор күңелендә сакланып калган бала вакыттагы һәм олыгайгач шуларны искә алып туган хисләре бәян ителә. Димәк, автобиографик әсәрдә хис һәм фәлсәфә катламнарын аерып карарга мөмкин[86].

Автор әсәрдә гаиләсенә һәм халык язмышына бәйле хисләрен тасвирлый. Бу хисләр картинасы шактый төрле төсмерләрдә күзаллана. Гомумән, М.Җәләлиева фикеренчә, Г.Бәширов “халык тормышын, халык хисләрен һәм теләкләрен бик тирәннән алып сурәтли”[87].

Балачагында иң тирән эз калдырган вакыйгалар халыкның авыр тормышы белән бәйле. Кечкенә малай һәм өлкән кеше күңелендәге хәсрәт хисе даими хис булып тора, әсәрнең башыннан ахырынача дәвамлылыкта тасвирлана. Әтисе Бәшир аганың гомере буе армый–талмый хезмәт итүе, талканы коры булса да, гаделлек, игелеклелек, кешелеклелек сыйфатларына ия булуы өлкән язучыда соклану катыш моңсу хисләр уята. Илнең асыл ир заты гомерен хәерчелектә үткәрергә мәҗбүр. Кечкенә Гумәр хәсрәтенең төп сәбәбе әтисенең даими хәсрәте, борчуы. Гумәрнең бертуктаусыз “әтинең күңеле булсын өчен” нидер эшләве, “әтисенең ачудан ярсыган усал чыраен күз алдына китерүе”, аның алдында “җебегән, уңмаган малай” булырга теләмәве, бер яктан, өлкән язучыда атасына карата саклаган хөрмәтне күрсәтсә, икенче яктан, әтисе язмышы аша тасвирлаган халык язмышы өчен хәсрәт хисенең дәрәҗәсен билгели.

Повестьта Бәшир ага чын җир кешесе образы буларак тасвирлана. Бу хакта түбәндәге өзектә аеруча ачык белдерелә: “Җир өстенә барып җиткәч, әти, уртага кереп, бер йомарлам туфрак казып алды да аның җылылыгын чамаларга кереште. Ул аны әле бер кулында, әле икенчесендә кысып карады, аннары, җиңен сызганып беләгенә куйды, борынына якын китереп иснәп алды. Ул туфракны шундый ипләп, күзләрен йома төшеп, шундый ихлас күңел белән тәмле итеп иснәде, аның бераз җылымсарак төче исе хәтта минем борыныма да килеп кергәндәй тойдым. Әмма әти моның белән генә канәгать түгел кебек иде. Менә ул як–ягына каранды. Нинди нияте барын шунда ук абайладым. Бүтән елларны ул җирнең чәчәрлек булып җылынганмы, түгелме икәнлеген җиргә утырып карап чамалый торган иде. Әмма бу юлы якын тирәдә кешеләр күп булганлыктан, алай итәргә кыймады булса кирәк. Җир өстенә чүгәләгән

---

[86]Яхин А. 11 сыйныфта татар әдәбиятын укыту. – Б.54.
[87] Җәләлиева М. Гомәр Бәширов. – Казан: Тат.кит.нәшр, 1959. – Б.97 .

килеш, кулындагы туфракны бер болай, бер тегеләй китереп, “бүреге белән” киңәшергә тотынды”[88].

Хезмәт иткән, үз эшен намуслы башкарган адәми зат иртәгәге көннең бүгенгедән яктырак, бәхетлерәк булуына ышана, шул өмет белән яши. Бәшир кебек меңәрләгән жир кешеләренең яшәү мәгънәсе шуңардан гыйбарәт. Тик бәхетле булу турындагы өмет бары хыял булып кала килә. Әсәр башындагы колын вакыйгасы кечкенә малайның “бәхетен чын күңелдән зур булганчы көтүе”(7), ягъни шуның турында өметләнүе хакында. Гомумиләштерсәк, әсәрнең үзәгендә халыкның бәхетле булуга, гаделлек, игелеклелекнең явызлыктан өстен чыгуына өмете ята. Бу фикер әсәрдә кат–кат кабатланып килә. Мисал өчен, язучы халыкның ныклы ышанычы дин булуын берничә мәртәбә ассызыклап үтә. Мөхәммәтҗан белән Бәшир әңгәмәсе:

– Иске мәдрәсәдә унар–унбишәр ел чүбек чәйнәү әрәм гомер түгелме?

– Юк, аннан кеше гыйлем булып чыга. Намаз–нияз укырга өйрәнә. Аның, ичмаса, өмете була. Кем белә, бәлки ахирәттә ким–хур булмас?! (132)

Халык язмышы ил идарәсенә бәйләп тасвирлана. Өлкән язучы кечкенә малайның моны аңлау дәрәҗәсенә килүен күзәтә. Әсәрнең башыннан ахырынача фикер масштабы үсештә тасвирлана: Сабантуйга кияр өчен яңа түбәтәе булмауга борчылуы, һәрдаим үзенең “иманасыз” икәнлегенә кимсенүе, “тезе, оегы, бишмәте ямаулы” картларны кызгануы, әле иген–таруларның уңмавына, әле терлек үләте килүенә борчылу, милләтләргә карата гаделсезлекне күреп хәсрәтләнүе, халыкның сугышка нәфрәттән туган ачуын авыру Фазулладан алырга тырышуын, ачлыктан ярсуын күреп кайгыруы.

Даими хәсрәт кечкенә Гомәрне яшьтән үк олыгайта. Гомәр Бәширов балачагында кичергән хәсрәтне сагынмый. Колын символы кешенең бәхеткә өмете мәгънәсендә кулланыла. Колынны югалту – нәни Гомәрнең иң зур хәсрәте. Бу турыда ул кат–кат әйтә: “Без туктаган урыннан мал–туар базары башланып китә. Ат базары үзе генә дә бер урамны тутырган. Шул якка күзем төшүгә, аягүрә бастым. Безнең җирән кашканы да алып килмәделәрме икән? Ул хәзер кырыкмыш булгандыр инде. Бер генә күрәсе иде, бер генә... Ни төсле булды микән? Җирәнме, әллә кызыл турымы? Таныр идеме икән?... Алай дисәң, нишләп сатарга алып килсеннәр аны?”(32) “Мине иң кызыксындырганнары колыннар иде.

[88] Бәширов Г.Б. Туган ягым–яшел бишек / И язмыш,язмыш. ‑ Казан: Тат.кит.нәшр.,1990. – Б.98. (Алда җәя эчендә бит саннары күрсәтелә барачак)

Алар, аналары җир башыннан борылып киткәндә, башларын иеп, йокымсырып калалар. Бераздан, аналары ерагая төшкәч: “Нишләп мине калдырып китәсең?” дигән сыман, үпкәләп кешни–кешни, шөлдерләрен чыңлатып, чабарга тотынлар. Үзебезнең теге, базардан әйләнеп кайтмаган җирән колын күз алдына килде. Бездә үссә, ул хәзер нинди булыр иде икән?”(102)

Бу метафора–вакыйга – халыкның күптән югалткан иреген, байлыгын, мал–мөлкәтен кире кайтару өметенә ишарә. Әсәрдә көрәш вакыйгасы кертелү бер яктан, өметләрнең беркадәр акланырга тиешлелеген күрсәтсә, икенче яктан, өлкән язучы, 60 еллар чигендә торып, әлеге көрәшнең мәгънәсезлегенә басым ясый. Язучы, үзе дә сизмәстән, сәясәткә бәя бирә, фәлсәфи фикерләрен җиткерә.

Шул рәвешле, истәлекләр авторы  ике планда күз алдына килеп баса. Бер яктан, ул – сурәтләнә торган вакыйгаларда катнашучы герой, икенче яктан, ул сөйләүче, вакыйгаларны шәрехләүче һәм бәяләүче. Башкача әйткәндә, бер үк вакытта автор хикәя ителә торган вакыйгаларның объекты һәм субъекты булып тора.

Автобиографик әсәрдә ике чорны бер үремтәдә тасвирлау очраклы хәл түгел. Язучы үткәнен хәзерге фикерләвенә, чынбарлыкны кабул итүенә нигезләнеп бәяли. Г.Бәширов үткәнгә мөмкин кадәр объектив якын килә, бу исә язучының бүгенгесен төгәлрәк аңларга ярдәм итә. Билгеләп үтелгәнчә, язучы өчен яшь Гумәрнең фикер үсешен, үзгәрешен күзәтү аеруча әһәмияткә ия. Әдип автобиографик әсәрдә, “мин”–геройның кичерешләрен бөтен тулылыгында тасвирлау өчен, төрледән–төрле фактлар, язмышлар  файдалана.

Ф.Хөснинең “Минем тәрәзәләрем” повестенда да алда билгеләп үтелгән жанр үзенчәлекләре күзәтелә. Автобиографик әсәр традицион кереш сүз белән башланып китә: “Әдәбият фәне белән шөгыльләнүче иптәшләремнең берсе көннәрдән беркөнне әйтте миңа:

– Син агай–эне, тормыш юлыңны язып кара әле, берәр нәрсә килеп чыкмасмы, – диде” [89].

Әлеге монолог–әңгәмә –  ике якын кешенең үзара аралашуы язучыда төрле хисләр уятуга сәбәпче була. Беренчедән, ул бу тәкъдимне каләмдәшләренең аңа ышанычы кимү дип кабул итсә, икенчедән, истәлекле сәхифәләргә яңадан әйләнеп кайту аңарда, иҗат кешесе буларак, кызыксыну тудыра. Үткән, бүгенге һәм киләчәк повестьның башында ук бер яссылыкта бирелә. Шулай итеп, автобиографик әсәрдә үзенчәлекле вакыт төшенчәсе барлыкка килә. Вакыт фәзаэ (пространство)

белән тыгыз бәйләнештә тора. Язучыга кичәге вакыйгалар бүген өчен мөһим, кызыклы тоелалар, төрле фикерләр уяталар. Гомумән, “яшьлек хатирәләре – кешене гомере буена җылытып, юатып, шатландырып, үкендереп торучы үткән чынбарлык ул”[90]. Шул сәбәпле үткәнгә күбрәк игътибар бирелә һәм аның вакыт белән пространство чикләре киңәя.

Ф.Хөсни әсәренең үзенчәлеге булып, сайлап алынган һәр вакыйганы бүгенге белән тыгыз бәйләнештә күрсәтү, ягъни үткәндәге хисләрнең бүгенге әһәмиятен ассызыклап бирү тора. Кагыйдә буларак, өлкән язучы әсәрнең информация өлешен үзе өчен мөһим вакыйгалардан кора. Әдип Мөхәммәтфатыйх Хөснетдиновтан Фатих Хөснетдиновичка, аннары Фатих Хөснигә әверелү – шәхес буларак танылу процессын җентекләп күзәтә. Мисалга, үзен тәнкыйтьләп, холкындагы үҗәтлек, масаерга ярату сыйфатларын берничә мәртәбә кабатлый. Башлангыч чор иҗатында “шәп итеп, шаккаттыргыч итеп язарга тырышуы” (317) – “әдәбиятның бурычларын ныклап аңлап җиткермәү дә, яшьләргә хас чак кына кыланчыклык та, үзенчә мөгез чыгарырга тырышу, оригинальлек артыннан куу да” (347) булуын таный. Язучы тәүге хисләрен бөтен тормыш материалы белән гомумиләштерә, моңа нигезләнеп, ул үз чорының олы вакыйгалары, фәлсәфи кануннар, яшәеш мәгънәсе турында уйлана башлый. Мисалга, әнисенең үлеме вакыйгасын зур “рухи тетрәү” дип кабул итүен күрсәтә: “Аннан соң күп кенә кешеләрне озаттым мин, зур гына кешеләр дә китте, газиз кешеләр белән хушлашуның җиңел түгеллеген беләм. Әмма ләкин әлеге шул егерме беренче елның март киче кебек салкын, күңелсез кичне һәм дөньяның ул вакыттагыдай бушап, шыксызланып калуын һич белмим”. (223)

Яшь Фатихның бу хәсрәте вакытка бәйсез рәвештә даими хәсрәткә әверелә. Газиз кешене озату кайгысының тирәнлеге, зурлыгы илгә ачлык вакыйгасы китергән фаҗига белән бәйләнештә күрсәтелә: “1921 нче ачлык елны, ачлыкның дәррәү сугып егуыннан булмаса да, шулай да алабута, имән чикләвеге оны белән кушып пешерелгән җитәр–җитмәс азыклардан әкренләп өзелә килгәнлектән булса кирәк, минем әни үлде”(222). Дөньяның фанилеге турындагы яшәеш кануны малайны “кинәт олы сымак” итә.(223) Башкача әйткәндә, бала шәхес буларак формалашуга бер адым ясый.

Язучы әтисе образын аерым игътибарга алып сурәтли. Әтисе Хөснетдиндә булган үҗәтлек, гайрәтлелек, “беркадәр үлчәүсезлек”, “шашкын йөрәклелек” (225) әдипнең үзендә һәм ул тудырган образларда

---

[89]Хөсни Ф. Минем тәрәзәләрем / Сайланма әсәрләр. 3 томда. – Т. Ш. ‑ Казан: Тат кит..нәшр.,1968. – Б. 205. (Алда җәя эчендә бит саннары күрсәтелә барачак)
[90] Яхин А.Г. 11 сыйныфта татар әдәбиятын укыту. – Б.55 .

гәүдәләнеш ала. “Әгәр вакыт–вакыт минем дә тамырыларымда шундый тиле кан кузгалып–кузгалып киткәли икән, әгәр мин язган китапларымда беркадәр үлчәүсезрәк, ләкин шашкын йөрәкле ике Айдар, бер Сәфәргали тудыра алганмын икән, шактый ук дәрәҗәдә тынгысыз җанлы шул этигә бурычлымын” (224–225). Шул рәвешле, автор, этисенең аерым шәхси характер сыйфатларына игътибар итеп, “мин” образына бәя бирә. Биредә лирик геройның үз–үзе белән горурлануы, иҗатыннан, ниһаять, сайлаган тормыш мәсләгеннән канәгать булуы сиземләнә. Ара–тирә “чиертеш малай” дип кимсенсә дә, атасы Фатыйхның күңел дөньясы формалашуда зур роль уйный. Моннан аңлашылганча, ата турындагы хәтердә беренче нәүбәттә авторның үз шәхесенә бәя үзәккә куела.

Балачактагы хисләрен сурәтләгәндә, өлкән язучыда шул вакыттагы күңел тынычлыгын сагыну хисе уяна. Гаиләдә төпчек булганлыктан, ул иң сөекле , иң иркә бала була. Икенче яктан, аңлы язучы үзенең гамьсез балачак хыялларыннан, фикерләреннән көлә. Мисал өчен, Г.Тукай дәрәҗәсенә таба үрмәләүче шагыйрь итеп күзаллаган яшь әдип болай ди: “Нихәтле беркатлылык, җиңел уйлау, сабыйлык. Түбәндә, чокырда булганмын мин ул чагында”.(275) Шунысы мөһим: яшь Хөснигә хас балаларча самимилек, тәҗрибәсезлек, “үлчәүсезлек” шул чорда бер төркем яшьләрдә күзәтелә. Язучы бу фикерне үзе үк ассызыклап бирә: “...күптән түгел генә Театр техникумын бетереп чыккан Хәким Сәлимҗанов, Зариф Закиров, Риза Ишморат кебек яшь артистлар озын чәч үстереп, шакмаклы пиджаклар киеп, татарда соңга калып уянган “футуризмны” аякка бастырмакчы булып йөриләр. Бөтен нәрсә яшь күренә, барыбыз да бугаз киереп кычкырырга яратабыз”.(280)

Язучы автобиографик әсәрдә еш кына тормышның мәгънәсе турында фикер йөртә. Яшь Хөсни үзеннән соң киләчәк буыннарга шаулап торырлык дан, шатлык калдырырга хыяллана. Өлкән язучы әлеге шау–шулы дан турындагы хыялга тиешле бәясен шушы мәсьәләне кабат кузгатып күрсәтә. Шәхеснең күңел кичерешләре аның дөньяга карашын, фикерләвен ачыкларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, шагыйрь Такташның кинәт вафат булуы бөтен җәмәгатьчелек өчен фаҗига, кителмәгән хәсрәт булуын искәртә. Өлкән язучы үзенең шул хәлдән соң “җитдиләшеп” киткәнен күрсәтә: “Һәрхәлдә, бер хакыйкатьне төшенә башлагандай булдым: юк, бу дөньяга без шаярып өчен килмәгәнбез, нәрсәдер эшләп калырга кирәк”.(300) Бу омтылышлар, фикерләр өлкән “мин” тарафыннан яшь әдипнең уй–кичерешләре кебек билгеләнә. Тормыш мәгънәсе турында әсәр ахырында әйтелгән берничә фикер алдагы идеяне тулыландырып килә: “бигрәк тә шунысы әһәмиятле: без, “бөтенесен дә беләбез, бар нәрсәгә ирешкәнбез!” дигән тәкәббер карашыбызны югалта

төштек. Юк, халыкның без белмәгән, без ачмаган байлыклары да күп булса кирәк әле. Безнең–язучыларның һәм, гомумән, барлык сәнгать кешеләренең –изге бурычыбыз– халык күңеленең әнә шундый ачылмаган якларын өзлексез ача барып, халыкның үзенә һәм аннары башка халыкларга әйтү:

–Менә син кем! Менә син нинди шаккаттыргыч эшләргә сәләтле. Менә синең әле моңарчы үзең дә белеп җиткермәгән нинди матур якларың бар!"(381)

Бу фикер әсәрдәге барлык вакыйгаларга бәя бирү бизмәне булып тора. Сабан туенда чабышта катнашкан һәр атны бәяләү вакыйгасы әсәрдәге үзәк идеягә метафора–вакыйга ролен үти. Өлкән язучы әсәрдә үзен мактау, данлау белән мавыкмый, ялгышларын, иҗатының кайтыш якларын тасвирлый. Шуңа нигезләнеп, әсәрне ике өлешкә бүлеп карарга мөмкин. Беренче өлеш – ат чабышы турындагы метафора– вакыйга, икенче өлеш халык язмышы турында язучы уйланулары. Язучы үз тормышының мәгънәсен "мескен халыкны" юатуда, аның хәсрәтен үзенеке итеп кабул итүдә күрә. Әсәрнең ахырында интонацияне үзгәртеп, шул фикерне үткәрә. Кеше күңеленең иң тирән хисләрен аңлау өчен, әдипкә "якты пыялалы киң күңел тәрәзәләре кирәк". Рухи сафлыкка омтылу турында пафос белән әйтүе аның шул фикернең хаклылыгына ышануы һәм башкаларны ышандырырга теләве кебек аңлашыла. Ф.Хөснине аның тормыш юлын өйрәнеп иҗатына бәя биргән әдәбият галиме Р.Сверигин "романтик табигатьле халык улы дип атый"[91].

Ф.Хөсни халык язмышын үз язмышы аша тасвирлый. Язучы үзе тормыш кыенлыклары белән бик иртә очраша, ләкин "аның күз алдында һәрвакыт өмет уты балкый, ... ул оптимист, шук табигатьле, җор күңелле..."[92]. Шунысы мөһим: һәр әсәренә хас булганча, биредә дә язучы көлү алымы белән иркен эш итә. Халыкның наданлыгыннан көлү үзенең туу датасы белән бәйле вакыйгада, укытучы абыйсының "тышлыклары каерылып, керләнеп беткән берничә дистә китаптан торган... авыл китапханәсе" турында, җизни тиешле кешенең пароходны ничек йөртүләрен аңлатуын сөйләгәндә кабатлана. Өлкән "мин" бала "мин"нең ачлык, ялангачлыктан туган хәсрәтен елмаеп сурәтли. (Авырлыктан зарланмау мотивы Г.Тукайның "Исемдә калганнар" әсәрендә чагылыш тапкан иде). Ф.Хөснинең, хәсрәт хисе турында сөйләгәндә, ирония һәм юморга мөрәҗәгать итүен берничә җитди сәбәп белән аңлатырга мөмкин. Беренчедән, язучының ачыктан–ачык зарланып язуы хакыйкатьне бөтен тулылыгында ачып бирү булыр иде. Көлү алымы цензураның тискәре

[91] Сверигин Р. Фатих Хөсни. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1968. – Б.102.

бәясеннән котылу чарасы булып тора. Икенчедән, өлкән язучы үзенең шәхес буларак олы җанлы, нык ихтыярлы икәнен раслый,тормыш авырлыгына юмор аша бәя биреп, укучысын сокландыра.

Халык язмышы, хезмәт кешесенең көнкүреше, тормышы, аны борчыган проблемалар Р.Төхфәтуллин иҗатында үзенчәлекле гәүдәләндерелә. Н.Гыйззәтуллин аның иҗатын характерлап, болай ди: “Р.Төхфәтуллин иҗатында төп нәрсә – аның хезмәт кешесенә тирән мәхәббәтендә, үзенә яхшы таныш кешеләрнең тормышын, аларның уңай сыйфатларын, кайгы–хәсрәтләрен, бәхет һәм шатлыкларын йөрәге аша кичереп күңеленә тирән сеңдерә алуында, тормыштагы иң гади вакыйга һәм хәлләрнең дә романтик матурлыгын күрә белүендә, тормыш фактларын сәнгать фактына әйләндерә алу сәләтендә”[93].

Повестьта вакыйгалар нәни малай исеменнән сөйләнә. Яшь малай тойган, аңлаган, кичергән тормыш авырлыклары укучының күңеленә үтеп керерлек, җитди итеп бирелә. Әсәрдә 60–70 нче еллардагы идеология шаукымына бәйле проблемалар яшь малай өчен генә түгел, олы яшьтәге язучы өчен дә әһәмиятен югалтмыйлар. Повестьта авылда мәчет манарасын төшерү вакыйгасының фаҗигасе калку чагылдырыла. Мәчет манарасын аудару халыкның муенын кисү белән бер, дип бәяли автор. Бигрәк тә авыл карты Кәрим бабай һәм аның карчыгының бу күренешкә йөрәкләре әрни, җаннары сызлана. Ә мәчет манарасын төшергәнне карарга җыелган балалар өчен бу бер кызык күренеш кенә булып тоела. Язучы балаларның мәчет манарасын аударганны карарга төшүен символик мәгънәгә ия дип белдерә. Бу – киләчәк яшь буынны диннән, иманнан аеруның бер ысулы.

Әсәрдә игътибарны җәлеп иткән образлардан Фазыл аеруча җылылык белән тасвирлана. Ул – олы гәүдәле, сары мыеклы, җитди кыяфәтле, калын тавышлы, гайрәтле ир–ат. Өлкән язучы белән малайның Фазылга бәясе төрле. Кечкенә малай Фазыл турында начар фикердә. Ул аны биек кәнәфиендә утырып кешеләргә карата каты, кырыс председатель буларак тасвирлый. Соңрак ул Фазылның принципиальлеген, төрле вакытта үзен яхшы яктан күрсәтә алуын, үз сүзе барлыгын, шул сыйфатлары өчен аны авыл халкының хөрмәт итүен билгеләп үтә. Фазыл авылдашларын аңлы–белемле итәргә тели, махсус рәвештә мәктәп оештыра, ләкин авыл кешеләре аңа каршы чыга. Моңарчы томана яшәгән халыкка бүген дә белемнең әллә ни кирәге юк. Алай да Фазылның максаты изге. Автор фикеренчә, ул – шул чор идеологиясе корбаны, өстән

[92] Шунда ук. – Б.103.
[93] Гыйззәтуллин Н. Әдәбият һәм тормыш / Кешенең күңел матурлыгы. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1988. – Б.103.

кушканны берсүзсез үтәүче җитәкче. Язучы Фазылның өлкәннәргә карата игътибарлы булуын, шуңа күрә абруе барлыгын ассызыклап үтә.

Әсәрдә Касыйм образы – иң матур образлардан. Касыйм абзый – колхозның яшелчә бакчасында хуҗа кеше. Ул – бик усал, ләкин бик нык куллы хуҗа. Касыйм бакчасы иртә яздан кара көзгәчә гел шау чәчәктә утыра. Яшел суганнан алып, редиска, кыяр, помидор, кәбестә, кып–кызыл алмалар дисеңме, аның бакчасында ничектер бик тиз өлгерә. "Эшенә дә бөтен җанын бирер, ну инде эшенә тисәң, синең җаныңны суырырга да күп сорамас", – ди аның турында авыл халкы[94]. Бакчасына рөхсәтсез кергәннәрне аямый ул, ау мылтыгына тоз тутырып, бала–чаганың арт сабакларын укыта, кычыткан көлтәсе белән "җимешнең иң татлы җирен" күрсәтеп ала.

Әсәрдә бакча образы Касыйм гаиләсенең йөзен, аның хуҗаларының ачык күңелен символлаштыручы образ буларак тасвирлана. Касыймның хатыны Гөлсем дә малайның күңелендә иң матур тойгылар уята. Автор Гөлсем апаның портретына игътибар итә. Түгәрәк йөзле, колак очларында зур гына алкалы, зәңгәр чемчекле ап–ак яулыклы, мөлаем карашлы изге күңелле татар хатыны язучы күңелендә якты нур булып саклана. Касыйм белән Гөлсемнең өйләре дә гел үзләренә охшаган: "Аларның өйләре һәрвакыт якты, җылы була иде. Бу җылылык, бу яктылык, барыннан да бигрәк Гөлсем апаның көләч йөзеннән, Касыйм абзыйның түгәрәк чал сакалыннан бөркелә" (358). Автор Касыйм белән Фазыл арасындагы тирән каршылыкны да күрсәтеп үтә. Бу каршылыкның асылы яңа гына кертелә башлаган алфавит – яңалиф белән бәйле. Авыл кешесенә эшнең нәтиҗәсен күрсәтми торып, аны теге яисә бу яңалыкка ышандыруы авыр. Бу – хакыйкать, кеше психологиясенең бер үзенчәлеге. Фазыл белән Касыйм арасындагы сөйләшү кызыклы:

– Син, Касыйм абзый, аң–белем эшенә явный аяк чалу юлына баскансың. Үзең дә йөрмисең курска, понимаешь, Гөлсем апаны да йөрмисең.

– Мин карчыкны тотмыйм, йөрсен, әмма ләкин миңа кирәкми ул яңалиф. (363)

Ахыр чиктә Рафаил бу эшне җайлауның әмәлен таба: аларны кичке якта язу танырга, укырга өйрәтә башлый. Берникадәр вакыттан көтелгән нәтиҗә: Гөлсем апа, яңалифне үзләштереп, шактый гына матур, йөгерек укырга, язарга өйрәнгән икән. Ул көннәр "яшь мөгаллимгә" хезмәт шатлыгы белән бергә, гаҗәпләнү тойгысы да алып киләләр. Яшь укытучыда бу эше үзе бер горурлык хисе тудыра. Һәр кеше күңелендә

тормышында беренче тапкыр булган вакыйга тирән уела, бер вакытта да онытылмый, мөһимлеген җуймый. Яңалиф мәсьәләсендә бер–берсен аңламаган Касыйм һәм Фазыл абзыйлары арасындагы мөнәсәбәтләрнең җайлашуына да малай беркадәр ярдәм күрсәтә. Өлкән әдип алар арасындагы каршылыкны бетерү теләге малайны яшь укытучы һөнәрен сайларга этәрүче сәбәпләрнең берсе булуына басым ясый.

Повестьта 20–30 нчы еллар өчен хас тагын бер проблема – иске татар телендә язылган һәм гарәп телендәге китапларны юкка чыгару, динне инкяр итү мәсьәләсе гәүдәләнеш ала. Әсәрдә авыл малайларының китап битләреннән очырткыч ясап уйнаулары сабыйчак шуклыгы дип бәяләнә. Шунда ук шәһәрдән килгән “эшләпәле интеллигентның” фикере китерелә: “...барлык иске китаплар да дини китаплар гына түгел бит. Алар арасында милли культурабызның җәүһәрләре дә бар” (351). Язучы повестьта тагын бер проблемага туктала. Бу – яңа буынның борынгыдан килгән гадәтләрне онытып ауропалашуына бәйле мәсьәлә. Ауропаның алдынгы карашлы фикер ияләренә хөрмәт йөзеннән килеп кереп, татар исемнәрен беркадәр читкә этәргән “Рафаил,  Чарлис” исемнәрен ишеткәч, авыл картлары “сөбханалла–машалла” дип тел шартлаталар, исемнәре дә үзгә хәзер, дип борчылалар. Моңа бәйле рәвештә, язучы буынара бәйләнешләрнең өзелү мәсьәләсен дә үзәккә куеп бирә. Бабайлар чал тарихның әкрен дә сиздермичә яшьләр хәтереннән җуела баруына көрсенәләр.

Автобиографик әсәрләрнең күпчелеге кечкенә “мин” тормышын сөйләү  белән башланып китә дип билгеләп үттек. Язучы сабый вакытындагы хисләрен хәтерендә яңартырга омтылыш ясый. Билгеле булганча,  5–6 яшьлек баланың тормышындагы бик ачык төсмерле хис һәм вакыйгалар гына соңрак искә төшә ала. Шул сәбәпле өлкән язучы сабыйчак мизгелләрен тәртипсезрәк рәвештә, хәтердә сакланганча сөйләп бирә. Кечкенә Гумәрнең әтисе янда булганда ата казлардан курыкмавы, юеш салкын туфрак өстендә “табага баскандай” сикергәләве һ.б. уен шатлыклары, Фатихның апалары туенда ишек бавын тоту шатлыгы, казларны кызгануы һ.б. эпизодлар еш кына бер–берсенә бәйләнешсез сурәтләнәләр.

Аерым очракларда әдип бер–берсенә охшаш вакыйгаларны фикер үсешен күрсәтү максатында туплап, җыйнап бирә. Мисалга, Ш.Маннурның “Агымсуларга карап” әсәрендә “Ут, эт, айбагыр” бүлегендә кечкенә “мин”нең янгыннан, эттән һәм урлашудан  куркуы сурәтләнә. Өлкән “мин” курку хисенең эчтәлеген, табигый халәт һәм кешенең рухи үсеш дәрәҗәсен  билгеләүче сыйфаты дип, икегә бүлә. Бу өч вакыйганы

[94] Төхфәтуллин Р. Җиләкле аланнар / Сайланма әсәрләр. Ике томда. – Т. П. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1983.

берләштерүнең мәгънәсе – шәхеснең уңай сыйфатлары анның табигатендә бар, саклана һәм ул үстерелеп, гадәткә әверелергә тиеш дигән нәтиҗә. Бу фикер малай белән бәйле тагын бер вакыйгада ассызыклана. Ул, чыбыркысы булмаганга гарьләнеп, Бәбекәй абзыйның мунчаласын урлап кайта һәм әтисе күзеннән яшерә. Ләкин яман эш тиз ачыла һәм әтисе улына җәза бирә: "Тиз генә шул беләк юанлыгы мунчаланы тотты да, икенче кулы белән мине эләктереп, арканы сыдырырга тотынды. Бер сукса – зәһәр суга иде ул"[95].

Шунда ук үткәндәге вакыйганың бүгенге көн өчен дә мөһимлеген билгеләп үтә: "Төнәтү сүзенең мәгънәсен шуннан бирле бик яхшы беләм мин", – ди[96].

Бер чорда яшәгән язучыларның балачактагы уй–хыяллары, уеннары, хисләре уртак һәм охшаш була. Кечкенә малайларда шатлык, өлкән язучыда шул шатлыкны сагыну хисе уяткан Сабан туе, Каз өмәсе, Аулак өй кебек милли гореф–гадәтләр, чәчүгә чыгар алдыннан җиргә күкәй чәчү йоласы турында информация һәр автобиографик әсәрдә урын ала. Кечкенә "мин"нең мактану, үз–үзе белән горурлану өчен тырышуын өлкән "мин" анның рухи үсеше буларак бәяли, ягъни бала матурлыкны күрергә һәм үзендә булдырырга омтыла дигән нәтиҗә ясый (Сабантуйда яңа кием киеп, уенда җиңеп мактану һ.б.). Бу рәткә кечкенә малайларның иркәләнергә ярату сыйфатларын да кертеп карый алабыз. Кагыйдә буларак, язучы әсәрнең башында ук сабыйчакның иң матур һәм истәлекле мизгелләре кебек хәтердә сакланган аналарына, туганнарына иркәләнү, сырпалануларын тасвирлыйлар. Г.Бәширов әнисе образын аерым бер җылылык, мөлаемлык, олы ярату аша тудыра: "Анның юка гына борын канатлары сәер генә булып селкенгәлиләр, соргылт күзләре тирәсендә ягымлы җыерчыклар җыела. Үзенә генә, бик матур итеп, нindидер матур сүзләр әйтәсе, я берәр күңелле нәрсә сөйлисе килә башлый" (66).

Сабыйчак образын тудыру максатында, әкият, миф яисә нindидер ышану–ырымнарны файдалану – һәр автобиографик әсәргә хас күренеш. Г.Бәшировта еланнар патшасы турында әкият, "Ажги амбары" турында легенда, табигатьне күзәтүдән туган эпизодлар исәпсез. Һәр күренеш бер эчтәлек тудыра. Мисал өчен, Алып батыр турындагы әкият дөньядагы һәр җан иясенә хөрмәт белән карарга кирәк дигән фикерне алып керә. Ана казның "тал бәбчеге төсле яшькелт мамыктан гына оешкан шул нәни бәбкәләренә бик ягымлы итеп, пышылдап кына"эндәшүе һәр ана белән

---

– Б.360 . (Алда җәя эчендә бит саннары күрсәтелә барачак)

[95] Маннур Ш. Агымсуларга карап. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1974. – Б.62. (Алда җәя эчендә бит саннары күрсәтелә барачак )

[96] Шунда ук. – Б.25 .

бала арасындагы үтә нечкә җепләр, җылы хисләр, шуларның матурлыгына чагыштыру булып килә. Нәни Гумәрнең сөйләм теле әкияти, серле табышмаклар белән тулы. Язучының балаларга хас образлы фикерләүгә, һәр табигать күренешен җанландыруга әһәмият бирүе – аның әсәренең үзенчәлеге, язучының уңышлы табышы. Шул ук вакытта мондый фикерләү мөмкинлеген төгәл һәм детальләп тасвирлау малайга бәя бирү вазифасын үти. Гумәр үзенең яшьтәшләреннән әллә ни аерылып тормый. Димәк, автор сабыйчак образын тулы сурәтләп, аның матурлыгын, хыялыйлыгын, серлелеген бәяли: “Минем монда беркем дә белми торган бик яшерен, әкияттәге урман эчедәй серле бер урыным бар. Анда кояш төшми, җил үтми. Канәфер ботаклары арасыннан, бик биектә, зәңгәрсу күк кенә күренә. Кошлар синең баш өстеңә үк килеп утыралар да, берни дә сизмичә, рәхәтләнеп сайрыйлар... Бу серле дөньяда мин үземне, Алып бабай кебек, бик зур итеп күрә башлыйм. Картларның аның турында сөйләгәне исемә төшә” (106). Биредә ай кызы турындагы тасвирламаны да мисал итеп китерү урынлы булыр: “Күктәге йолдызларның исәбе–саны юк, аларның һәркайсы, йодрык хәтле булып, зәңгәр очкыннар чәчрәтеп тора. Айдагы теге кызый шулкадәр ачык күренә, лапас түбәсенә шундый якын тора, әйтерсең хәзер иелер дә, көянтә–чиләген лапас кыегена элеп, үзе ишегалдына сикереп төшәр кебек. Шулай да ул кыз хәзер бик моңсу кебек күренде. Мин аны хәтта кызгана башладым” (21).

Балалар, үсә төшкәч, әкиятне бары матур хыял итеп кенә кабул итә башлыйлар. Дөньяны танып белү процессында алар чынбарлык белән әкият арасындагы аерманы төшенә баралар. Бу процесс әсәрдә нәни Гумәрнең күңел дөньясының үсеш юлы буларак бәяләнә.

И.Газиның “Малайлыкта кунакта” автобиографик повестенда сабыйчак образы башка планда тудырыла. Бу әсәрдә И.Гази үзенең балачагына, туган авылы Карамалыга әйләнеп кайта. Өлкән язучы балачагын сагыну хисенең эчтәлеген, аның табигый матурлыгын, самимилеген юксынуны шул чор атмосферасы белән бәйләп аңлата. Сабыйчакны югалту фаҗига буларак тасвирлана. Чөнки ул яшәгән чордан берни дә калмаган, аның балачагының матурлыгы югалган. Өлкән “мин” өчен хәзерге заман матурлыгы кыйммәтле түгел. Әсәрдә балачак югалу белән матурлыкның бетүеннән туган үкенү хисе ачыктан–ачык белдерелә: “Мин аллага ышана идем. Сез ышанмыйсыз. Мин бичурага, җен–пәригә, су анасына ышана идем. Сез каһәрләр, ышанмыйсыз. Олы күлдә су анасының, басмага чыгып, ай яктысында чәч тарап утыруын күреп кайттым дип, Закир сукыр ялганлангач, без шуңа тәмам ышанган идек. Сукыр башы белән су анасын ул ничек күргән, шуны уйлап карамаганбыз. Ә сезне, бар, ышандырып кара. Без бүтәнрәк кеше идек шул. Сезнең әнә

чатыр–чотыр мотоциклыгыз гына да биш су анасын, алты албастыны, җиде шүрәлене өркетеп качырырлык!”[97]

Язучы үкенү хисенең дәрәҗәсен хәзерге балачакның матурлыгын инкяр итеп күрсәтә. Һичшиксез, ул аны танымый түгел, әмма кабул да итә алмый. Бу очракта инкярне инкяр итү фәлсәфи кануны өлкән “мин”нең бәясе булып тора. Башка автобиографик әсәрләрдән аермалы буларак, язучы үзәккә балачагын югалту үкенече хисен ала, ләкин бу әле халык язмышы белән бәйле хәсрәт хисе бөтенләй сурәтләнми дигән сүз түгел. Ачлык, ялангачлык, ятимлек – лирик геройдагы хәсрәт хисенә сәбәпче хәлләр. И.Гази балачагының тоташ хәсрәттән торуына зарланмый, тик үкенә. Аның сөйләмендә бүгенге белән үткәнне янәшә куеп чагыштыру алымы өстенлек ала. Бүгенгенең матурлыгы –рәхәтлектә, иркенлектә. Үткәндә болар һәммәсе хыял иде. Балачак, нинди генә газаплы булса да, гомер буе юксындыра, ымсындыра икән. Шул рәвешле, бу әсәрне ике өлешкә бүлеп карыйбыз.

Кагыйдә буларак, әсәрдә язучының замандашлары, туганнары образлары гәүдәләнеш ала. Алар арасында Хәмидулла абзый, Зәкәрия абзый, күрше Җәлил агай, Галәү абзый, иптәшләре Хәбир, Касыйм, Шакир һ.б., аеруча яратып, җылы хисләр белән искә алына. Тәтеш врачы Аркадий Боголюбов үз эшенә нык бирелгән чын табиб образы буларак бәяләнә. Соколов – аңа капма–каршы образ. Ул да врач, ләкин, Боголюбовтан аермалы буларак, ялган белешмәләр яза, үз эшенә салкын карый. Лирик герой, Җәлил абзый турында искә алып, аның күп сөйләшергә яратмавын билгеләп үтә. Кечкенә малайга үзен кемгә дә булса кирәкле итеп тою рәхәте бик кадерле .Җәлил абзыена алма сатарга ярдәм итеп, малай беренче тапкыр эш башкару бәхетен, үзенең өлкәннәргә кирәкле булу шатлыгын тоя. Ибраһимнарның икенче күршесе Таифә нәнәйнең бердәнбер улы сугышта үлеп калган. Әлеге образ аша язучы ил кайгысының ни дәрәҗәдә зур булуын күрсәтә. Малай Таифә нәнәсен чын күңелдән кызгана: “Мин аны кызганам. Кызгана торгач, улына атап җыр чыгардым...Таифә нәнәй бик яраткан иде, кызарып беткән күзләрен сөртә–сөртә тыңлаган иде”(330).

Балачагының чиксез авыр чорга туры килүен ул кабат–кабат тасвирлый. Үзен приютка илтүләрен, анда үткәргән беренче көннәрен аеруча моңсу катыш кырыс нота белән сурәтли. Авылда вакытта өнәп бетермәгән Хафизны – приюттагы бердәнбер авылдашын үз итә, ярата башлый.

[97] Гази И. Малайлыкта кунакта / Әсәрләр. Өч томда. Т.I. Повестьлар һәм хикәяләр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1987. – Б.299. (Алда җәя эчендә бит саннары күрсәтелә барачак)

Авыр балачагыннан тирән уелып калган тагын бер җәрәхәт– аның ата–ана назына туймавы. Автор, сөйләм интонациясен үзгәртеп, малайның газизләрен югалтуга бәйле эчке кичерешләрен өлкән язучы исеменнән сөйли: “Ата–ана кабере... Ул читтә йөргәндә анасы гүр иясе булган... Юлда кышлый катып үлгән... Аның каберенә дә бара алмый, чөнки белми... Әтисенең сөякләре тау читендә ялгыз яталар”…(301) Өлкән “мин” сөйләме аша кеше тормышының бу чиксез авыр, гасабилы, кайчак күңел йончыткыч фани дөньядагы мәгънәсе турында фәлсәфи фикерләр берничә мәртәбә кабатлана.

Әсәрдә бары балачакта гына була торган шатлык–сөенечләр, юанычлар шулай ук кабатланып килә. Язучы фикеренчә, тәрәзә куючы артыннан йөгерүләр, чыбыркы шартлатудан кызык табулар, башка беркайчан кабатланмаячак әкияти мизгелләр булып, могҗиза рәвешендә күңелдә саклана. Балачактагы хыяллар да үзенчәлекле, алар, беркайчан да тормышка ашмасалар да, сабыйчакның матурлыгы булып, мәңгелек халәттә калалар. Биредә язучы, үзе дә сизмәстән, И.Кантның саф матурлык беркайчан да файда өчен булырга тиеш түгел, дигән фикерен раслый. Кечкенә вакытта малай кош булырга тели, кош кебек ерак биеклеккә, чиксезлеккә ашкына, ләкин өлкән язучы бу хыялның бары хыял булып калачагын искәртә. Соңрак самолетларда очарга туры килсә дә, кош булу хыялы барыбер күңелендә яши, саклана. Самолетта очу рәхәтен кошларның чиксезлектә канат кагулары белән чагыштыру мөмкин түгел, ди автор. Кеше гомере буе ireккә омтыла, үзен төрле кысалардан азат итәргә тели. Кошлар алар теләсә кая очып китәләр, теләсә нинди җирләрне күрә алалар, алар биеклегеннән “авылда ниләр барын, кемнәрнең нишләвен карап йөрү” – кеше өчен буй җитмәс хыял, теләктер, мөгаен. Өлкән язучы малайның көнбагыш булып, эт эчәгесе чәчәге булып кап–каты туфракта үсеп утырырга теләвен дә билгеләп үтә. Биредә автор кешенең чәчәкләр, гомумән, табигать сулышын тоярга омтылуын тасвирлый. Балачакның самими хыяллары, бары хыял булып калганда гына, чын матурлыгын саклап кала дидек. Чөнки кеше белән табигать арасындагы бәйләнешләрнең аклыгына, сафлыгына гөнаһсыз сабый сизгеррәк. Шул ук вакытта бу хыяллар кешене гомере буе үзенә буйсындырып, җылытып, ымсындырып тора. Әсәрдә кабатлану алымы хис көчәйтү вазифасын үти. “Без дә үзебезчә бәхетле идек” гыйбарәсе берничә тапкыр кабатланып килә. Лирик чигенеш һәр ике очракта кабатлау эчендәге кабатлау буларак бирелә. Беренче очракта җөмлә “хәер” кереш сүзе белән башланса, икенче очракта җөмлә башында “әйе” сүзе тора . Димәк, бердән, автор бәләкәй чактагы бәхетен чын бәхет дип бәяли, шул ук вакытта, “иде” формасын кулланып, аның үткәндә булуына басым

ясый. Икенчедән, “үзебезчә” дип, һәркем үзенчә, һәр буын үзенә күрә бәхетле дигән фикергә игътибар итәргә куша.

Рафаил Төхфәтуллинның “Җиләкле аланнар” повестенда балачак образы – җиләкле аланнар. Образ–символ әсәр ахырында кабатлана. Бу – балачакны сагыну хисенең даими булуына ишарә. Язучылар балачактагы самими сөенечләрнең, хәтта шул чор тудырган авырлык хәсрәтенең яңадан кабатланмавын төшенгән хәлдә, бүгенге көндә шуны сагынып юаналар. Үткәндәге зур хисләр, бүген хәтердә уянып, яңа матурлык тудырырга сәләтле. Өлкән язучыларның бик кечкенә вакыттагы хисләрен искә төшерергә омтылулары – шул саф матурлыкны яңадан тудыру теләге ул.

Шул рәвешле, “Җиләкле аланнар” повестенда балачак вакыйгалары өлкән язучының иң кадерле, иң самими истәлекләре буларак гәүдәләнеш ала. Балачак образы белән бәйле рәвештә, автор авыл тормышының кайбер үзенчәлекләрен, проблемаларын тасвирлый, малай исеменнән шуларны сөйли.

7–8 яшьтән балада тормышны аңлы рәвештә танып–белү ихтыяҗы туа. Автобиографик әсәрдә бу чорны тасвирлау мәдрәсәгә укырга бару вакыйгасын бирү белән башлана. Өлкән “мин” кечкенә “мин”нең беренче тапкыр китап тоту шатлыгын, шәкерт булу сөенечен бәяли. Бу вакыйгалар, баланың киләчәгендә зур әһәмияткә ия булу сәбәпле, кабатланып киләләр. Ф.Хөснидә Әхмәтша абый китапханәсе болай тасвирлана: “Тышлыклары каерылып, керләнеп беткән берничә дистә китаптан торган шул кечкенә авыл китапханәсе, әмма эшлисе эшен эшләде, кем белә, шуннан килеп төшкән нур валчыклары, үзләре янына башка нурларны йоктырып, безнең күңелләрдә әле һаман исән–сау саклана торганнардыр” .(221–222)

Г.Бәширов әсәрендә бу фикер шулай ук кабатланып бирелә. Тормыш авырлыкларын шактый күп татыган Гумәргә китаплар “хыялый матурлык” алып килә, “бер төрле йокымсыраган авыл тормышына җан кертеп җибәргәндәй була”[98]. Зәбихулла абыйдан алган беренче шигырь китаплары кечкенә Гумәрнең дөньяны танып белү ихтыяҗын канәгатьләндерер өчен хезмәт итәләр, “юанычларның иң зурысы” булып торалар. Язучы Гумәрнең бу шатлыгы бүгенгәчә дәвам итүен ассызыклый. Кечкенә малай үзенең киләчәген болай күз алдына китерә: “Минем өемдә идәннән түшәмгә кадәр өелеп менгән бик күп китап булыр. Калыннары да, юкалары да, күп төплеләре дә, мондыйлары да. Дәү булгач, мин аларның теләсә кайсын рәхәтләнеп укырмын”.(298)

[98] Җәләлиева М. Гомәр Бәширов. –Б. 4 .

Кулга китап тоту шатлыгы И.Газидә үзенчәлекле тасвирлана. Өлкән “мин” шул рәхәт мизгелләрне сагына, аеруча бу мизгелләрнең сирәк, шуңа кадерле булуын ассызыклый: “Хәзерге заманда гына ул китап күп. Авыл саен китапханә, мәктәпләрдә дә китапханә... Без малай чакта алай түгел иде. Китап бик кадерле иде. Әти базарга чыгып киткәндә “Китап алып кайтырмын” дисә, ул көнне җанга тынычлык бетә иде инде. Кайчан кайта дип, алып кайтамы дип, әллә таба алмыйча буш кул белән кайтып керәме дип, көне буе ут йотып тора идем. Юлга әтинең каршысына чыгып торулар, кулга китап эләккәч, куанычтан сикеренүләр, китапны тышлаулар, кадерләп кенә укулар”... (301) Авторлар балачак шатлыкларын сурәтләгәндә аеруча игътибарлы, алар лирик геройларның даими хәсрәтенә юану төсендә аңлатылалар. Шул ук вакытта язучылар тарафыннан яшь “мин”нең үсешендә мондый шатлыклар бүгенге белән бәйләнештә сурәтләнә. Соңрак китап язудан туган олы шатлыкның башлангычы әнә шул ярлы авыл китапханәләренә барып тоташа дигән фикергә басым ясала.

Шул рәвешле, автобиографик әсәрдәге балачак материалын язучылар ике өлешкә бүлеп тасвирлыйлар:

5–6 яшьлек сабыйчак хисләренә өстенлек бирү;

Баланың аңлы үсеш чорына бәя өлеше.

Беренче өлештә өлкән “мин” вакыйгаларда катнашучы кечкенә “мин”нең сабыйчак шатлыгын, борчуларын аның вафасызлыгы, самимилеге, табигый мәрхәмәтлелеге белән бәйләп аңлата. Шунда ук язучы бу матур чорның кабатланмавына моңая. Икенче өлештә өлкән “мин” кечкенә “мин”нең хисләр эчтәлеге үзгәрүен күзәтә. Яшь “мин”нең дөньяга карашы үзе яшәгән гаилә хәле һәм халык тормышы белән тыгыз бәйләнештә сурәтләнә. Моңарчы бөтен хакыйкатьне ишетеп, тоеп–сиземләп төшенгән бала, хәзер китаплардан укып, аңлы үзләштерү мөмкинлегенә ия. Бала әйләнә–тирә мохиткә бәя бирергә өйрәнә башлый, һәр вакыйгага башка күзлектән карый. Үткәннең бу чорын сурәтләүгә язучылар аерым игътибар бирәләр. Шул кечкенә “мин” теле белән күп кенә тирән фәлсәфи фикерләр, язучының тормыш турында уйланулары бәян ителә. Г.Бәширов, Ш.Маннур, И.Гази әсәрләрендә бу чор аеруча киң пространствода тасвирлана.

Һәр автобиографик әсәрдә халык язмышы әсәрнең аерым өлеше булып килә дип билгеләгән идек . Язучы, документаль фактларга таянып, чынбарлыктагы шәхесләрне образ, характер дәрәҗәсенә күтәреп, чорның

киңкырлы манзарасын тудыра. Бу да – документаль әдәбиятны күпмедер дәрәҗәдә матур әдәбиятка якынайта торган бер күпер.

Кагыйдә буларак, автобиографик әсәрдә халык язмышы мәсьәләсе лирик геройның әтисе һәм әнисе, ягъни гаилә тормышы аша гәүдәләнә. Шулай ук, аның авылдашлары, дус–ишләре образлары әлеге мәсьәләне яктыртуга хезмәт итәләр. Билгеле, алар автор тарафыннан сайланып алыналар һәм, кирәк булса, әдәби сурәт тудырганда уйдырмага да урын бирелә. Документаль әдәбият коры факттан гына тормый, язучы төрле максатларны күздә тотып, фактка хилафлык китермичә, образны үз фантазиясе белән баета ала. Бу җәһәттән Л.Гинзбург фикере кызыклы: “В документальном контексте, воспринимаемом эстетически, жизненный факт в самом своем выражении испытывает глубокие превращения. Речь идет не о стилистических украшениях и внешной образности. Слова могут остаться неукрашенными, нагими, как говорил Пушкин, но в них должно возникнуть качество художественного образа”[99].

Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” әсәрендә Бәшир ага, Ш.Маннурның “Агымсуларга карап” повестенда Фәрхулла ага, Ф.Хөснинең “Минем тәрәзәләрем” әсәрендә Хөснетдин ага образлары – үз чорының каһарманнары. Аларның гадел, игелекле, олы җанлы, иманлы, шул ук вакытта тормыш авырлыгыннан кырыс, аз сүзле булулары билгеләп үтелә. Балачак образын тудырганда, язучылар әниләре образына игътибар бирәләр. Һәр әсәрдә ана өлкән “мин”нең күңелендә мәңсу хисләр уятучы буларак тасвирлана. Аналарының күңел җылысы, сафлыгы, мәрхәмәтлелеге балачакта калган матурлык кебек искә алына. С.Батталның “Баштан үткәннәр” исемле истәлекләрендә әнисе образы мондый эчтәлектә бирелә: “Әни истәлеге миндә гел әдәплелектән, тыйнаклыктан, тынлыктан һәм өзлексез хезмәттән тора”[100].

Ана матурлыгы югары әхлакый кануннар, әдәплелек, күңел җылылыгы, мәрхәмәтлелек булып аңлашыла. Ана образының теге яисә бу әсәрдә башка эстетик мәгънәсе дә бар. Бала бөтен әхлакый кыйммәтләрне анасыннан кабул итеп ала, аннары гомере буе үзенең күңелендә шуларны йөртә, һәм, шәхес буларак формалашканда, әлеге кыйммәтләр хәлиткеч роль уйный. Анасына булган мәхәббәт кеше күңелендә гомере буе саклана, алай гына да түгел, шәхесне анасының үзенә булган мәхәббәте һәрвакыт рухландырып, дәртләндереп тора. Бүгенге уңышлары, тормышта үз кыйблаларын табулары белән өлкән әдипләр яшь чакта әти–әниләреннән алган сабакларга бурычлы булуларын кабатлап сөйлиләр.

---

[99] Гинзбург Л.. О психологической прозе. – С. 10.
[100] Баттал С. Баштан үткәннәр / Сайланма әсәрләр. Проза. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1974. – 246 б. (Алда җәя эчендә бит саннары күрсәтелә барачак)

Ана мәхәббәтенә тиң мәхәббәтне шәхес бертуктаусыз эзли, төгәлрәге, шундый мәхәббәт тудырган матурлыкны эзли. Шул матурлыкны таба алмаса, гомере буе анасын юксынып, хәсрәтләнеп яши. Өлкән “мин”нәрнең газиз ата–аналарын югалту хәсрәте иң авыр хәсрәт буларак тасвирлана. Бу хәсрәтнең бик иртә килүе хиснең дәрәҗәсен тагын да арттыра. Ш.Маннур, И.Гази, Ф.Хөсниләрдә бу мотив аеруча ачык белдерелә. Аларның иртә вафат булуларының сәбәбе итеп язучылар чиктән тыш авыр тормышларын күрсәтәләр. Әлбәттә, бу фикерләр сәяси басым нәтиҗәсендә артык көчле һәм берьяклы яңгырый. Гасыр башындагы тетрәнүләр һәр гаилә тормышына йогынты ясый. Революция, ачлык вакыйгалары әсәрләрдә аеруча киң гәүдәләнә. Мисалга, И.Гази, Ф.Хөснинең әсәрләрендә, аналарның фаҗигасенә сәбәпче вакыйга булып, ачлык күрсәтелә. И.Гази шулай ук үз анасының ачлыктан, ялангачлыктан гаҗиз булып, улын калдырып карт кешегә кияүгә китүен чынлап торып “олыгайгач аңлый”: “...атсыз, сыерсыз, ярдәмчесез хатын–кыз нишли алсын!”.(330)

Балачакта беренче тапкыр булган вакыйгалар, шуларга бәйле хисләр өлкәннәр күңелендә тирән эз калдыра дип билгеләп үткән идек. Һәр әсәрдә малайларның беренче укытучылары образлары төрле урын ала. Г.Бәширов беренче хәлфәсе Зәбихулла абзыйны бик тә әдәпле, “китапча” гына сөйләшә торган кеше буларак тасвирлый. Үз авылы мәдрәсәсендә укыганда, ул тел белән җәгърәфия фәннәренә гашыйк була. Әтисе аны кадими мәдрәсәгә илтеп ташлагач, бик кайгыра, туган авылы мәдрәсәсен сагына. Берникадәр вакыттан соң яңадан шунда кайта һәм беренче тапкыр Тукайның “Туган тел” шигырен укуын сурәтләп яза: “Ике юлын укуга, әллә ни булды. Нигә икәнен үзем дә белмәстән, әсәрләнеп туктап калдым”, – дип соклануын, гаҗәпләнүен белдерә. (145) Автор Зәбихулла хәлфәне кырыс, бик гадел, үз эшенә бирелгән укытучы дип бәяли: “Әгәр дә син сабагыңны белсәң, дәресләреңне яхшы әзерләп килсәң, шул ук кырыс холыклы хәлфәнең йөзе яктырып, вак кына тешләре күренә”. (150)

Гомумән алганда, язучы шул “дүрт–биш кенә тәрәзәле ... кечкенә иске бинаның” күңелендә онытылмаслык хатирә булып саклануын күрсәтә. Биредә аның шәхес буларак үсешен билгеләүдә мәктәпнең роле ачыкланып үтә: “барлык белеп чыкканнарың гомер буе синең тормышыңны баетып, аңа ямь биреп килде”.(150) Бу Ш.Маннур әсәрендә тагын да ассызыклана. Язучы үзенең тормыш юлында тел, әдәбият укытучысы Фарукъ абзый очравын хәлиткеч әһәмияткә ия дип күрсәтә. “Ябык–җыйнак гәүдәле, җирән чырайлы, бервакытта да чыгырыннан да чыкмый торган бу укытучы” үз фәнен җаны–тәне белән сөюе, күп нәрсәләр белүе белән бөтен укучыларны үзенә гашыйк итә: “Әдәбияттан

сөйли башласа, шул хәтле кызыктыра, әйтерсең дөньяда әдәбияттан, шигърияттән гүзәлрәк бернәрсә юк!” (226) Р.Төхфәтуллин үзен әдәбият дөньясына алып кергән, аның сихрилеген, гүзәллеген таныткан әдәбият укытучылары Фәхри һәм Нәфикъ абыйларына әле дә булса соклануын белдерә, беренче адымнарын искә ала.

Язучылар укытучыларның язмышларына да күпмедер игътибар бирәләр. Моңа бәйле рәвештә мәктәп–мәдрәсәләрдә укытуның торышы, халык наданлыгы мәсьәләләре күтәрелә.

Шул чор әдәбиятында ут уйнаткан үрнәк шәхес образлары һәр язучыда гәүдәләнеш ала. Г.Тукай образы Г.Бәшировта, Ш.Маннурда, Ф.Хөснидә сурәтләнә. Моннан тыш, Ш.Маннур һәм Ф.Хөсни,Ә.Еники, С.Баттал үз әсәрләрендә Һ.Такташ, Г.Ибраһимов, М.Җәлил шәхесләрен игътибарга алалар. Алар–язучыларга әдәбият мәйданына аяк атлаганда беренче юл күрсәтүчеләр. Димәк, маяк ролен үтәгән вакыйгалар, образлар кешенең киләчәгендә еш кына хәлиткеч әһәмияткә ия булып торалар. Шуңа күрә алар турындагы мәгълүмат өлкән “мин”нәрнең күңелендә саклана, хәтердә яңартыла.

Автобиографик әсәрдә образлылык язучының фантазиясенә бәйле дип билгеләп үттек. Г.Бәширов, Ф.Хөсни, Р.Төхфәтуллин әсәрләрендә төрле функция үтәүче метафора–вакыйгалар булуы документаль әсәрләрне әдәби әсәр итеп карарга мөмкинлек бирә.

Документаль әдәбиятның тагын бер төре *истәлекләр* дип атала. Алар шулай ук автобиографик характерда булалар, сөйләм беренче зат исеменнән алып барыла. Истәлекләрне автобиографиядән аерып торучы билге булып анда язучының сөйләм объекты үз шәхесе түгел, ә күргән, белгән кешеләре, ишеткән вакыйгалары тора дип, керештә аңлатып үтелде.

Автобиографик жанр белән беррәттән, 60–70 нче еллар әдәбиятында истәлек жанры аерым үсеш баскычына күтәрелеп, татар мемуаристикасының бер катламы булып яши башлый. 1972 нче елда С.Батталның “Баштан үткәннәр” истәлек–уйланулары, 1981 нче елда Ә.Еникинең “Соңгы китап” әсәре дөнья күрә.

Язучылар автобиографик язмаларының жанрын үзләре истәлек дип тәкъдим итәләр. Чынлыкта, автобиография һәм истәлекләр жанр ягыннан уртак нигезгә корылган булу сәбәпле, моны төгәл билгеләү һәрвакыт мөмкин дип әйтеп булмый. Анализлау нәтиҗәсендә, без бу әсәрләрнең автобиографик жанрга якын торуын ачыкладык.

Ә.Еники “Соңгы китап” дип исемләнгән язмаларының башында ук “үзем турында, мине чорнаган тормыш һәм кешеләр турында” сүз барачагын билгеләп үтә. Әсәрнең башыннан ахырынача ул үз шәхесен

күзәтә, һәр вакыйга, деталь, һәр әдәби күренеш шуңа хезмәт итә. Дөрес, без алда анализлаган әсәрләрдән аермалы буларак, әсәр уйдырмадан азат булуы белән игътибарга лаек. Бу хакта да автор үзе әйтеп үтә: “Язучы юкны бар итмәскә, барын яшереп тормаска тиештер дип беләм”[101].

Автобиографик әсәргә хас булганча, биредә язучы үткән белән бүгенгене бер үремтәдә тасвирлый. Әсәрнең структурасын шулай ук хис һәм фәлсәфә катламнарына аерып карый алабыз. Информация күп булуы, фактик материал байлыгы белән истәлекләр игътибарны җәлеп итә. Мисал өчен, әсәрнең башында Ә.Еники үзенең фамилия тарихына, морзаларга нисбәтле нәсел–нәсебенә кагылышлы вакыйгаларны үзәккә ала. Туып–үскән җирләре турында мәгълүмат, Каргалы халкының татар дип йөртелүе сәбәбе хакында мәгълүмат документаль фактларга корыла.

Истәлекләрне әдәби әсәргә якынайтучы өлеш булып, аның халык язмышы турында уйланулары тора. Әсәрнең буеннан буена өлкән “мин” ата–анасы турында сөйли. Алар белән горурлану, сагыну хисләрен ул аларга мөрәҗәгатьтә үк күрсәтә (әсәрдә ул аларга тормыштагыча атакай, анакай дип мөрәҗәгать итә). Нигъмәтҗан ага турында авылдашларының мактап сөйләве өлкән “мин”дәге атасына булган хөрмәт хисенең дәрәҗәсен арттыра. Нигъмәтҗан аганың “табигате белән егет кеше булуын сөйлиләр. Җитез хәрәкәтле, ачык күңелле, җор сүзле, уен–көлке яратучан иде диләр. Ул матур гына җырлаган да, гармун да уйнаган, оста гына биегән дә. Туйлардан һәм мәҗлесләрдән аны бер дә калдырмаганнар. Бизәгән мәҗлесләрне!... Хәтта аның яшь чакларын белүчеләрдән шуны да ишеткәнем бар: туй кайткан чакта ул төпкә җигелгән атка йөзе белән тарантаска карап атлана икән дә кияү белән кәләшкә гармун уйнап бара икән”. (16) Атасының сәүдәгәрлек кәсебе белән шөгыльләнүен өлкән “мин” дә хуплавы, беренчедән, аның үз эшенә мөнәсәбәте белән аңлатылса, икенчедән, Нигъмәтҗан аганың эчке дөньясы матурлыгына соклanудан килә. Чын сәүдәгәргә хас булганча корырак, катырак булырга тиешле атаның, киресенчә, “асылда хис кешесе”, “һәр җан иясен бик ярата торган кеше булуы” балада аңа карата хөрмәт хисен арттыра. Әсәрнең язылу чорында сәүдәгәр Нигъмәтҗан ага образы тәнкыйтьтә тискәре бәя алырга тиешлеген язучы алдан ук белә һәм аның бу һөнәрен пәйгамбәр һөнәре дип ассызыклый, яклый. Бу эпизодның әсәр эчтәлегенә керткән икенче бер мәгънәсе кешенең үз эшен яратып, белеп һәм чын күңелдән башкарырга тиешлеге турындагы фәлсәфи фикер. ( Нигъмәтҗан ага

[101] Еники Ә. Соңгы китап. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1987. – Б.59. (Алда җәя эчендә бит саннары күрсәтелә барачак)

сәүдәгәрлеген ташларга мәҗбүр булгач, чәйханә ача ләкин төп һөнәреннән аерылмый).

Әнисе Бибихадичә образы өлкән "мин" хәтерендә моңсу хисләр уята. Иң элек ул әнисенең яшь вакытын белмәвен, "ул туганда, төсе, бите һәм табигате белән башка булуын" – бераз картайган, тормыш авырлыгы баскан кеше булуын билгеләп үтә. Әнисе хәсрәтенең сәбәбе балаларының бер–бер артлы үлә баруы. Өлкән "мин" бу вакыйгага карата ачыну катыш гаҗәпләнү хисләрен түбәндәгечә сурәтли: "Мине иң гаҗәпләндергәне – ул чактагы кешеләрнең наданлыгы һәм көчсезлеге. Каргалы бит инде зур авыл, укыган кешеләре дә аз түгел, ә менә белеп–аңлап ярдәмгә килүче дә, һич югы дөрес киңәш бирүче дә булмаган. Бер фельдшер кисәге булган шикелле, ләкин ул да корчаңгы атларны гына дәвалый белгән, имеш". (20)

Кыскасы, әтисенең, яңа хакимият килү аркасында, яраткан эшеннән колак кагуы, халыкның медицина өлкәсендә надан булуы сәбәпле, әнисенең иртә картаюы өлкән "мин"нең иң тирән даими борчуы. Ул халыкның яман хәленә бәя бирә, кечкенә "мин" аңламаган хакыйкатьне җиткерә.

Г.Бәширов, Ш.Маннур һ.б. шул чор язучыларның автобиографик әсәрләрендә төрле алымнар белән әдипләрнең фәлсәфи, сәяси фикерләре бәян ителә, дидек. Ә.Еники исә мондый рухтагы фикерләрне турыдан–туры белдерә. Әсәрнең башыннан ахырынача кешене кеше итүче асыл сыйфатлар бөртекләп тасвирлана. Болар безгә өлкән әдипнең үз шәхесен бәяләү мөмкинлеге бирә, аның күңел дөньясына алып керә. Язучының тормыш вакыйгалары арасыннан сайлап алынган һәм әсәргә кертелгән фактлары беренче чиратта шәхеснең бүгенгесе турында сөйли. Һичшиксез, бу фикерне һәр автобиографик әсәр авторына нисбәтләп булыр иде. Ә.Еникигә килгәндә, ул тудырган образларның, хәтерендә яңарткан шәхесләрнең күңел кичерешләре язучының рухи дөньясына тәэсир итә дип билгели алабыз. Истәлекләрдә язучының әтисе белән әнисе – шәфкатьлелек, миһербанлылык символлары; әбисе белән бабасы гаделлек, дөреслек, иман сагында торучы кешеләр буларак идеаллаштырып гәүдәләндерелә. Бабасының чирәмгә кара җилән җәеп намаз укыганы өлкән язучы күңелендә, сабый чагыннан (дүрт яшьлек чагыннан) калган тәүге матур хатирә булып, тирән уела. Шунда ук малайның шатлыгы, бабасына соклануы ассызыклана. Әбисенең үлеме – кечкенә вакытта истә калган иң тетрәндергеч вакыйга. Бу хис шулкадәр көчле һәм авыр була ки, ул гомере буе "үлем–бетемнән бик нык ятсынып яши: "Хәзер дә ниндидер бер мәҗбүрият мәет янына барырга кушса, мин аның йөзенә ничек тә карамаска тырышам. Әмма бу һич тә куркудан түгел. Кешенең тере кыяфәте һәм мәете шул хәтле бер–берсеннән ерак,

гайре табигый нәрсә ки, мин, күрәсең, шуңа тиз генә ышана да, ияләшә дә алмыйм". (29–30) Биредә сабый чакта күңелдә калган вакыйганың, шуның белән бәйле хисләрнең кешенең киләчәк тормышында, үз–үзен тотышында ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуы ассызыклана. Кеше һәм аның киләчәктәге эш–хәрәкәтләре белән еш кына аңның икенче катламы ("подсознательное") идарә итә. Тормыштагы күп вакыйгалар, кичергән хәлләр типкеле тәэсирле булган очракта, аңсыз өлештә саклана. Ә.Еники шундый кичерешләргә аерым игътибар бирә.

Әсәрдә гадел кеше темасы үзәк мотивларның берсе булып тора. Әбисе, бабасы, үрнәк шәхес образлары аша автор бу мәүзугны бөтен тулылыгында ачуга ирешә. Язучы картларның саф күңелле, гадел, иманлы булуларына басым ясый. Мисалга, әбисенең төп йортта кем калу мәсьәләсен хәл итүендә, аның кешелеклелек дәрәҗәсе ачыклана. Нигъмәтулла, төп йортны салуга көче кергәнгә, үзенең йортка хакы күбрәк икәнлеген яхшы белә, ләкин әбекәй йортны Мөхәммәдьярга калдыру ягында. Шул вакыт Нигъмәтулла йөзен каплап елап җибәрә, һәм кайгыртучан ана салмак һәм җитди итеп болай ди: "Нигъмәтулламның бу өйдә хакы күбрәк икәнен мин белмичә, кем белсен. Дөрес әйтә ул, иңнәрендә күтәрде... Ходай шаһит, улларым икесе дә миңа газизләр... Ләкин мин аларның чамаларын да беләм бит. Нигъмәтуллам иншалла, өйсез калмас, яңасын салырга да хәленнән килер. Ә Мөхәммәдьярга авыр булачак. Төп нигездән аерырга ярамый аны". Язучы авыр һәм четрекле мәсьәләнең ананың зирәклеге ярдәмендә уңай хәл ителүен күрсәтә. М.Вәлиев сүзләре белән әйткәндә, кешелеклелек ул – "кешеләр меңләгән еллар дәвамында яши–яши күп мәртәбәләр сынап килгән һәм нык ышанган әхлак кануннары буенча яшәү дигән сүз. Көче әзрәк булганга ярдәм итәргә кушучы, аңа мәрхәмәтлерәк карарга кушучы катгый кануннар, ныклы принциплар таләбе буенча дигән сүз"[102]. Өлкән буынның түземле, кайгыртучан, алдан күрүчән булуы ассызыклана, өлкән "мин" яшь буынга үгет–нәсихәт бирә. Бер–береңне рәнҗетүдән курку кешенең иманлы, югары әхлаклы булуыннан килә дигән фикер башка вакыйгаларда да кабатлана. (Мисалга, Хәмит, Нигъмәтулланың хатыны Мәдинә белән бәйле вакыйгалар).

Автобиографик әсәрдә традицион рәвештә үрнәк шәхес мәсьәләсе күтәрелә дип билгеләп үттек. "Соңгы китап" повестенда өлкән "мин" күңелендә чын кеше образы булып сакланган Шәриф Сүнчәләй, матур татар хатын кызы образы Мәдинә, Сәгыйдә, чын мөгаллимнәр Габдрахман абзый белән Мәрзия апа образлары игътибарны җәлеп

---

[102] Вәлиев М.Х. Каһарманнар кирәк! – Казан: Тат.кит.нәшр., 1990. –Б.190.

итәләр. Шәриф Сүнчәләй – малайның җизнәсе – аны кечкенә вакыттан ук әдәбият дөньясының матурлыгы белән таныштыра, китаплар белән сихерли. Ә.Еники аны болай искә ала: “Ул тыныч, сабыр кеше иде, бик мөлаем һәм тыйнак кеше иде, тавышы да йомшак, кешегә мөгамәләсе дә йомшак иде. Үзе озын гына буйлы, какча гына кеше иде, бик пөхтә киенеп, гел чиста кырынып йөри иде. Болары тышкы яклары, ә эчке яктан ул үтә әдәпле, инсафлы, нәзакатьле – кыскасы, аңарда гүя тумыштан ук килгән үзенә бер күркәм затлылык бар иде. Мондый ирексездән сокландыра, хөрмәт кузгата торган затлылык гадәттә иске интеллигентларда күбрәк очрый... Ихтимал, шуңа күрәдер мин Шәриф җизнине үрнәк бер кеше итеп саный идем”. (50–51) Шунда ук язучы аның кебек затлы була алмавы һәм чын кешелек сыйфатларын ялгыш кына булса да бозуы өчен курка, борчыла. Күренгәнчә, өлкән әдип зыялы, затлы булуы белән үзеннән нур бөркетеп торган кешеләрне үрнәк саный. Шул ук вакытта лирик герой үз шәхесенә бәя биргәндә алар дәрәҗәсенә җитә алмавын ассызыклый. Биредә Ә.Еникинең тыйнаклыгы һәм үз–үзенә таләпчәнлеге сиземләнә. Укучы, әсәр белән танышу барышында, язучы образында да Шәриф Сүнчәләйдәге матур сыйфатларны күзәтә. Үзе шуңа омтылмаган кеше бервакытта да яхшы кешеләрне тиешенчә бәяли алмый, дигән хакыйкать бар бит әле.

Лирик герой хәтерендә саф күңелле, йомшак табигатьле Сәгыйдә образын яңарта, аңа мәдхия укый. Гомумән, Хәмит белән Сәгыйдә гаиләсе – дөнья байлыгына кызыкмый, тормышларын салмак, бер көйгә җайлы гына алып бара торган матур гаилә үрнәге: “Килгән саен, безне бу өйдә бик теләп, куанып каршы алалар, хәзинәдә бары белән чын ихластан сыйлыйлар” (99). Гаилә учагын сүндермичә саклый белүдә, ирен ир дип хөрмәтләп, тормышны гади, җайлы алып баруда Сәгыйдәнең роле зур: “... Сәгыйдә... чын авыл җиңгәсе, ачык, сүзгә юмарт, кунакчыл. Гәүдәгә ул Хәмиттән күп тазарак, әмма чебеш кебек – шулай сизелә”. (98) Хәмит тә – гап–гади авыл кешесе, елмаеп сөйләшә, бер дә иренмичә гәпләшә, кәефе килсә җырлап та җибәрә. Габдрахман абзый белән Мәрзия апа образларында язучы тормышның барлык авырлыкларын иңгә–иң күтәргән сабыр, киң күңелле чын мөгаллим сыйфатларын туплый. Әдип фикеренчә, яхшы кешеләр башкаларга яшәү дәрте бирерлек, рухи таяныч була алырлык көчкә ия: “... яхшылар да, начарлар да иртәме–соңмы бу дөньядан китәләр. Начары кеше буларак шунда ук онытыла, ә яхшысы гомер буена диярлек онытылмый. Әгәр аның кайбер сыйфатларын балаларында да күрсәң, кешеләргә ничектер ышаныч арта, тормыш үзе дә яктырак, рәхимлерәк тоела”(103 )

Ә.Еники һәм Г.Бәширов әсәрләрен берләштереп торучы мәсьәлә – туган туфрак мәсьәләсе. “Сезне автобиографик повесть язарга нәрсә мәҗбүр итте?” дигән сорауга Г.Бәширов болай дип җавап бирә: “Безне тудырган туган туфрак бар бит әле. Тукай белән Такташны, Җәлил белән Фатих Кәримне, Сәйдәшевне һәм Яруллинны тудырган җир бит ул. Бөек Ватан сугышының йөзләгән геройларын, бүгенге тыныч тормышның фидакарь кешеләрен тудырган җир. Мин әнә шул җирнең нинди икәнен үзем өчен, шул нәүбәттән укучы өчен дә күңел күзеннән үткәреп карарга теләдем. Җиде юл чатында, тарихның усал җилләре астында гасырлар кичергән, ике катлы изү–җәберләргә дучар булган халык ничек соң исән калган. Ниһаять, ул үзенең күп гасырлык культурасын нинди могҗиза белән саклап кала алган?” [103]

Ә.Еники әсәренә лирик–фәлсәфи чигенешләр кертеп җибәрә. Туган туфрак турында уйланулары әсәрнең башында ук урын ала, биредә ул күп дистә еллар аша кайтып, бала һәм үсмер чакларын күрергә теләвен белдерә. Бу фикер кабатланып килә һәм әсәрнең идея–эчтәлегендә аерым әһәмияткә ия булып тора: “Бер уйласаң, бу сәер дә тоелырга мөмкин. Җитмеш елдан артык гомеремнең бары унбиш елы гына Дәүләкән өлешенә тия бит, калганы гел читтә, еракта узды. Әмма ул унбиш ел минем гомерем башы–иң саф, иң самими, иң гөнаһсыз чагым. Нәкъ шушы чакта адәм баласында хыял канатлану, мәхәббәт кабына түгелме соң?! Югыйсә, җитмештән узгач та кайтып йөрү нигә кирәк икән?..”(89)

Өлкән “мин” күңелендә үткәнне хәтерләтеп торучы детальләр саклана. Алар кечкенә “мин” өчен дә, өлкән “мин” өчен кадерле туган як образын тудыралар. Бабасының кайнап торган самовар морҗасыннан утлы күмергә кечкенә лимон төшереп җибәрүгә, өйгә таралган хуш ис, туган туфракның ачы әрем исе һәм саф тирес исе өлкән “мин”дә сагыну катыш моңсулык тудыра. Әсәрдә туган җиренең нигъмәте кымыз – турында өлкән “мин” горурланып һәм аның бетә баруына борчылып яза. Гомумән, лирик геройның моңаю хисе әсәрнең үзәк мотивы булып тора. Әсәрнең башыннан ахырынача язучы хиснең эчтәлеген ача бара. Өлкән “мин”нең борчуы, тирән хәсрәтенең сәбәбе – “гомернең сизелмичә” үтеп китүе. Бу фикер күп тапкырлар кабатлана, һәм шуңа бәйләп адәм гомеренең бик кыска булуы турындагы үкенечле хакыйкать ассызыклана. Шундый ук югары пафос белән бу фикер И.Газидә дә урын ала. Ә.Еникидә: “Бер уйласаң, кызганыч та инде без, кайчан гына әле яланаяк, күлмәк–ыштаннан гына шушы күл әйләнәсендә кармак күтәреп йөрүче малайлар идек, ә хәзер? Юк, кыска. Бик кыска адәми затның гомере!”

---

[103] Ахунов Г. Җир һәм күңел җылысы / Әдәби язмышлар. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1970. – Б.64 .

(108) И.Газидә: “Менә бүген дә ... Шул ук кояш. Ай да шул ук. Йолдызлар да. Ике тау арасындагы чишмәләр дә... Агайлардан тау башында каберләр генә калган... Кырык–илле ел эчендә шундый мәңге үзгәрмәс шикелле тоелган авыл танымаслык булып үзгәрде”. (303) Гомер кыскалыгы турында хакыйкать өлешендә интонациянең үзгәрүе бу очракта лирик геройлар кичергән үкенү хисен иң югары ноктада күрсәтә.

Моннан тыш, Ә.Еники табигатьне саклау мәсьәләсенә аерым игътибар бирә. Түбәндәге өзектә фикер үсешен күзәтү кызыклы: “...шушы кыска гына гомерле адәмнең кодрәте чамадан ашты: мең ел гына түгел, миллион еллар сакланып килгән табигатьне соңгы егерме–утыз ел эчендә генә ничаклы үзгәртеп, бозып бетерде. Һәм бу үзгәрешләр Япраклы күлнең тирә–ягында да бар. Әнә каршы яктагы киң тугайны аркылы бүлеп, дамба сузганнар... Ни өчен, нинди максат белән? Ишетүемә караганда, кайчандыр Дәүләкәннән Стәрлетамакка юл салырга уйлаганнар һәм бу дамбаны шуның өчен күтәргән булганнар. Ләкин соңыннан, юл үткәрүне бу төштә кирәксез табып, эшне туктатканнар. Ә дамба калган, хәзер ул, оборона ныгытмасы шикелле, бөтен тугайны ямьсезләп, күпме печән бирә торган болынны алып тора”. (108) Өзектән аңлашылганча, экологик проблема кешенең гомер озынлыгы белән бер тәңгәллектә куела. Бу фикерләрдә дә аһәң үзгәреше сизелә. Гомумән, әлеге әсәрләрдә беренчел, саф матурлыкны югалтудан туган тирән сагыш, моң, элегик аһәң геройның кәефен билгели торган нота булып тора. Элегик герой үз яшәешенең индивидуальлеге, үткәненең беркайчан да яңадан әйләнеп кайтмаячагы турында моңсулык катыш горурлык белән сөйли.

Язучы игътибар иткән тагын бер проблема – татар һәм башкорт халкының милли һәм дини йола–гадәтләре югала бару мәсьәләсе. Бу яктан да Г.Бәширов белән Ә.Еники әсәрләре аваздаш. Һәр язучы бу турыда мәгълүматны шул йолаларның матурлыгына соклану хисе белән үремтәдә бирә. Ә.Еникидә малайларның кичке азан тыңларга бару шатлыгы, Дим өстендә җомга көн саен, көймәләргә утырышып, гармун һәм мандолинага күңел ачулары һ.б. тасвирлана. Шунда ук өлкән “мин”, бу гадәтләрнең сакланмавына үкенеп, болай ди: “Әйе, кайчандыр иде бу, ә менә хәзер егерме биш ел буена кайтып–китеп йөрим, әмма Дим өстендә бер генә тапкыр да җыр, гармун тавышын ишеткәнем юк!... Беткән, онытылган бу матур гадәт, ләкин аның каравы моторлы көймәләр ярларны ишә–ишә колак тондырып чабалар. Әйе, үзгәрешләрнең төрлесе була–куандырганы да һәм уйландырганы да”(97).

Туган җиренең табигате – аның өчен иң гүзәл, шифалы табигать. Үзен үстергән, кеше иткән нәрсәләр дип өлкән язучы өч әйберне – “саф һава, өзлексез хәрәкәт һәм табигать җимешләрен” атый. Истәлекләрнең иң

мөһим сюжет сызыгы булып, татар милләте белән горурлану, аның иң асыл сыйфатларын билгеләп үтү тора. Тыйнак, сабыр, акыллы татар хатыны образлары турында билгеләп үтелде инде. Дәүләкән “купичларының” иң билгелесе – аз сүзле, тыныч, горур Борһан абзый турында сокланып яза, аның сәләтле сәүдәгәр булуын билгеләп үтә. Шул җәһәттән язучы чор идеологиясенә мөнәсәбәтен белдерә: “Минһаҗ абзый зур купич булырга хыяллана. Әмма ләкин Минһаҗ абзыйның хыялы гамәлгә ашарга өлгергәнче, ул арада 1917 елның революциясе дә килеп җитә...” (121) Инкыйлаб барлык сәүдәгәрләрнең гөрләп барган эшләренә аяк чала, НЭПтан соң аларның кәсепләре юкка чыга: “Шул рәвешчә, бу кешеләрнең “купичлыгы” үз гомерләренә дә җитмәде. Аталары сәүдәгәр булмаган шикелле, сәүдәгәрлек балаларына да күчмәде” .(133)

Татар халкының башка милләтләр белән мөнәсәбәтен язучы публицистик рухта тасвирлый. Эткολдагы татарларның күршедәге немецлар, башкортлар белән тату яшәвен, татар–башкорт арасында тарихи уртаклык булуы турында да ул горурланып яза. Шул ук вакытта халыкның нинди генә милләттән булса да, үз гореф–гадәтләрен сакларга тырышуы, бергәләшеп яшәргә омтылуын ассызыклап үтә. Рус һәм немец милләтләре белән көнитешен сурәтләү беркадәр үзенчәлеклерәк төсмер ала. Бу ике милләтнең үзара мөнәсәбәтләре бераз киеренкерәк, бер яктан, тел киртәсе көчле, “аннары борыннан сакланып калган милли дошманлык та үзен сиздергәли”. Ләкин малай яшь немец кызына гашыйк була. Тел киртәсе булса да, алар бик матур аңлашалар. Бу вакыйгалар олы әдип күңелендә җылы хатирә булып сакланып килә.

Туган авылы белән бәйле кайбер атамаларның яшьләрнең хәтер сандыгыннан юкка чыгуы – аянычлы хәл. Борынгы озын көйләр урынына хәзер – кыска дәртле көйләр, кушаматлар урынына “фәлән–фәләневичләр”. Язучы үткәннең соклангыч аһәңен, табигыйлеген юксына: “ Ә матур иде ул, табигатьнең үзеннән алып, халык биргән исемнәр”. Өч мәчетле Каргалы авылы да юк икән хәзер. Гаиләләре торган зур таш йортның тәмам искереп, тузып бетүе аның күңелендә тагын да тирән хәсрәт уята, хәтта ул өйнең эченә керергә дә базмый: “Тышындагы үзгәрешләрне күрү дә җитәр, эчендәгесе... хыялымда сакланган килеш калсын, дидем, ахрысы”. Әсәрдә язучы тормышның, яшәешнең мәгънәсе турында кайта–кайта уйлана. Кырык елдан соң Каргалыда инде аны беркем дә танымый. Гомер агышының күз ачып йомганчы үтүе бик үк табигый түгелдер кебек тоела. Ә табигать кешенең уйларына,хисләренә битараф ул. Тормыш бер урында гына тукталып тормый. Еллар дусларны, туганнарны үзе белән алып китә тора. Тормышның өзлексез хәрәкәттә

булуы, салмак агышы олы әдипне кат–кат уйланырга мәҗбүр итә.Өлкән язучы балалык белән картлык бәйләнешләренең өзелмәвенә басым ясый.

Әсәр “Соңгы китап” дип атала, укучыда ирексездән бу атаманың мәгънәсен аңлау теләге туа. Әсәрнең буеннан–буена автор һәр кешенең кояшы котылгысыз рәвештә баюга бара дигән фикер үткәрә. Һәр җирдә урынлы фәлсәфи чигенешләр ясап, автор бу хакта кат–кат искәртә: “Дөньяда ике генә бәхәссез хакыйкать бар: туу һәм үлем. Без менә шул ике араны узабыз. Һәм үзебезне белә башлаган көннән алып, иң якыннарыбызны – ата–ана, кардәш–ыру, дус–ишләрне югалта–югалта килеп җитәбез соңгы сәгатебезгә”… (498)

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: Ә.Еники “Соңгы китап” әсәрендә теге яисә бу фикерен публицистик рухта хикәяләп бирә. Истәлекләрендә үз шәхесенең рухи үсешен күзәтү белән беррәттән, ул лирик геройга үз бәясен бирә. Шул ук вакытта укучы язучыны бөтен барлыгында күрә алу, тою мөмкинлегенә ия. Язучының алдан ук китапта ялган булмаячагын искәртүе истәлекләрнең ышандыру көчен тагын да арттыра. Бу исә укучы белән язучы арасын якынайта, бер–береңә ышануга корылган мөнәсәбәтләр булдыруга ярдәм итә.

С.Батталның “Баштан үткәннәр” әсәре жанры ягыннан истәлекләр–уйланулар дип төгәлләштерелә. Әсәрнең сюжет сызыгы – язучының тормыш вакыйгалары белән автор–геройның шул вакыйга–хәлләргә бәйле карашлары, фикерләре янәшә чагылдырыла. Композицион корылышы ягыннан әсәр кыска күләмле бүлекчәләрдән тора. Аларның исемнәре үзенчәлекле. Берничә бүлек Салих Батталның туган авылы Тигәнәле белән бәйле. Язучы һәр бүлекнең исемен “Безнең авыл” дип башлый. Бүлекчәләрдә авыл тарихы, чишмәләре, күлләре, телләре, көннәре, урамнары, яклары, “академиклары”, тилеләре турында сүз бара. Язучы әсәрнең жанрына мөнәсәбәтле юкка гына истәлекләр һәм уйланулар дигән төгәллек кертми. Автор күптән булган, башыннан үткән хәл–әхвәлләрне бүгенге өлкән язучының уйланулары белән янәшә куеп тасвирлый. Иң мөһиме, һәр вакыйгада лирик герой үзен, үз шәхесен эзли, күзәтә, бәя бирә. “Безнең авыл тилеләре” исемле бүлектә, дүрт тиле турында язып үткәннән соң, бишенче сәер кеше итеп, үзен атый. Әсәрдә тилелек категориясенә үзенчәлекле “фәлсәфи трактат” бирелә. Тилелекне ул “авыру түгел, ә гади хезмәт” дип саный һәм шуның турында фәлсәфә сатарга ярата. Үзен берничә урында надан, тиле дип бәяләп, автор бу сүзгә үзенчә яңа мәгънә өсти. Тилелек аның өчен иҗадилык, хыялыйлык, даһилык мәгънәсендә килә: “... даһи ул – хезмәт дигән сүз. Әлбәттә, хезмәт биржасында бирелә торган хезмәт түгелдер... Иҗат хезмәтедер. Һәрхәлдә, йөзләрчә кабат сәхнәдә куелырлык әсәр иҗат итә алганмын

икән, димәк, мин бу турыда фикер йөртә алам”. (282)

Автор берөзлексез үз шәхесенә мөнәсәбәтен ачыклый. Кайбер урыннарда үзе хакында турыдан–туры сөйләп китә. Очучылар арасында ул үзенең хыялыйлыгы белән аерылып тора: “Татар Салих Баталов башка төрле холык кешесе иде. Дәүрәк, әле авыраеп өлгермәгән, әмма яшь имәндәй төптән нык һәм тыгыз гәүдәле, киң, яссы, аз хәрәкәтләнүчән йөзле, сирәк елмая; гомумән, үз эченә бикләнгәнрәк кеше һәм, тыштан караганда, бигүк интеллектуаль түгел кебек күренә иде ул. Әмма бу беренче тәэсир алдагыч булып чыкты. Тиз арада мин Баталовның күп укыган һәм гомумән ул чак без яшәгән мохиттән өстен торганлыгын күрдем... Аның әдәбиятка мәеле дуслар белән үзара сөйләшүендә чагыла иде... Теләп һәм үз эшен белеп оча иде, әмма сикерүләре белән мавыгып китмәде (парашют белән сикерүләр турында сүз бара – Г.Г.)... Баталов яхшы иптәш иде... Кем турында булса да чит кеше фикерен шаярып әйтүдән дә үз–үзен тыя иде”. (345–346) Баттал–язучы бу фикерләрне төрле ситуацияләрдә кайта–кайта кабатлый, укучы белән үзен якыннанрак таныштыру өчен, холкы турында гел искәртеп тора, шул ук вакытта бераз чытлыклана, иркәләнә дә кебек. Лирик геройның хезмәткә мөнәсәбәте җитди икәнлеге билгеләп үтелде. Ул бервакытта да ялган, фальшь белән килешми, бу “укучы белән язучы арасындагы ышанычны югалтырга тырышучы шайтан” дип бәяләнә. (253) Әсәрдә фәлсәфи мәсьәләләргә аерым шәхеснең карашы гел тасвирлана килә. Әйтик, даһилыкны ул хезмәт белән, тырышлык белән янәшә куеп бәяли, шул ук вакытта “даһиларга карата чиктән тыш хөрмәт үзеңдә көчсезлек, коллык хисе уятырга да мөмкин” дигән нәтиҗә ясый. (323) Биредә тел, әдәбият, милләт мәсьәләләре ачыктан–ачык публицистик рухта яктыртыла. Мисал өчен, аның ике теллелеккә мөнәсәбәте бүген дә бик актуаль яңгырый: “Рус теле аша дөньякүләм мәйданга чыгабыз! Шул тел аша үзебез дә дөньякүләм әдәбият белән таныш”, – дип сөйлибез икән, бу тик өлешчә генә, шартлы рәвештә генә дөрес... Чишмәнең үзеннән эчми торып, әсәрнең шигърияте турында уй йөртү читен, бәлки мөмкин дә түгелдер. Тукай, Дәрдмәнд кебекләрне Шекспир, Байрон, Пушкин кебек даһилар рәтендәге урыннарда күрү үзеңне дә башка халыклар белән бер сафта итеп сизәргә ярдәм итә, аларны тудырган халыкка ихтирам уята”. (323)

Үз туган әдәбиятың белән горурланырга өйрәнмичә торып, башкалар турында, халык турында сөйләшү мөмкин түгел дигән хакыйкать ачыктан–ачык яктыртыла. Шунда ук әдәбият мәсьәләләренә караган фикерләрен дә бәян итә. Истәлекләрдә Һ.Такташ, Г.Ибраһимов белән очрашулары турында горурланып та, рухланып та яза. Һ.Такташ яшь

язучыга үз юнәлешен табарга ярдәм итә, үз–үзеңә ышанычның бик зур әһәмияткә ия булуын билгели: “Язучыда шундый ышаныч булырга тиеш, – диде Такташ. Әйтик, мин кулыма каләм алам икән, укучымны үземә ияртүемә ышанып язам. Юкса, мин язарга ук тотынмас идем... Яхшы, ышандыргыч әсәр укучы күңеленә әнә шулай барып төшә дә, анда ургып, таралып, аның күңелен биләп ала. Ә инде ышандырмый торган начар әсәр тискәре реакция тудыра”. (325) Г.Ибраһимов янында булып, С.Баттал аның зыялылыгына, затлылыгына югары бәя бирә, аның гаилә фаҗигасен аерып тасвирлый, тирән хәсрәтен уртаклашуын белдерә.

Шунысы мөһим: язучы фикерен интонацион үзгәрешләр, чигенешләр ярдәмендә сеңдереп үтә дә, бераз соңрак ниндидер вакыйга мисалында дәлилли. Мисал өчен, тиләләр һәм акыллылар каршылыгы турында фикер йөртеп, болай ди: “... чиләкләп тутырган акыллар үзләренчә зур бер эш куптарырга ниятләгәндә, уймак акылларның коты очып: – Нишлисез? Әллә акылдан яздыгызмы?! – дип кычкырулары мөмкин”.(241) Гроховский исемле конструктор турында сөйләп, шушы фикеренең хаклылыгын дәлилли. Гроховский Павел Игнатьевич – һава десанты идеясенең энтузиастларыннан берсе, балчыктан бомба ясап, фәндә яңалык тудырган үз фикерле, нык ихтыярлы кеше. Аңа, үз хылларын тормышка ашыру өчен, күп каршылыклар үтәргә туры килә, “нишлисез?” дип сөрән салучылар шактый була. Язучы бу кешене үрнәк шәхес итеп бәяли: “Ул буй җитмәс начальстволылыкның чиген кыю атлап үтә дә һәркем өчен бары тик олы, акыллы иптәш булып әверелә. Син үзеңне үзең белергә дә өлгермәгәнсең, тормышыңда әле берни эшли дә алмагансың, ә ул инде сүзләре белән һәм тавышы белән синең бик күп эшли алуыңны, ул эшләрне синнән көтүен әйтә һәм синең шәхесеңне хөрмәт итә башлый”. (341) Шундый үрнәк шәхесләр рәтенә автор тарихи шәхесләрдән Чкалов, Сафронов, Анисимов һәм башкаларны кертеп тасвирлый. Аларны берләштереп торучы уртак сыйфатлар – гадәттән тыш куркусызлык, нык ихтыярлылык, тәвәккәллек, гадилек һәм гаделлек. Автор кешедәге әлеге сыйфатларны иң кирәкле һәм затлы сыйфатлар дип бәяли: “Батырлык үзеннән үзе генә булмый, аны көрәш тудыра. Яшәү өчен, Дөреслек һәм Гаделлек өчен, яңа Белемнәр өчен көрәш”. (352) Лирик герой үзе үк әхлакый кануннар сагында торучы буларак күз алдына килеп баса. Авторның хатын–кызга бәясе дә кызыклы: “... хатын–кыз шулай ук биер өчен яратылган музыкаль бер мәхлук икән. Тик ашыкмаска, кирәкмәгәнгә көч сарыф итми, бары тик музыка ритмына буйсынып, үз хәрәкәтеңә партнершаны ияртергә генә икән”. (368) Шул рәвешле, С.Баттал “Баштан үткәннәр” истәлекләрендә үзенең тормыш турында фикерләрен бәян итә, теге яисә бу әхлакый кануннарны төрлечә бәяли, укучыга кызыклы

фәлсәфи трактат тәкъдим итә. Аның истәлекләре белән уйланулары янәшә килү укучы өчен авторга бәя бирү ягыннан аеруча әһәмияткә ия.

Билгеле, бу әсәрләрне автобиографик жанрга карый дип бәяләмибез. Истәлек һәм автобиография уртак нигезгә корылган жанрлар булу сәбәпле, саф автобиографик әсәр яисә саф мемуар дип билгеләү – каршылыклы мәсьәлә. Аерым урыннарда лирик геройның фикерләре ачыктан–ачык публицистик пафос белән белдерелә. Бу XX гасыр ахыры автобиографик әсәрен XIX йөз сәяхәтнамәсенә якынайта.

Бу бүлектә безнең максат 60–70 нче еллар татар әдәбиятына автобиографик жанрның яңадан кайту сәбәпләрен барлау, төп үзенчәлекләрен билгеләү иде. XX гасыр башы автобиографик әсәре белән бу чор автобиографик повестеның уртак һәм аермалы яклары шактый.

Беренчедән, авторның үз шәхесен ачарга, күңел кичерешләрен барларга, рухи үсешен күзәтергә, ниһаять, чор тарихында үз урынын билгеләргә омтылышы бөтен автобиографик әсәрләргә хас үзлек. Бу, Г.Исхакый һәм Г.Тукайдан башлап, 60–70 нче һәм 80–90 нчы еллар мемуар авторларында күзәтелә.

Икенчедән, автобиографик әсәрдәге лирик башлангыч жанрны лирика төре белән якынайта. Шул сәбәпле әсәргә анализ эпос һәм лирика төрләренә анализ алымнарын файдалануны таләп итә. А.Яхин фикеренә кушылып, без автобиографик жанрны ике катламга – хис һәм фәлсәфә катламнарына бүлеп тикшердек. Структур яктан Г.Тукайның “Исемдә калганнар” әсәре 60–70 нче еллардагы автобиографик әсәрләр белән уртак. Һәр әсәрдә лирик геройның теге яисә бу вакыйгага бәйләнешле рәвештә хисләре урын ала.

Өченчедән, автобиографик әсәрдә автор хикәяләүнең субъекты да, объекты да булып тора. Автор–өлкән “мин” яшь “мин”нең – үзенең балачагы вакыйгаларын күзәтә һәм бәяли. Шуның белән беррәттән, автобиографик әсәрдә яшь каһарман үзе ук бәяләүче ролен үти. 60–70 нче елларда язучылар балачак образын тудыруга аерым игътибар бирәләр. Гасырның икенче яртысында күп кенә әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүе – әдипләрнең уртак хәсрәте. Алар үз балачакларын бүгенге балачак белән янәшә куеп тасвирлыйлар. Кечкенә “мин”нең хисләренә сәбәп булып, балачак үзе тора.

Дүртенчедән, балачак үзе ике өлешкә бүлеп сурәтләнә. Бер яктан, язучылар 5–6 яшьлек сабый чакларын хәтердә яңартсалар, икенче яктан дөньяны аңлы рәвештә танып–белә башлаган чорны искә төшерәләр. Бу бүленеш Г.Тукайда ук күзәтелә.

Бишенчедән, һәр автобиографик әсәрдә гасыр башының тарихи вакыйгалары гәүдәләнеш ала.Шуларга бәйле рәвештә авторларның сәяси,

фәлсәфи фикерләре белдерелә. Ф.Хөсни, И.Гази, Ә.Еники әсәрләрендә ачлык вакыйгасы китергән фаҗига, Г.Бәшировта революция күренеше һ.б.лар өлкән әдипләр тарафыннан бәяләнәләр.

Алтынчыдан, илдәге тарихи вакыйгаларга бәйле рәвештә халык язмышы яктыртыла. Бу мәсьәлә Г.Бәширов, Ш.Маннур, Ф.Хөсни, Ә.Еники әсәрләренең үзәгендә тора.

Җиденчедән, автобиографик әсәр өчен реаль шәхесләрне әдәби образ дәрәҗәсенә күтәреп сурәтләү хас. Язучылар, кагыйдә буларак, әсәрнең каһарманнары ролендә әти–әниләре, туганнары, авылдашлары, дус–ишләре, беренче укытучыларын, үзләренә үрнәк булып торучы тарихи шәхесләрне тасвирлыйлар.

Ахыр килеп, автобиографик әсәрдә үткән белән бүгенге бер үремтәдә тасвирлана. Язучы балачагындагы, яшьлек һәм үсмер чорындагы вакыйгаларның хәзерге тормышында әһәмиятен күзәт

## Татар автобиографик повестенең жанр үзенчәлекләре

Бөтендөнья әдәбиятында мемуарларның туу тарихын гомумән фәлсәфә тууы белән бәйләп карау тенденциясе хөкем сөрә. Ксенофонтның “Воспоминания о Сократе” истәлекләре һәм грекларның хәрби походлары турында “Анабасис” дип исемләнгән язмалары документаль характердагы тәүге әсәрләр буларак билгеле. Урта гасырлар тарихында Пьер Абелярның “Минем бәла–казаларымның тарихы”, Дантеның “Тормыш”, Бабурның “Бабурнамә” әсәрләре билгеле, Яңарыш чорында Бенвенуто Челлини, Л.Сен–Симон истәлекләре игътибарга лаек.

XIX гасырда Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятында мемуаристиканың моңарчы күрелмәгән үсеше күзәтелә. Мадам де–Сталь, И.В.Гете, Стендаль, Г.Гейне, Х.К.Андерсен, А.Франц, Р.Тагор, Г.Манн, Р.Роллан, Ж.П.Сартр, Ф.Морлак һ.б.лар мемуар жанрның кыйммәтле үрнәкләрен бирделәр. Рус әдәбиятында декабристлар Н.И.Тургенев, И.И.Пущин, И.Д.Якушкин, М.А.Бестужева, әдәбиятчылар Н.И.Греч, С.П.Жихарев, Ф.Ф.Вигель, В.С.Печерин, цензорлар Е.М.Феоктистова, А.В.Никитенко, язучылар С.Г.Аксаков, А.И.Герцен, И.С.Тургенев мемуарлары кызыклы. Шулай ук башка профессия вәкилләре дә мемуар язмалар иҗат итүгә тартылды. Аерым алганда, юрист А.В.Кони, математик С.В.Ковалевская, дәүләт эшлеклесе С.Ю.Витте мемуарлары тарихи әһәмияткә ия.

Шул рәвешле, төрле чорда мемуар әсәрнең үсеше үзенчәлекле төсмер ала. XIX гасырның 50 нче елларында рус әдәбиятында мемуаристикага игътибар артуның сәбәпләрен Л.Я.Гинзбург түбәндәгечә нигезли: “Романтизм, в частности русский романтизм 30–х годов возбудил напряженное внимание к личности. Эпоха раннего реализма, отнюдь не утратив этот интерес, выдвинула требования психологической конкретности (самораскрытие романтической личности в конкретности не нуждалась), требование социально–истрической обусловленности изображаемого. В свете этих требований по–новому трактуется тема становления человека. В переходной для литературы период начала 50–х годов наблюдается повышенный интерес ко всевозможным мемуарам, автобиографиям, запискам, очеркам и пр.”[104]. Галимә фикеренчә, рус әдәбиятында романтизмның реализм юнәлешенә күчеш чорында күзәтелгән шәхес концепциясенә яңача караш, таләп мемуар жанрның үсешен тизләтә. Мемуар әдәбиятның үсешен, классицизм һәм сентиментализм чоры әсәрләреннән аермалы буларак, чынбарлык вакыйгаларын сурәтләүгә омтылыш белән бәйле рәвештә, Е.Е.Приказчикова бик вакытлы күренеш дип атый[105].

Рус әдәбияты фәнендә мемуар жанр ике юнәлештә өйрәнелә, аның үзенчәлекле табигатенә бәйле рәвештә, бердән, эстетик һәм, икенчедән, тарихи аспектта якын килү кабул ителгән. Автобиографик әсәрләрне болай өйрәнү сәнгатьчә үзенчәлекләрен дә, сюжетның фактик материалга корылуына бәйле сыйфатларын да иңләргә мөмкинлек бирә.

Автобиографик жанрның төп үзенчәлеге – тарихи һәм әдәби материалның бер үремтәдә тасвирлануында. Тарихчыларны әсәрдә урын алган төгәл фактлар кызыксындырса, әдәбиятчылар игътибарын әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше , әдәби кыйммәте җәлеп итә. Тарихчы әдәби әсәрдә бирелгән фактларга игътибар белән күзәтү ясый, аларның төрле сәбәпләр аркасында үзгәртелү мөмкинлеген исәпкә алып, сак эш итә. Атаклы тарихчы Е.В.Тарле мемуар һәм автобиографик әсәрләрдәге фактларның төгәллеге турында болай ди: “Мемуар әдәбиятның эчтәлегенә, хәтта язучы чын дөресен язам дип исбат иткән очракта да, аның шәхесенең сыйнфый һәм милли үзенчәлекләре, симпатия һәм антипатияләре йогынты ясый”[106]. Бу фикерне И.Белявский һәм А.Пронштейн да куәтлиләр. Мемуарларны анализлау өчен, тарихчының психолог булуы да таләп ителә: авторның

---

[104] Гинзбург Л. “Былое и думы” Герцена. – Л.: Гос.изд–во “Худ.лит–ра”, 1957. – С. 13.

[105] Приказчикова Е. Записки кавалерист–девицы Н.А.Дуровой и военная мемуарная литература первой половины XIX века. Дисс. …. канд.филол.наук. – Екатеринбург, 1995. – С. 6.

[106] Тарле Е.Значение архивных документов для истории // Вопросы архивоведения. – 1961. – № 3. – С.101.

материалны сайлау үзенчәлеге, максат–ниятләре исәпкә алына. Бу – куелган мәсьәләгә тарихи–психологик караш үрнәге [107].

Үткән гасырның 90 нчы еллары әдәбият белемендә документаль әсәрдәге уйдырма һәм тарихи образларны аерып өйрәнү тенденциясе дә алга сөрелә. Бу исә тасвирланган вакыйгага социаль, тарихи һәм психологик аспектта бәя бирү максатыннан башкарыла. Бу караш Л.Гаранинның "Мемуарный жанр советской литературы" дигән хезмәтендә урын алган[108].

В.Г.Белинскийдан соң мемуар жанр теориясе күп кенә әдәбият галимнәре тарафыннан төрле яссылыкта өйрәнелә. Язучылар үзләре үк бу мәсьәләне әсәрләренә керештә ачыклап үтәләр. Мисал өчен, В.Г.Короленко "Замандашым тарихы" ("История моего современника") исемле мемуарларына керештә болай яза: "Хезмәтемдә мин мөмкин кадәр тарихи дөреслеккә хилафлык китермәскә тырыштым. Биредә мин кичермәгән, күрмәгән, чынбарлыкка туры килмәгән берни булмаячак"[109]. Герцен үзенең "Былое и думы" исемле автобиографик хезмәтен "шәхес тә ул юлыккан тарихның чагылышы (отражение истории в человеке, случайно попавшимся на ее дороге)"[110] дип атый. Ә.Еники "Соңгы китап" исемле истәлекләренә керештә шул ук фикерне ассызыклый: "... Язучы юкны бар итмәскә, барын яшереп тормаска тиештер"[111]. Шунда ук: "Үзем турында да, мине чорнаган тормыш һәм кешеләр турында да мин бары чын дөресен генә язарга тырышачакмын"[112], – дип белдерә. Күренгәнчә, мемуар әсәрләрнең төп принцибы – автор үзе яшәгән, күргән яисә "тап булган" үткәнне, тарихны үзгәртмичә, ничек бар, шулай тасвирлауга ирешү. Г.Г.Елизаветина, А.И.Герцен әсәре төзелешенең төп принцибы дип, хакыйкатькә якынаюны саный[113]. Бу фикер жанр теориясен барлауга караган һәр хезмәттә күзәтелә.

Ф.М.Головенченко мемуарларны "художестволы эпик әсәрләрнең бер төре"[114] дип билгели. А.Богданов, аларның художестволылык якларын өйрәнүне дәвам итеп, тар һәм киң мәгънәләрен аерып күрсәтә: "... в широком смысле – записи людей о событиях прошлого, которые они наблюдали или в которых участвовали... Основным условием для

---

[107] Белявский И., Пронштейн А. Некоторые психологические аспекты отражения действительности в исторических источниках // Известия Северокавказского научного центра высшей школы. Серия общественных наук. – 1974. – № 1. – С. 17–20.
[108] Гаранин Л. Мемуарный жанр советской литературы. Историко–теоретический очерк. – Минск, 1986. – С. 9–18.
[109] Короленко В. История моего современника / Собр.соч. Т.V. – М., 1954. – С. 8.
[110] Герцен А. Полн.собр.соч. Т. X. – М., 1954–65. – С. 9.
[111] Еники Ә. Соңгы китап. Истәлекләр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1987. – 58 б.
[112] Шунда ук. – Б. 3.
[113] Елизаветина Г. "Былое и думы" А.И.Герцена. – С. 24.
[114] Головенченко Ф. Введение в литературоведение. – М.: Наука,1964. – С. 259.

отнесения подобных записей к МЛ (мемуарной литературе – Г.Г.) в узком смысле слова по особому виду искусства слова является установка их авторов на образное воспроизведние жизни”[115]. Шул ук фикерне үткәреп, М.А.Жиркова болай ди: “автобиографиянең максаты – тормыш юлын эзлекле, этаплап яктырту. Мемуар әдәбиятта беренче урында тарих, көнкүреш кешеләр тора, алар автор образын каплап китәләр, әйләнә–тирә мохитне танып–белү үз–үзеңне танып белүдән өстен чыга”[116].

Л.А.Левицкий күрсәткән билгеләмәдә мемуарларның көндәлек характерындагы әсәрләр белән уртак нигезгә корылуы, охшашлыгына басым ясала: “... мемуары – повествование в форме записок от лица автора о реальных событиях прошлого, участником или очевидцем которых он был. По форме изложения, идущего как правило от первого лица, по хроникальности и фактографичности изложения, по отсутствию сюжетных приемов мемуары примыкают к дневнику – периодическим записям о событиях текущей жизни”[117].

Галимнәр автобиографияне мемуарларның бер төре дип күрсәтә. Ю.Б.Борев автобиография белән мемуарның аермасын түбәндәгечә аңлата: “Автобиография – авторның шәхси тормышындагы вакыйгаларны хәтердә яңадан тудыруы. Мемуар язучы яшәгән чорны тасвирлауны үзәккә ала. Мемуарларда автор чор яктылыгында гәүдәләнсә, автобиографиядә авторның яшәгән чоры образ буларак чагылыш таба”[118]. Бу билгеләмәдә мемуарларда автор һәм чор мөнәсәбәтләренә кыскача аңлатма бирелә. Күп галимнәр мемуар әсәрләрне берничә төркемгә бүлеп өйрәнә. Г.Г.Елизаветина текстны жанрлык хасиятләре яссылыгында, реаль вакыйгаларны тасвирлауда төгәллеккә нигезләнеп, әсәрнең сәнгатьчәлеге һәм документальлегенә бәйле рәвештә, сайлаган материалына авторга карап бәя бирү нисбәтендә тикшереп, мемуар текстларны түбәндәге төркемнәргә аерып карый:

1) автобиография (бары үзең турында гына сөйләү);

2) исповедь – тәүбә (үзең турында ачыктан-ачык сөйләү);

3) мемуар (күп очракта сәясәт тарихы);

4) истәлекләр (хронологик яктан төгәллек сакланмаган һәм эзлексез характерда тасвирланган материал)[119].

---

[115] Богданов А. Мемуарная литература / Словарь литературоведческих терминов. – М.: Наука, 1974. – С. 67.

[116] Жиркова М. Исповеди в романе Ф.М.Достоевского “Братья Карамазовы”. Дисс. … канд.филол.наук. – СПб., 1997. – С.5.

[117] Левицкий Л. Мемуары / Краткая литературная энциклопедия. Т. 4. – М., 1967. – С. 201.

[118] Борев Ю. Компьютерный словарь литературоведческих терминов. – М.,1996. – С. 101.

[119] Елизаветина Г. Жанровые особенности автобиографического произведения (Герцен, Руссо, Гете) / Герцен – художник и публицист. – М., 1977. – С. 4.

Рус әдәбияты галимнәре бу төркемләргә еш мөрәҗәгать итәләр. Б.Д.Кабдрахманов, документаль чыганакларның сәнгатьчәлек функцияләрен анализлап, югарыда күрсәтелгән классификациягә өстәмә рәвештә әдәби портрет жанрын тәкъдим итә, мемуарларның төп сыйфатларын билгели: “хакыйкатькә омтылыш, ретроспективлык, автор башлангычының әһәмияте, субъективлык”[120].

Г.А.Марахова хат жанрын мемуарларның бер төре итеп карарга тәкъдим итә. Ул мемуар әдәбият даими үсеш–үзгәрештә икәнлеген һәм әледән–әле аның яңа жанр формалары барлыкка килүен раслый[121].

З.Р.Сутаева мемуар прозаны документаль–биографик әсәрләр дип берләштерергә тәкъдим ясый, үз классификациясен бирә. Ул мемуар текстларга мемуарлар, язмалар, истәлекләрне кертеп карый. Мемуар белән күпмедер күләмдә “чиктәш”, ягъни документаль–биографик характердагы әсәрләр, шул ук вакытта кайбер сыйфатлары белән үзгә булган төрләр дип аерып чыгара:

а) автобиографик проза – мемуардан сөйләмнең беренче / өченче заттан алып барылуы, сюжетның язу моментына нисбәтле булуы белән аерылып торучы проза;

б) “көндәлек”, “журнал”да сюжет язу моментына нисбәтән карала, әдәби уйдырмага урын калдырыла;

в) сәяхәтнамәләр мемуар проза белән параллель рәвештә үсеш–үзгәреш кичерәләр;

г) биография өчен материаллар – мемуарлардан катгый документальлек, филолог өчен язылган фәнни характердагы хезмәт булуы белән аерылып торучы жанр;

д) әдәби портрет – романнан аерымланган очерк рәвешендә булуы ягыннан мемуарга охшамаган жанр;

е) мәзәкләр, үзара сөйләшүләр – кече жанр төрләре.

Сутаева, шулай ук, “әби хикәятләре” дип исемләнгән төрне аерып чыгарырга тиеш таба[122].

Күренгәнчә, рус әдәбият белемендә автобиографияне мемуар әдәбиятның бер төре дип күрсәтү тенденциясе өстенлек итә. “Әдәби энциклопедик сүзлек”тә автобиографик жанрга түбәндәге бәяләмә бирелә: “Автобиография (от греч. – autos – сам, bios – жизнь, grapho – пишу) –

[120] Кабдрахманов Б. Художественная функция документальных источников в контексте мемуаров Герцена “Былое и думы”. – С.4.

[121] Марахова Г. О жанрах мемуарной литературы // Ученые записки Горьковского пединститута. – Горький. – 1968. – Вып. 69. – С. 20–21.

[122] Сутаева З. Жанровые особенности автобиографической и мемуарной прозы (на материале творчества А.С.Пушкина, П.А.Вяземского, Н.Г.Чернышевского). – Дисс. … канд.филол.наук. – М., 1998. – С. 35.

литературно–прозаический жанр; как правило, последовательное описание автором собственной жизни... Литературную автобиографию не следует смешивать с автобиографией информационной, которая сводится к краткому (“анкетному”) изложению событий собственной жизни, с газетными интервью или автобиографиями, которыми писатели нередко открывают свои сочинения. Для автобиографического жизнеописания характерно стремление осмыслить прожитую жизнь как целое, придать эмпиричность существованию, оформленность и связность. Пишущий литературную автобиографию нередко прибегает к вымыслу, он “дописывает” и “переписывает” свою жизнь, делая ее логичнее, целенаправленнее”[123]. Сүзлектә автобиографик, мемуар, көндәлекләрнең аермасы да билгеләнә, алар арасында абсолют чик булмавы ассызыклана. “От мемуаров автобиография отличается тем, что ее автор сосредоточен на становлении истории своей души в ее взаимоотношениях с миром, тогда как авторы мемуаров интересуют прежде всего сам этот мир, люди, которых он встречал, события, которые он наблюдал и в которых участвовал. Для дневника (притом, что ее автор как в автобиографии ведет речь о том, что с ним произошло, что он передумал и перечувствовал) не характерен разрыв межде временем, о котором пишут; отсутствие этого временного интервала препятствует взгляду на собственную жизнь как на единое целое, который отличает автобиографию”[124]. Биредә автобиографик жанрның төп сыйфатлары ачыклана. Болар – авторның үткәнне бербөтен итеп күзаллавы, аны логик эзлекле, кызыклы итеп тасвирлау мөмкинлеге, шул ук вакытта үткән белән бүгенгенең бәйләнештә торуын күрсәтә алуы, субъективлык, тарихи фактка хилафлык китермичә, уйдырмага мөрәҗәгать итүе.

Татар әдәбият белемендә автобиографик жанр теориясенә аңлатма Г.Батталның 1913 нче елда дөнья күргән “Нәзарияте әдәбия” хезмәтендә үк урын ала. Әдәбият галиме Д.Ф.Заһидуллина фикеренчә, “автор сәяхәтнамә, мемуар жанрларын әдәби әсәр белән бер дәрәҗәгә куймый, аларның табигатендә сәнгатьлелек түгел, мәгълүмат бирү әһәмиятле икәнлекне күрсәтә”[125]. “Әдәбият белеме сүзлеге”ндә автобиография белән мемуарның якынлыгы язучының үз кичерешләре, үз бәяләре һәм фикерләренә таянган булуы белән аңлатыла. “Ләкин мемуар автор үзе шаһит булган кешеләр һәм вакыйгалар турында, ә автобиография исә, күпчелек очракта мин исеменнән сөйләнгәнгә күрә, авторның үзе турында

[123] Литературный–энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия, 1987. – С.12.
[124] Шунда ук. – С. 12.
[125] Заһидуллина Д. Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). – Казан: Татар.китап нәшр., 2000. – 152 б.

була[126]. Әдәбият галиме Ф.М.Хатипов “язучыларның истәлек язмаларында күп кенә әсәрләрнең тормыштагы конкрет вакыйгалар йогынтысында, аларны баштан кичерү, күрү яки шулар хакында сөйләгәннәрне ишетү нәтиҗәсендә иҗат ителүен искәртеп уза”[127].

Гомумән, мемуар проза әдәбиятның катлаулы төрләреннән санала. А.Ахматова мемуарларны хаклы рәвештә “непроявленный жанр” дип атый, Н.Шайтанов, әлеге билгеләмәне киңәйтеп, “катгый чикләре булмаган һәм кагыйдәләргә буйсынмый торган”[128] жанр дип билгеләми, белдерә. Беренче карашка, мемуар документаль һәм матур әдәбиятның чигендә торучы жанрны хәтерләтә. Әмма, икенче яктан, аның тарих фәненә мөнәсәбәте барлыгы көн кебек ачык. Шунысы мөһим: рус әдәбиятчылары озак еллар дәвамында мемуарларны беренче чиратта тарихи язмалар буларак өйрәнделәр. Бу караш нигезендә мемуарларның төп әдәби юнәлешләр белән мөнәсәбәте барланды һәм аларның матур әдәбият үсешенә йогынтысы игътибарга алынды. Г.Е.Гюбиева, Г.Г.Елизаветина, Г.Я.Гинзбург, А.Г.Тартаковский шул мәсьәләләрне хәл итү барышында матур әдәбиятка төгәллек, конкретлык кебек принципларны алып керүен күрсәттеләр[129].

Ике гасыр чигендә мемуарларны сәнгатьлелек дәрәҗәсе ягыннан классификацияләү юнәлеше күзәтелә. Б.Д.Кабдрахманов, “эстетик структураның булу–булмавына бәйле рәвештә”, мемуарларны ике төркемгә аера: “фактографик мемуарлар – коры фактларны гына бирүне күздә тоткан әсәрләр һәм чорның типик образлары аша документаль нигездә иҗат ителгән әдәби мемуарлар”[130]. Кабдрахманов фикере, безнең карашка, беркадәр төгәллек кертүне таләп итә. Беренчедән, һәр фактографик мемуарның сәнгатьлелек дәрәҗәсе үзенчәлекле булырга мөмкин. Шул ук вакытта һәр мемуар авторының әдәби әсәр алымнарыннан файдалануын исәпкә алу зарур.

Ю.Андреев хаклы рәвештә “укучы мемуар әдәбиятны әдәби һәм әдәби булмаган дип аерып карамый, чөнки сөйләм һәр очракта документаль характердагы конкрет “мин” исеменнән алып барыла, һәм

---

126 Әдәбият белеме сүзлеге/ Төз.–ред. Әхмәдуллин А. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1990. – 6 б.

127 Хатипов Ф. Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – 297 б.

128 Шайтанов Н. “Непроявленный жанр” или литературные заметки о мемуарной форме // Вопросы литературы. – 1979. – № 2. – С. 52–53.

129 Кара: Гюбиева Г. Этапы развития русской мемуарно–автобиографической литературы ХУШ в. Автореф.дисс. … канд.филол.наук. – М., 1969. – С.19.; Елизаветина Г. Последняя грань в области романа // Вопросы литературы. – 1982. – № 10. – С. 147–172; Гинзбург Л. О психологической прозе. – С. 448; Тартаковский А. 1812 год глазами современников // Военные дневники. – М.: Советская Россия, 1990. – С. 5–28.

130 Кабдрахманов Б. Художественная функция документальных источников в контексте мемуаров. – С. 9.

әсәрдә реаль чынбарлыктагы вакыйгалар тасвир ителә”[131], – ди. Бу фактор әдәбият белгече өчен зур әһәмияткә ия түгел. Язучы “мин”е белән әсәрдәге “мин”–герой һәр очракта да тәңгәл була алмый. Бу хакта хезмәттә алдарак сүз алып барылачак. Моннан чыгып, Кабдрахманов күрсәткән фактографик мемуарлар иң элек вакыйганы бөтен төгәллеге, ваклыклары белән тасвирлауга корылса, әдәби мемуарлар, беренче чиратта, укучыга авторның үзе, шәхес буларак формалашуы турында мәгълүмат бирә, дигән нәтиҗә ясыйбыз. Гомумән, “истәлекләр – кеше турында ачыктан–ачык сөйләшү ул”[132], – дип ассызыклый Л.Я.Гинзбург.

Автобиографик жанрдагы әсәрләрдә автор белән герой мөнәсәбәтләре мәсьәләсе фәнни әдәбиятта иң катлаулы нәзари мәсьәләләрнең берсе булып тора. Документаль әсәр уйдырмага нигезләнмәсә дә, аннан башка гына була алмый. Шул сәбәпле, автор шәхесенә, автобиографик язмадагы лирик геройның кичерешләренә, фикерләренә нигезләнеп, тулы бәя биреп булмый. Бу хакта әдәби тәнкыйтьтә бәхәсләр күп булды, төрле аңлатмалар яңгырады. Документаль жанр үзенчәлекләрен барлауга зур өлеш керткән рус галимәсе Л.Гинзбург түбәндәге фикерне белдерә: “Хәтта иң автобиографик дип саналган романда да автор һәм герой тәңгәл була алмыйлар, чөнки герой әдәби чынбарлыкка мөнәсәбәттә карала”[133].

XX гасыр башында ук рус әдәбиятының атаклы галиме М.М.Бахтин “Автор и герой в эстетической деятельности” дигән хезмәтендә автобиографик әсәрдә автор һәм герой мөнәсәбәтләре проблемасын фәлсәфи яссылыкта яктырта. Бу өлештә без, аның фикерләренә дә таянып, татар автобиографик әсәрендә автор һәм лирик герой мөнәсәбәтләренең үзенчәлекләрен барлауны кирәк таптык. Безнең максат – татар әдәбиятында автобиографик жанрның ни дәрәҗәдә классик таләпләргә туры килүен, камилләшкән булуын бәяләү.

Бахтин геройның аң үсешен, аның хис–тойгыларе эволюциясен авторның әлеге геройны тудыргандагы максаты, уй–теләкләре белән бәйләнештә күрсәтә: “Автор тәмамланган бөтеннең – әдәби әсәрнең актив берәмлеген тәшкил итә, шул ук вакытта әлеге бөтеннең һәр өлешенә трансгредиент хәлдә кала”[134].

---

[131] Андреев Ю. По законам искусства (О природе документальностей) // Вопросы литературы. – 1979. – № 2. – С. 31.
[132] Гинзбург Л. О психологической прозе. – С. 137.
[133] Гинзбург Л.Я. О психологической прозе. – С. 50.
[134] Бахтин М.М. Автор и герой в эстетической деятельности. Проблема отношения автора к герою / Эстетика словесного творчества,– М: Искусство,1986. – С. 16. (Алда җәя эчендә бит саннары күрсәтелә барачак)

Әсәр героен тудырганда, автор үзенең бүгенге карашлары, яшәешне күзаллавына таяна. Һичшиксез, аның бу чордагы фикерләре үткәндәге һәм, бәлки киләчәктәге фикерләре белән тәңгәл була алмый. Автор геройны бәяләгәндә, үзе яши торган чорның иҗтимагый, әдәп–әхлак кануннарыннан  чыгып эш итә. Һәр герой күпмедер дәрәҗәдә авторның үз–үзе белән көрәше нәтиҗәсе.(10) Чөнки образны үзе теләгәнчә бирү өчен, автор максатчан рәвештә аның чынбарлыктагы прототибының күп кенә сыйфатларына игътибар итми, кайберләрен тудырганда уйдырмага мөрәҗәгать итә.

Автор иҗат итә, әмма ахыргы нәтиҗәсен үзе күрә алмый, ул бары әсәрнең туу процессын гына контрольдә тота. Шуңа күрә язучы иҗат процессы турында берни әйтә алмый, ул тулаем үзе тудырган процесска керешеп бетә. (11) Моннан аңлашылганча, автор геройны тудыру процессы белән мавыга, үз шәхесенең геройда чагылышы белән кызыксына.

Автобиографик әсәрдә  язучының  бөтен табигатен, уй–кичерешләр эволюциясен эзләү – шулай ук каршылыклы мәсьәлә. Иң элек әсәр авторы үз шәхесенә мөнәсәбәтне үзгәртеп, үзенә башка кешеләр күзлегеннән бәя бирә алырлык дәрәҗәдә булырга тиеш.

М.Бахтин автор–герой мөнәсәбәтләренең өч төрен билгели:

“1. ... геройның автордан өстенлеге: аның эмоциональ–ихтыярый халәте, тормыш позициясе автор өчен зур кыйммәт булып тора, ул предметны герой бәясенә таянып кына күзаллый, башкача (геройдан читтә) ул ныклы һәм тотрыклы таяныч таба алмый.  (20)

2. ... авторның геройдан өстенлеге очрагында автор үзе иҗат иткән геройга тәмамланган төс, бөтенлек бирә, тулы канлы образ барлыкка китерә. Мондый төр герой ике юнәлештә үстерелә: беренчедән, герой, автор рефлексын үзләштергән хәлдә, автор шәхесеннән ераклаша һәм автобиографик моментлардан читләшә; икенчедән, герой шул ук хәлдә даими үсеш–үзгәрештә тора, яңара, ләкин тәмамланмый. Һәр тәмамланган моментка килеп туктау мизгеле геройны эчке, бервакытта да ачыктан–ачык белдерелә алмый торган сер–хикмәттән ераклаштыра. Автор өчен мондый герой үсеше чиксез дәвам итә, ул һәрчак яңара, төрләнә, “яңадан туа”.

3. ... геройның үз үзен иҗат итү очрагы. Бирелә герой тормыш–яшәешне үз күзлегеннән барлый, формалаштыра, андый герой, романтизм героеннан аермалы буларак, үз–үзеннән канәгать һәм тәмамланган характерда ”. (21,23–24)

Беренче очрак геройның автордан өстенлеге буларак билгеләнә. Автор шәхси ихтыярына бәйсез хәлдә үз шәхесенә башка күзлектән якын

килә, геройны үз шәхесе белән тиңли, ягъни герой ярдәмендә әхлакый кыймматләр, алдан билгеләнгән эстетик концепция үткәрә. Бу очракта хакыйкатьне тулы гәүдәләндерү күздә тотылмый, әдип уйдырмага киң урын калдыра. Икенче очракта М.Бахтин авторның геройдан өстенлеген билгели, герой үсеш– үзгәрештә тукталып калган, чикләнгән рәвештә күз алдына килеп баса. Өченче очрак – геройның үз–үзен иҗат итүе, ягъни язучының үз тормыш юлына, кичерешләренә эстетик аспектта якын килүе – без игътибарга алган кайбер автобиографик әсәрләрдә күзәтелә .

Г.Бәширов “Туган ягым–яшел бишек” әсәрендә балачакның тулы образын тудыра. Башкача әйткәндә, автор укучыга үзенең балачак портретын тәкъдим итә. Әсәр героеның үсеше турында әйтелгән фикерләр – авторның киләчәккә юлын билгеләүче уйлары, хыяллары, өметләре. Автор, үзенең бүгенге шәхесе сурәтенә нигезләнеп, үз героен тудыра, аның нәкъ менә бүгенге язучы күзлегеннән уңай дип табылган сыйфатларын аерып күрсәтә, димәк, шәхеснең үсеш юлын максатчан тасвирлауга ирешә. Ниһаять, әсәр герое авторны үзе тудыра, аның дөньяга карашларын ачып бирә. Повестьта шәхси бәхеткә омтылыш темасы малай–геройга бәйле рәвештә гәүдәләнә. Хыялы турындагы фикерне чикләнмәгән вакытка бәйләп тасвирлау авторның яшерен сере барлыгы турында сөйли. Үз бәхетен гомере буе көтүе аның бүгенгәчә табылмавы турында нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирә. Димәк, яшь геройның теләк–омтылышлары белән автор шәхесе арасында әйтеп бетерелмәгән уй–фикерләр сызыгы әсәрнең моңсу нотасын билгели.

Авторның геройдан өстенлеге һәм кире очрак башка әсәрләрдә күзәтелми. Бахтин күрсәткән төрләрдән геройның үз–үзен иҗат итү очрагы бу чор автобиографик әсәренең идея эчтәлегенә ачыклык кертә. Ф.Хөсни, И.Гази, Ш.Маннур, Ә.Еники, С.Баттал үз шәхесләре белән канәгать автор ролендә. Мисалга, Ә.Еники үзенең истәлекләренең ахыргы өлешендә “бөтен замандашларын санап чыгуын максат итеп куймавын” белдерә һәм сәбәбен аңлата: “Без – замандашлар, бер үк чорларны кичергән кешеләр, бер–беребезне күптән инде якын беләбез, һәм шушы нигездә башланып та китте безнең арадагы дуслыклар. Әмма дуслыкны чын иткән, нык иткән нәрсә – бер–береңә ышану... Кеше булып калуыбызга ышану дияр идем мин. Хәтерләр калганда да, бәхәсләр туганда да–теләсә нинди хәлләрдә дә”. (503) Автор тарафыннан замандашлары арасыннан язучы образын тудыру өчен кирәклеләре сайланып алына. Өзектән Ә.Еники өчен шәхеснең төп сыйфаты кешелеклелек, олы мәгънәдәге игелеклелек икәнлеге аңлашыла, шунда ук үз тормыш позициясенә югары бәясе ассызыклана. Димәк, автор әсәр герое белән горурлана һәм шәхес булып җитлегүе, үзбилгеләнүеннән

канәгатьләнү  хисе кичерә.

Ф.Хөснинең“Минем тәрәзәләрем” әсәре ахырындагы “ачыш” турында фикер автор белән герой мөнәсәбәтенә ачыклык кертә. Автор геройның шул фикергә килү юлын, аң үсешен күзәтә һәм ахыргы максатка ирешүен, шәхес булып өлгерүен төп интонацияне үзгәртеп, ягъни басым ясап әйтеп бирә. Икенче төрле әйткәндә, герой рухи эволюциясенең билгеле бер ноктага җитүен күрсәтә, бу нокта аның киләчәген билгеләүче кыйбла икәнлегенә билгели.

Ш.Маннур автобиографик герой образын үзенчәлекле бәяли: “Юк, зур шагыйрь, атаклы шагыйрь дә була алмады ул, зурлыкка бик омтылмады да бугай. Илле ел буена шигырьнең рядовой солдаты булып хезмәт итте. Ялгышлары да, үкенечләре дә булды. Бер генә көн яши торган ялтыравык бөҗәкләр дә шактый чыккалады аның кулыннан... Ярый әле вакыт дигән мәрхәмәтсез хөкемдар андыйларның күбесен шул ук куллары белән юкка чыгарырга мәҗбүр итте аны... Язучының бөтен бәхете–гомер буе эзләнү, гомер буе өйрәнү икән, дигән гади бер фикергә килде ул... Бу фикер аны кара көнчелектән сак булырга өйрәтте, бу фикер аны эшендә гади һәм намуслы булуны төп максат итеп йөртергә өйрәтте”. (492–493) Укучы күз алдында шагыйрь шәхесе бөтен барлыгы белән гәүдәләнеш ала. Биредә шулай ук автор үз шәхесеннән канәгать булуына басым ясый, герой автор шәхесенең шул үсеш ноктасына кадәрге юлын күрсәтә.

М.Бахтин үз хезмәтендә автопортрет язучы рәссам алдында торган бурычларны автобиографик әсәр язучы алдында торган бурычлар белән янәшә куя һәм түбәндәгечә билгели: “Первой задачею художника, работающего над автопортретом, и является очищение экспрессии отраженного лица, а это достигается только тем путем, что художник занимает твердую позицию вне себя, находит авторитетного и принципиального автора, это – автор художник, как таковой побуждающий художника–человека”. (35) Бу җәһәттән, галим әле тулы автопортрет булырлык чиста автобиографик әсәр очратмавын билгеләп үтә. Чөнки автопортрет кешене бөтен барлыгында тасвир итәргә тиеш ди. Автор, үзенең тулы сурәтен иҗат итү өчен, күпмедер вакытка табигый халәтеннән читләшеп, үзенә карата булган шәхси хисләрен исәпкә алмаска мәҗбүр. Шул очракта гына фотосурәттән үзгә булган чын автопортрет туу мөмкинлеге барлыкка килә. Язма–басма сүздә кешенең тышкы сурәте, сынлы сәнгатьтән аермалы буларак, башка игътибарга лаек детальләр белән баетыла. Болар рәтенә кешенең үз–үзен тотышы, йөреше, йөз чалымнарының төрле хисләргә бәйле рәвештә үзгәреше, кешенең

даими үсеш–үзгәреше нәтиҗәсендә балачак–яшьлек, картлык образлары һ.б. керә.

Ләкин, Бахтин фикеренчә, кеше үзен бөтен тулылыгында күз алдына китерү мөмкинлегеннән мәхрүм:“...собрать себя в сколько–нибудь законченное внешнее целое сам человек не может, переживая жизнь в категории своего я... В этом смысле можно говорить об абсолютной эстетической нужде человека в другом, в видящей, помнящей, собирающей и объединяющей активности другого, которая одна может создать его внешне законченную личность; этой личности не будет, если другой ее не создаст: эстетическая память продуктивна, она впервые рождает внешнего человека в новом плане бытия”. (37)

Нәтиҗә ясап, түбәндәге фикергә аерым игътибар итәргә мөмкин: автобиографик әсәр авторы, үз портретын тудыру, укучыга аны бөтен тулылыгында тәкъдим итү өчен, үз шәхесеннән читләшеп, аңа бөтенләй башка кеше күзлегеннән карарга, ягъни эстетик хәтеренә мөрәҗәгать итәргә бурычлы. Бары тик шул очракта гына ул мөмкин кадәр тулы объективлыкка ирешә ала. Шунысы мөһим: һәр автобиографик әсәрдә автор геройны мактау, данлау юлына баса. Бу исә авторның үзе белән әсәрдә сурәтләнүче “мин” арасында аерма барлыгын күрсәтә. Чөнки, кагыйдә буларак, “мин” категориясенә башка “мин”, беренче чиратта, тәнкыйди күзлектән якын килә. Бу җәһәттән, Ф.Хөсни, Ә.Еники, С.Баттал аеруча зур уңышка ирешәләр. Алар шәхси сурәтләрен иҗат итү барышында башка “мин” позициясен алалар, үзләрен чит күзлектән бәяләргә омтылалар, аннары үзләре инанган хакыйкатьне күрсәтәләр. Моңа мисал итеп Ф.Хөснинең үз шуклыкларына, ялгышларына юмор аша бәя бирүен, С.Батталның Баталовны башка очучы дуслары күзлегеннән “сәер” дип тамга сугуын күрсәтеп үтәргә мөмкин.

Башка жанрдан аермалы буларак автобиографик әсәрдә язучы аның субъекты һәм бер үк вакытта объекты булып килә ала. Бахтин фикеренчә, биография авторы герой белән тиңләшмәсә дә, бик якын позициядә тора: “ они как бы могут обменяться местами, поэтому–то и возможно персональное совпадение героя и автора за пределами художественного целого”. (140–141)

Шул ук вакытта автор әсәр героенда үзенең көзгедәге сурәтен тасвирларга омтыла, “көзгедәге сурәт” язучының үз шәхесе турында хыяллары белән тәңгәл килергә мөмкин.(141) Димәк, автор героена бәя – иң элек үзендә күрергә теләгән кешегә бәя ул. Бахтинча әйткәндә, “память прошлого всегда эстетизирована, память будущего – всегда нравственна”. Бу һәр автобиографик әсәрнең нигезен тәшкил итә. Алда билгеләп үткәнчә, һәр язучы – Г.Бәширов, И.Гази, Ш.Маннур, Ә.Еники, С.Баттал үз

әсәрләрендә үткәннең матурлыгын сурәтләүне максат итеп куя, шул вакыттан киләчәк өчен әхлакый кануннар алып баруларын билгели. Автор үз "мин"ен тәнкыйтьләгән очракта да, аклый һәм яклый, үзенең ялгышларын үткән заманга кайтарып калдыра, автор бүген шул үкенечле ялгышларны аңлаган, хакыйкатьне төшенгән, өлкән "мин" буларак бәяләнә. Билгеле, киләчәктә бу хакыйкатькә хилафлык китермичә, сайлаган юлны (үзләре дөрес дип санаган юлны) дәвам итү турындагы фикер ассызыклана. Шул сәбәпле әсәрдәге өлкән "мин" образы автор өчен абруй казанган герой.  Ә.Еники өчен кешелеклелек, мәрхәмәтлелек, Г.Бәширов өчен затлылык, олы җанлылык, милли хисләр, И.Гази өчен өлкәннәрне хөрмәтләү, С.Баттал өчен куркусызлык, белем, дөреслек, гаделлек, Р.Төхфәтуллин өчен мөлаемлык, тырышлык – иң югары әхлакый кануннар.

Автобиографик әсәр кысасына  кертелгән образлар еш кына авторның тормышка карашына теләктәш. Киресе булганда, автор аларны инкяр итә, кабул итмәвен билгели. (Әйтик, И.Газида ак велосипедның машина, мотоциклга алмашуы, Ә.Еники, Г.Бәшировта милли гореф–гадәтләрнең юкка чыгуына борчылу, С.Батталда, Ф.Хөснидә, Ш.Маннурда әдәбиятка очраклы рәвештә килеп кергән язучылар турында фикерләр һ.б).  Шул рәвешле, сөйләмне алып баручы әсәр героена әверелә. Иң мөһиме, автор үз әсәрендә тормыш вакыйгаларының бары  үзе турында билгеле бер фикер калдыра торганнарын сайлап туплый. Л.Гинзбург фикеренчә: "язучының лирик герое әйтергә теләгән фикерен аңлау өчен, тормыш фактларының никадәр күләмдә, ни дәрәҗәдә алынуын ачыклау зарур"[135]. Биографиянең шактый әһәмиятле өлеше аның үзенә якын кешеләрнең сүзләре, бәяләренә таянып хикәя ителә (әйтик, туу, сабыйчак шуклыклары, гаилә хәлләре, балачактагы милли гореф–гадәтләрне аңлау, төшенү дәрәҗәсе һ.б)  Язучы, әти–әнисе, туганнары, дус–иптәшләренең, үрнәк шәхесләрнең бәясен тупламаган очракта, үз шәхесе образын эчтәлекле, эзлекле сурәтләүгә ирешә алмас иде. Бахтин: "только тесная, органическая ценностная приобщенность миру других делает авторитетной и продуктивной биографическую самообъективизацию жизни, укрепляет и делает неслучайной  позицию другого во мне, возможного автора моей жизни,"– дигән нәтиҗә ясый.

Галим биографик сурәтләүнең ике төрен билгели: шуның беренчесе – героик авторга корылган биография. Аның нигезендә башкалар янәшәсендә батыр, герой булу, һәркемнең хөрмәтен, мәхәббәтен яулау, эчке һәм тышкы дөньяның төрлелеген иңләргә омтылу теләге ята. Икенче

[135] Гинзбург Л. О психологической прозе. – С. 207.

төр социаль–көнкүреш автобиография дип исемләнә (144) һәм тарихи–мәдәни кыйммәтләргә мөрәҗәгать итүне күздә тота. Бу төрнең үзәген социаль кыйммәтләр һәм гаилә традицияләре тәшкил итә. Әгәр беренче төр биография үз шәхесеңне данлауга, башкалардан өстенлеген, кабатланмас булуын сурәтләүгә корылса, биредә гадел һәм игелекле шәхес концепциясе үзәккә алына. Героик автобиографиядә үз чорының данлыклы шәхесләренә урын бирелсә, социаль автобиографиядә замандашлары арасында хөрмәт казанган тарихи шәхесләр гәүдәләнә. Ниһаять, биредә мәхәббәт дан–шөһрәткә ирешүнең бер ысулы түгел, ә тормышның мәгънәсе буларак кабул ителә.

60–70 нче еллар татар автобиографик әсәре, тулаем алганда, социаль автобиография үзлекләренә ия дип күрсәтергә мөмкин. Г.Бәширов, И.Гази, Ш.Маннур, Ә.Еники, Ф.Хөсни, Р.Төхфәтуллин һ.б. – һәммәсе шәхес концепциясен социаль–иҗтимагый аспектта күзәтәләр. Повестьларда тарихи вакыйгалардан алда төп геройның гаилә тормышы, көнкүреше төрле яклап гәүдәләнә. Мәхәббәт автор–геройның тормыш мәгънәсе буларак аңлашыла. Ата–анага, авылдашларга, замандашлары, дус–ишләренә, сөйгән ярга, үзе башкарган хезмәткә мәхәббәтне югалту һәр әсәрдә фаҗига буларак билгеләнә. Мәхәббәт тудырган матурлык – бәхет ул, диләр язучылар. Шул ук вакытта мәхәббәт – тыныч һәм иркен яшәү шарты дип искәртелә. Һәр герой гомере буе шуңа омтыла, шуны юксына, хәтерли, искә ала.

Алда билгеләп үтелгәнчә, алар гаилә хәлләрен иҗтимагый тормыш вакыйгалары, милләт язмышы белән үремтәдә тасвирлауга ирешәләр. Әсәрләрдә сурәтләнгән тарихи шәхесләр беренче чиратта – авторларның хөрмәтен яулаган замандашлары, милләттәшләре. Гасыр башындагы мәдәни иҗтимагый барыш автобиографик әсәр язучыларны билгеле бер юнәлештә уйланырга, нәтиҗәләр ясарга этәрде, гасыр ахырындагы сәяси борылышлар да мемуаристиканың яңа үсешен барлыкка китерде. Әсәр үзәгендә милләт язмышы өчен җаваплы, аның киләчәген үз киләчәге дип кабул итүче “мин–герой” торды. 60–70 нче елларда Г.Бәширов, И.Гази, Ш.Маннур, Ә.Еники әдәбиятта милли рух, гореф–гадәтләрне матурлык дип сурәтләсәләр, 80–90 нчы еллар мемуаристлары шул матурлыкның югалуыннан туган фаҗигане бәяләделәр. Ике чор мемуаристикасының җитди аермасы автор–замана–лирик герой мөнәсәбәтләрендә ачык күренә. Соңгы еллардагы мемуаристиканың үсешен күзәтү мәсьәләгә ачыклык кертергә мөмкинлек бирер.

Ике гасыр чигендә татар әдәбияты, рус һәм башка милли әдәбиятлар белән берлектә, хакыйкатьне яктырту юлында эзләнүләр, уйланулар юнәлешендә үстерелде. Әлеге күренеш әдәбиятның документаль дип

исемләнгән төренә ихтыяҗны көчәйтте. Автобиографик проза 60–70 нче елларда ил тарихына, аерым шәхескә игътибар арту нәтиҗәсендә үсеш кичерсә, 80–90 нчы еллар мемуаристикасы милли вәзгыять үзгәрешләренә бәйле рәвештә язучы, әдәбият белгече, киң катлам укучы кызыксынуын уятты. Бу күренеш жанрның язучы һәм аның тормышы, ул яшәгән мохит, катлаулы һәм каршылыклы замана, татар милләтенең сәяси аренадагы урыны турында яңа мәгълүматлар алырга мөмкинлек тудыру хасиятенә бәйле иде.

XX гасыр ахыры мемуаристикасы, әсәрнең язылу максатыннан чыгып, ике этапка бүлеп карала :

– 60–70 нче еллар – яшерен хакыйкатьне яктырту юлында эзләнүләр, аерым шәхеснең үз уйларын, кичерешләрен белдерергә омтылу чоры;

– 80–90 нчы еллар – шәхеснең үзе турында ачыктан–ачык сөйләп, ил, халык, милләт турындагы чынлыкны объектив сурәтләүгә омтылыш дәвере.

80–90 нчы еллар мемуар прозасының төп үзенчәлекләре нидән гыйбарәт соң? Бердән, гасыр ахырында мемуар проза жанр ягыннан төрләнде, хәтта яңарды. Бу елларда иң актив жанрлар булып *истәлек, уйланулар* торды. С.Батталның “Баштан үткәннәр” исемле уйлануларыннан соң бу жанрда Г.Ахуновның “Йолдызлар калка” (1979), Ә.Еникинең “Соңгы китап” (1987), М.Мәһдиевнең “Ачы тәҗрибә” (1993), Т.Галиуллинның “Замана балалары” (1993), А.Гыйләҗевнең “Йәгез, бер дога”(1997) әсәрләре дөнья күрде.

Автобиографик язмалар да мөһимлеген һәм кызыклыгын җуймады. А.Расихның өч кисәктән торган “Елларны чигерсәм” (Ишан оныгы (1990), Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр (1993), Тыныч еллар күләгәсендә (1997)), Ә.Баяновның “Минем кечкенә дөньям”, “Су өсләрендә пароход”, “Хыялда туган калам”, Л.Ихсанованың “Кемгә сөйлим серләремне”, Т.Галиуллинның “Гомер тәлгәшләре” (1999) повестьларында автор үз шәхесе яктылыгында замана образын тудырды. Р.Мөхәммәдиев, автобиографик характердагы “Утлы таба өстендә” (1996) әсәрендә сәяси идеология белән бәйле тетрәнгеч вакыйгаларны объектив гәүдәләндерүне күздә тотып, аның жанрын фаҗига дип төгәлләштерә.

Көндәлекләр, куен дәфтәрләре, хәтер дәфтәрләре дип аталган, тормыш–яшәеш, милләт турында фәлсәфи күзаллауны, үтеп баручы гомерне бүгенге белән бер үремтәдә тасвирлауны максат итеп куйган әсәрләр буларак Ф.Бәйрәмованың “Тәгәри китте йомгагым”, Ә.Борһановның “Туган якның җиле татлы”, Т.Миңнуллинның “Утырып уйлар уйладым”, А.Гыйләҗевнең “Күңелем серләре”, Ә.Баяновның “Уйлар дәрьясында” әсәрләрен билгеләп үтәргә мөмкин.

Документаль повесть жанры язучының шәхси тормыш материалы, истәлекләр белән тулыландырылып үстерелде (А.Вәлиевнең “Көйгән сакаллы мәхбүс”, “Истә, һаман да истә”, “Талантлар арасында”, Г.Ахуновның “Тимерханның эзләнүләре”, Р.Фәизевнең “Узган гомер–янган күмер” һ.б.). Болардан тыш, Ш.Галиевнең “Минем беренче гомерем”, М.Әхмәтҗәновның “Белем баскычлары”, Р.Җәмдихановның “Сагыну”, Ф.Галиевнең “Әтнә–күңелем билгесе”, Т.Миңнуллинның “Бетте көч, сынды кылыч”, К.Латыйпның “Үр арты үр”, Ш.Әхмәтовның “Дәһшәтле көннәрдә”, Ф.Маннаповның “Бабаемның тормыш фәлсәфәсе” һ.б. истәлекләр рәвешендә дөнья күрде. Документалистиканың башлангычы булган сәяхәтнамә жанрын М. Юныс “Юлда уйланулар” исемле әсәре белән дәвам итте. Соңгы елларда М.Мәһдиев, Т.Әйди юлъязмалары бу жанр үсешендә аерым бер баскыч булып тора.

Икенчедән, язучының төп максаты булып үз шәхесенең “рухи эволюциясен күзәтү” белән беррәттән, “үзе генә белгән” хакыйкатьне киң катлам укучыга җиткерү торды. 80–90 нчы еллар мемуары шәхеснең тормышта үз урынын табу, омтылышларын билгеләү мәсьәләсен күтәреп, язучының үз шәхесен аклау актын тудырды. Бу максатлар йөген автобиографик жанр гына күтәрә алмаганга күрә, мәйданга информацион мөмкинлекләре ягыннан киңрәк истәлекләр жанры килә.

Автобиографик проза исә мемуаристиканың башка жанр төркемчәләре белән кисешкән, баетылган халәттә үстерелә. Ә.Баяновның “Хыялда туган калам” тәгаен автобиографик язмалар дип күрсәтелсә дә, язучы, үз шәхесенә бәя биргәндә, чордашлары турындагы истәлекләргә дә мөрәҗәгать итә. А.Расихның “Елларны чигерсәм”, Т.Галиуллинның “Гомер тәлгәшләре” информация катламы ягыннан истәлекләргә якыная төшәләр. Язучылар үз башларыннан кичкән һәм “рухи дөньяларының калыплашуы барышында” билгеле бер роль уйнаган һәр вакыйганы ачыктан–ачык тасвирлыйлар.

80–90 нчы еллар документаль әсәре биографик сурәтләүнең М.Бахтин күрсәткән социаль–көнкүреш автобиография төренә карый һәм тарихи–мәдәни кыйммәтләргә мөрәҗәгать итүне күздә тота. Сөйләүче–герой, башка геройлардан аермалы буларак, әсәрнең эчке катламын тәшкил итә. Ул, ике сөйләм чигендә торып, я биография герое белән тәңгәлләшергә омтыла, яисә авторның үзенә якыная, кайбер очракта үзе турында ачыктан–ачык сөйләп аклану позициясен ала. “Хыялда туган калам” повестенда сөйләүче–герой бер өлештә автор образына кереп сөйли, кайбер урыннарда “Казан егете” буларак та гәүдәләнә. “Гомер тәлгәшләре” исә язучының шәхси хисабын хәтерләтә. Биредә әсәрнең лирик герое биографик геройга якыная, автор белән тәңгәлләшә.

Гасыр ахыры автобиографиясендә автор–герой мөнәсәбәтләре үзенчәлекле төс ала. Билгеләп үтелгәнчә, мондый язмалар ярдәмендә язучы үз шәхесен яклауга, тормышка карашын, кылган гамәлләрен, сайлаган юнәлешен аклауга ирешә. Автор, шәхес хакыйкатен раслау максаты белән, геройны билгеле бер кысаларга кертә, аңа тиешле күрсәтмәләр бирә, шәхси тормыш материалын әсәрнең язылу максатына буйсындырган хәлдә, геройның эчке дөньясын ача. Бу позициядә герой автордан өстенрәк тора, шуңа күрә әсәрнең эмоциональ фонын, пафосын герой үзе билгели. "Хыялда туган калам" язмаларында автор рәвештә гадел, игелекле шәхес турындагы фикерләрне даими кабатлый, үз шәхесенә бәя биргәндә, шул кануннарга таяна.

Ахыр килеп, гасыр ахыры мемуары, әдәби әсәр булудан бигрәк, документаль, тарихи чыганакка, публицистикага тартымлыгы белән үзенчәлекле. Шуның киресе – Ә.Еникинең "Кояш баер алдыннан" публицистик мәкаләләре мемуар прозага якынайтылган. Бу күренеш авторларны берләштергән милли хакыйкать темасын мөмкин кадәр тулырак, объектив ачарга омтылышлары белән аңлатыла.

Бахтин күрсәткән икенче төр автобиография авторы хәрәкәттә тасвир ителми, ул бары хикәяләүче һәм күзәтүче ролендә тора. Галим бу төр автобиографиянең ике яклы булуын билгели:

"1) Сам рассказчик–герой, изображенный изнутри так, как мы переживаем себя самого в герое своей мечты и воспоминаний, слабо ассимилированный с окружающими другими, в отличии от них он сдвинут во внутренний план, хотя разность планов обычно не воспринимается резко; он лежит как бы на границе рассказа, то входя в него как биографический герой, то начиная стремиться к совпадению с автором–носителем формы, то приближаясь к субъекту самоотчета–исповеди;

2) другие действующие лица, в их изображении много трансгредиентных черт, они могут быть не только характерами, но даже типами".(150)

Әлеге икепланлылыкны татар автобиографик повестена нисбәттә күзәтергә мөмкин. Үзенең табигате, күңел сурәтен тудыру өчен сөйләүче я башка образларга мөрәҗәгать итә, алар турында хикәяли, яисә, кылган гамәлләренә бәя биреп, үзе алдында хисап тота, яки авторның үзе белән тиңләшергә омтыла. Башка образлар, нигездә, әсәрнең икенче планында күзәтелә. Мисал өчен, Г.Бәшировның "Туган ягым – яшел бишек" әсәрендә автор җир кешесенең җыелма образын әтисе Бәшир яссылыгында, моң–зарлы татар халкының типик образын Әхмәт,

Фазуллалар аша, көчләп чукындырылган татар–мөселманнарны Бикә әби, Анный, Кируш образлары аша гәүдәләндерә.

Ә.Еникинең автобиографик герое автор белән тиңләшергә омтылуы ягыннан үзенчәлекле. Әсәр язучының шәхси хисабын хәтерләтә. И.Газинең “мин”е Ә.Еники героена охшаш. Һәр ике әсәрдә башка образлар типик образ дәрәҗәсенә ирешә алмыйлар.

Бу ике планга караганда, биографик геройның һәрвакыт күзәтүче һәм бәяләүче ролендә килүе аңлашыла. Аңа каршы якта торучы башка образлар мөстәкыйль һәм трансгредиент форма алалар.

Шунысы мөһим: автор белән герой арасында җитди каршылык була алмый. “Автор герой белән чагыштырганда, баерак һәм тулырак сурәтләнә алмый,  аңа иҗат өчен өстәмә моментлар хас була алмый, автор үз иҗатына геройларның тормышындагы конкрет булган хәлләрне генә кертә ала”. (151)

Геройның бөтен  фикерләре автор фикере белән тәңгәл, башкача ул үз–үзен аклый һәм яклый алмый. Алар бөтен уй–хыяллары, ышаныч–өметләре һ.б. кыйммәтләре ягыннан теләктәш, димәк, әдәби әсәр авторы белән чынбарлыктагы язучы – фикердәшләр. Шул сәбәпле автобиографик әсәрдә берьяклылык күзәтелә, ягъни ике “мин”  янәшә тасвирланган сурәттә дә, икесе өчен бертөрле уртак эстетик кыйммәтләр, тормыш позициясе бәян ителә. Бахтин сүзләре белән әйткәндә: “и здесь миры их почти совпадают, принципиального избытка нет в мире автора; нет принципиального самоопределения двух сознаний друг против друга (одного в жизненном плане – пассивного, другого  в эстетическом плане – активного)”. (152) Бу фикерне без алдагы бүлектә кат–кат искәреп килдек. Яшь “мин” өлкән “мин”нең фикерләрен үзенчәлекле тел–стиль ярдәмендә бәян итә. Шул рәвешле, автобиография – үз–үзеңә карап, башка кеше исеменнән язу, үзеңне беркадәр икенчерәк планда сурәтләү. Татар әдәбиятында бу традиция, Кол Галидән башланып, гасырлар дәвамында камилләшә. Автор үзен артык зурламый, мактамый, бары үзе турында искәртеп, билгеләп кенә үтә. Соңрак бу калып аерым жанр буларак камилләшә башлый. “Үзең турында үзең язу” жанры, структур яктан җитлеккәнче, үз–үзеңә юмор, ирония аша бәя бирү баскычын үтә. Гасыр башы язучылары, әдәп, тыйнаклык саклау йөзеннән, үз шәхесләре турында кимсетеп, беркадәр көлебрәк сөйләргә омтылалар (Г.Камал, Ф.Әмирхан). Г.Тукай үз шәхесе яктылыгында татар халкын күтәрә, милләтенең игелеге, ярдәмчеллеге турында яза. Бала аша икенче кеше исеменнән бәя биреп, ул шатлык тудырган хәсрәт турында яза. Тукайның кечкенә Апушны кызгандырырга теләмәве аның әхлакый йөзен күрсәтә. Бу тенденция Ә.Еники, Ш.Маннур, Г.Бәшировта күзәтелә. 60–70 нче

еллар автобиографик әсәрендә Тукайлар рухы, традицияләре беркадәр саклана. Гасыр ахырына таба лирик геройның икенче планда калу юнәлеше бөтенләй башка борылыш ала. Беренчедән, автобиографик әсәр авторы инде өлкән буын язучысы гына түгел, икенчедән, лирик герой автор белән тәңгәлләшә, еш кына үзен мактау, данлау, чиктән тыш күтәрү юлына баса, тормыш–чынбарлык вакыйгаларына “бик акыллы кеше” күзлегеннән бәя бирә. Моның өчен философ, чит ил язучыларының төрле гыйбарәләрен файдалана, эпиграф итеп ала. Башкача әйткәндә, үз тормыш позициясен яшерми, әсәрнең үзәгенә үзен, үзе генә таныган кыйммәтләрне чыгара.

Автор әсәрдә үзен бөтен барлыгы белән ачып сурәтләү максатын күздә тотмый. Әгәр аның тормышы турында барлык информация, хис–тойгылар аның “гомер китабына” тупланып–җыйналып бетсә, ул шәхес буларак үсүендә туктап калыр, дәвам итмәс иде. Шул сәбәпле бер генә автобиографик әсәр дә тәмамланган характерда була алмый. “Биография – это не произведение, а эстетизированный органический и наивный поступок в принципиально открытом, но органически себе довлеющем ближайшем ценностно–авторитетном мире”. (153)

Димәк ки, билгеле бер чор автобиографик әсәренең төп үзлекләре турында сүз алып барганда, биографик геройның фикер үсеше беренче чиратта, автор яшәгән һәм яши торган дәвер һәм шул дәвер билгеләгән кыйммәтләргә бәйле булуын исәпкә алырга тиешбез.

Биографик материал, һәр очракта укучыны күздә тотып әсәр буларак формалаштырыла. Димәк, автор позициясен укучы яулый .(153) Укучы язучының биографик материалын тәмамланмаган рәвештә кабул итә һәм үз хисләре, фикерләре белән тулыландырып баета. Моннан чыгып, авторга бәя бирә.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: укучы автор шәхесенә бәя биргәндә, беренче чиратта, авторның үз бәясенә таяна. Үз чиратында, автор бәясенең кыйммәте аның, геройны тудырганда ни дәрәҗәдә үзеннән аерылып, читләшеп, үз шәхесенә яңа күзлектән карый алуына бәйле. Автор, Бахтин фикеренчә, саф рәссам позициясендә торырга бурычлы.

Нәтиҗә ясап, шуны билгеләп үтик: без М.Бахтин, Л.Гинзбург һ.б. бер төркем галимнәрнең, автобиографик әсәрдә автор һәм лирик герой образы тәңгәл була алмый, дигән фикерен хуплыйбыз һәм моның документаль әсәрнең художестволы үзенчәлегенә бәйле булуын ассызыклыйбыз.

Автобиографик әсәрнең жанрлык хасиятләре аның структур элементлары белән билгеләнә. Беренчедән, автобиографик әсәр һәрвакыт үткәнне хәтердә яңартуны күздә тота. Икенчедән, сөйләм һәр очракта

“мин” исеменнән, ягъни беренче заттан алып барыла. Әдәби энциклопедик сүзлектә жанрга мондый аңлатма бирелә: “Автобиография – үтеп баручы вакытны җиңеп, үзеңнең балачагыңа, яшьлегеңә кайту, иң әһәмиятле һәм истәлекле вакыйгаларны хәтердә яңарту – тормышта яңадан яшәгән кебек булу”[136].

Истәлекләр язу процессы үткәндәге манзараларны гадәти искә төшерүгә кайтып калмый, ул үткән белән бүгенгене бәйләп, вакыйгаларны тулыландырып, беркадәр яңа төсмерләр өстәп сурәтләүгә нигезләнә. Үткәндәге вакыйгаларны искә төшерү – үзенчәлекле процесс, хыял уены. Һәр эпизод, вакыйга хәтердә ничек бар, шулай саклана алмый, еш кына үзгәрешләргә дучар була. Язучыларның, үз балачакларын сурәтләгәндә, төрле характердагы вакыйгаларны бирүләрен күзәттек. Үткәндәге, аеруча сабый чактагы вакыйгалар хәтердә кисәкләп кенә, фрагмент рәвешендә генә яңарырга мөмкин, кайберләре бигрәк тә аерым сәбәпләр аркасында искә төшкәннәре катгый эзлеклелектә, үзара бәйләнештә тасвирланалар.

Үткәнне хәтердә яңарту барышында әдип төрле “әверелүләр” процессын кичерә: балачагын тасвирлаганда кечкенә малайга, яшьлеге турында сүз алып барганда егет булып “әверелә”. Нәтиҗәдә, ике планлы сурәт туа: бер якта – малай–герой, егет–герой, икенче якта өлкән герой тора. Шул рәвешле, төп геройга ике яклап бәя бирелә. Алдан кечкенә малай – үзенә, аннары өлкән “мин” үзенең балачагына бәя бирә.

Автобиографик әсәрдә вакыт һәм пространство сызыклары тыгыз бәйләнештә биреләләр. Язучы, үткәнне тасвирлаганда, вакыт һәм пространство чикләрен киңәйтә, чөнки, бүгенгене аңлау өчен, үткәнне бербөтен итеп күзаллау зарур. Ә.Еникидә бу фикер түбәндәгечә яңгырый: “Бу (балачак – Г.Г.) бик озынга сузылган, әмма үтеп киткәне сизелми дә калган гомернең дәвамын аңларга да ярдәм итәр дип ышанам”.(3) М.Бахтин автобиографик әсәрдәге вакытны биографик вакыт дигән төшенчә белән билгели, аның кабатланмас, үзгәрешсез булуын, чикләнгәнлеген аерым шәхес тормышына нисбәтле нигезли[137]. Кагыйдә буларак, биографик романда мизгел, көн, төн һ.б. кыска вакыт аралыгы символик мәгънәгә ия түгел, чөнки сүз тулы бер тормыш турында бара, шәхес язмышының зур бер чоры күз алдыннан үткәрелә. Әлбәттә, озын бер гомер эчендә булган вакыйга–хәлләр кайбер очракларда сәгать, көн–төн белән чикләнә, ләкин алар аерым тормышны сурәтләүгә йөз тоткан биографик романга хезмәт итәләр, тормыш чынлыгы белән баетылалар. Мәсәлән, И.Газидә малайның Гөлниса белән очрашу вакыйгасы,

[136] Литературный энциклопедический словарь. – С.12.
[137] Бахтин М. М. Роман воспитания и его значение в истории реализма. К исторической типологии романа / Эстетика словесного творчества. – С. 196.

Г.Бәшировта сабантуй, аулак өйләр, җирән кашканы югалту вакыйгасы, Р.Төхфәтуллинда малайларның очкыч очыру вакыйгасы, һәр язучыда диярлек гәүдәләнеш алган әниләренең үлемнәре вакыйгасы. Чынбарлыктагы күренеш рәвешендә биографик вакыт тарихи вакытның барышын, дәвамлылыгын билгели алмый, ләкин шул бер чорга нисбәтле тарихи нигездә барлыкка килә. Биографик тормыш чор, дәвергә нисбәттә генә карала. Чор исә аерым бер кешенең тормышы белән генә чикләнми, аның дәвамлылыгы буыннарга бәйле[138].

Буыннар хәрәкәте исә билгеле бер тарихи вакытка ишарә итсә дә, тарихи вакыт белән биографик вакыт тәңгәл түгел. Буыннар алмашынуы, аларның гомуми тарихи вакытка йогынтысы, шуның белән бәйле төрле үзгәреш, борылышлар Ә.Еники һәм И.Газидә калку күрсәтелә. Язучылар щул үзгәрешләргә бәя бирәләр, ике чорны (үткән һәм бүгенгене) очраштырып нәтиҗә ясыйлар, әсәрдә сурәтләнгән дөньяны өр–яңа тормыш материалы белән баеталар. И.Гази “сөяккә эләгеп торасы килмәгән ыштанлы” үз буынын машиналы, мотоциклы, унъеллыек белемле, югары уку йортлары тәмамлаган яңа кешеләр белән очраштыра. Монда биографик вакыт үз тормышына, “мин”енә мөнәсәбәттә бирелә, ләкин әле тарихи вакытны билгели алмый. Алда билгеләп үтелгәнчә, буыннар көрешү моменты әсәргә яңа эчтәлек бирә. Бичурага, җен–паригә ышанучы буынга бәя авторның үз “мин”енә бәя кебек аңлашыла. Вакытның үзгәреше, төрле кешеләре арасындагы аерма язучыны яшь буын турында уйланырга этәрә, нәтиҗә чыгарырга нигез бирә. Аның карашынча, үткәннең бүгенгегә охшамавы нәкъ менә тарихи барышка бәйле. Еш кына үз тормышының азмы–күпме җайлануын ул инкыйлаблар нәтиҗәсе дип бәяли. Әйтик, үзләреннән налог түләтми башлауларын революциядән соң авыз иткән беренче җимеш дип күрсәтә.

Автор әсәрдә объект һәм субъект вазифаларын үти. Шуңа күрә вакыт төшенчәсе ике яссылыкта чагылыш таба: бер якта әдипнең үткәнендә булган вакыйгалар, икенче якта аның бүгенгесе игътибарга алына. Язучы үзенең үткәне образын бүгенгесе яктылыгында, өлгергән шәхеснең тирәнтен фикерләренә таянып барлыкка китерә. Шул рәвешле, автобиографик әсәрдә шәхеснең фикер үсеше ике вакыт яссылыгында күзәтелә. Башкача әйткәндә, язучының максаты – шәхеснең рух үсеше, аң–фикер диалектикасын яктырту. Г.Бәширов, Ф.Хөсни, Ә.Еники, И.Гази һ.б. автобиографик әсәр авторлары күңел дөньясы белән саф акыл диалектикасын бәйләп сурәтлиләр.

[138] Бахтин М. М. Роман воспитания и его значение в истории реализма. К исторической типологии романа / Эстетика словесного творчества. – С. 197.

Шәхеснең формалашу һәм үсеш процессы тарихи фонда гәүдәләнеш ала. Язучылар тарихи фонны төп документаль фактларга хилафлык китермичә, чынбарлыктагы кеше образларына мөрәҗәгать итеп булдыралар. Шул ук вакытта әсәрдә сурәтләнгән шәхеснең формалашу, үсеш–үзгәрешен биографик роман нигезендә күзәтү мөмкин түгел. Биредә аның тормыш юлы сурәтләнә, язмышы күз алдыннан үткәрелә, ә герой үзе, чынлыкта, үзгәрешсез кала. Кагыйдә буларак, язучының игътибарын биографик шәхеснең кылган гамәлләре, мактауга лаек эшләре, кайбер очракта хата–ялгышлары җәлеп итә. Герой үсешенең бердәнбер мөмкин булган очрагы – аның тормышындагы кискен борылыш, “яңадан тууы”, тормышка карашының, уй–фикерләренең тамырдан үзгәрүе[139]. 60–70 нче еллар автобиографик повестенда герой үсешен тулы күзәтү мөмкин түгел. Г.Бәширов, И.Гази, Р.Төхфәтуллин, Ә.Еникидә – балалар, алар тормышындагы һәр вакыйга шәхеснең киләчәктә үз–үзен тотышына нигез булып тора. Г.Бәширов әсәрендә инкыйлаб вакыйгалары, Ш.Маннурда Бөек Ватан сугышы, Ф.Хөснидә Сталин репрессияләре белән бәйле тарихи вакыйгалар урын ала. С.Баттал үзе турында Ә.Фәйзи сүзләре белән: “Без бөек кешеләр түгел, ләкин бөек чор кешеләре”,–ди. Чыннан да, алар яшәгән чор – олы тарихи борылышлар, үзгәрешләр дәвере. Шул рәвешле, автобиографик әсәр шәхеснең тарихи аренада формалашу процессын күзәтүгә корыла. Бу – аның төп жанр үзенчәлеге.

Кагыйдә буларак, автобиографик әсәрнең башлам өлеше кереш ролен үти. Бу өлеш кыска күләмле булуы белән үзенчәлекле. Ф.Хөснинең “Минем тәрәзәләрем” әсәрен дусты белән әңгәмә ачып җибәрә. Каләмдәше аңа үз тормышы турында берәр әсәр язарга тәкъдим итә. Керешнең башлам өлешендә әлеге әңгәмә–монолог бирелә. Ә.Еники “Соңгы китап” әсәренә керештә “бала һәм үсмер чакларын күрәсе килү” теләген белдерә. И.Гази “Малайлыкта кунакта” повестеның башлам өлешендә үткәне белән күрешү – исәнләшү мизгелен сурәтли. Моны да үзенчәлекле әңгәмә–монолог дип күрсәтергә мөмкин. М.Әмир “Без бәләкәй чакларда”, “Үсә төшкәч”, “Казан” бүлекләреннән торган автобиографик повестена керештә болай ди: “Бу китапта мин күбрәк башымнан кичкәннәрне һәм өлешчә үз колагым белән якыннан ишетеп белгәннәрнең тарих китапларында яки рәсми биографияләрдә язылмый үтә торган детальләрен хикәя кылырга тырышам. Бу язмалар фәкать тормышта булган һәм күңелемдә билгеле бер эз калдырган фактик материалларга нигезләнгән... Тагын шуны әйтәсем килә: кичә турында

[139]Бахтин М.  Роман воспитания и его значение в истории реализма. К исторической типологии романа. – С. 196.

бүген язам. Автор буларак, кайчандыр башымнан кичкән вакыйга яки таныш шәхесләрне искә төшерү уңае белән туган уй–тойгыларымны, әйтәсе килгән фикерләремне изһар итүдә мотлак образлар теле булсын дип тормадым, ачыктан–ачык публицистика алымына мөрәҗәгать иттем. Стиль ягыннан мондый “иркен кылануны” әдәби прозада нинди жанр кабул итә ала соң? Минемчә, повесть... Шуңа ышанып, китабымның жанрын автобиографик повесть дип билгеләдем дә”[140].

Биредә язучы автобиографик жанрның берничә хасиятен ачыклый. Беренчедән, документаль нигезгә корылган булуын, икенчедән, тарихи шәхесне чор вакыйгалары белән кушып бирү омтылышын күрсәтә. Моннан тыш, язучы әсәрнең интонациясе, пафосы үзгәрүен шулай ук жанрның аерым үзлегенә бәйле дип аңлата. Шул рәвешле, автобиографик әсәр язуның төп мотивы, максаты – “үткәнне хәтердә яңарту”, “кичә белән” күрешергә, сөйләшергә теләү.

Ш.Маннур, Г.Бәширов, Р.Төхфәтуллин әсәрләренең автобиографик жанр өчен традицион булган башлам өлеше юк.

Автобиографик әсәр структурасы бердәм калыпларга сыешмый, катгый таләпләргә буйсынмый. Һәр язучы үзенең гомер китабын төрле мәгънәви өлешләргә тарката. Мондый әсәрләрнең күпчелеге аерым бүлекләрдән гыйбарәт, ягъни тартмалы композициягә корыла. Мисал өчен, Ф.Хөснинең “Минем тәрәзәләрем” әсәре “Сабый чак” бүлеге белән ачыла. Алдагы бүлекләр “Үсмер чак, сабак башлау, сабак ташлау еллары”, “Укырга керү”, “Университет” һәм башкача исемләнә. Бүлекләрнең исемнәре язучының тормышындагы төп вакыйгаларны атап күрсәтә. Кайбер бүлекләр, мисал өчен, “Каз өмәсендә”, “Тун трагедиясе”, “Әти белән икәү”, “Без Такташны тыңладык” әсәрдәге хәлләрне эзлекле күрсәтәләр. Ф.Хөсни әсәрендә вакыйгаллар хронологик тәртиптә тасвирланмыйлар. Мондый “тәртипсезлек” И.Гази, Р.Төхфәтуллин, Ш.Маннурда күзәтелә. Г.Бәширов, М.Әмир, Ә.Еники әсәрләрендә хронологиягә хилафлык китермиләр. Г.Бәширов, Ш.Маннур, Ә.Еники әсәрләре композицион яктан шулай ук кечкенә бүлекчәләрдән төзелә. Бүлекчәләрнең исемнәре төп вакыйгаларга ишарә рәвешендә куела. Мисал өчен, Ш.Маннурда “Ай югары, без түбән...” бүлеге гомер агышының тизлеге, дөньяның фанилеге турындагы фәлсәфи фикер үткәрүне күздә тота, әсәр исеме – шуңа ишарә. Г.Бәширов “Җирән кашка сагышы” бүлегендә малайның колынын югалту сагышы турында, “Скрипкә нәрсә дип җылый?” бүлегендә татар милләтенең чукындыру сәясәтенә бәйле хәсрәте хакында сүз алып бара. Ә.Еники әсәрен төп вакыйгалардан чыгып

---

[140] Әмир М. Без бәләкәй чакларда. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1979. – 3–4 б.

исемли. “Каргалы”, “Эткол”, һ.б. бүлекләр әдипнең яшәгән урыны һәм шундагы хәл–әхвәлләрне вакыйгаларны сурәтли. С.Баттал истәлекләрендә, алда билгеләп үтелгәнчә, бүлекләр, нигездә, язучының искә алган хатирәләрне бер мәгънәви үзәккә җыеп тасвирлауга корыла. Берничә бүлек язучының туган авылы белән бәйле вакыйгаларны сурәтли, аерым бүлекләр аның очучы булып хезмәт иткән чорын яктырталар.

Автобиографик әсәрдә эпиграф әһәмиятле сурәтләү элементы булып тора. Ә.Еникинең “Соңгы китап” әсәрендәге “Каргалы” бүлегенә Гетеның: “Язучыны аңлыйсың килсә, аның туып үскән җиренә бар” дигән сүзләре эпиграф ролен үти. Аның мәгънәсен язучы әсәр башында үзе үк аңлата: “Гади генә әйтелгән бик дөрес фикер булса кирәк бу... Чынлап та, әдипне яки шагыйрьне туган–үскән җиреннән аерып аңлау мөмкинме?!” (3) Димәк, әсәрдә сүз башлыча туган җир турында барачак, кеше яшәешендә, аның киләчәген, язмышын, тормыш кагыйдәләрен билгеләүдә әһәмиятле урын алып торуы кат–кат искәртеләчәк. Ә.Еники бүгенге шәхесне аңлауга юл аның үткәнен күзаллау аша гына салына, дип күрсәтә. Ш.Маннурның “Агымсуларга карап” әсәренә эпиграф повестьның салмак моңсу нотасын, эчке сагышын билгели:

“Узган саен гомер юлым һаман
Каерылып карыйм артыма:
Иң кадерле чаклар шунда калган
Һәм манылган бар да алтынга.
Кайгы да юк анда, хәсрәтләр дә,
Сагышлар да үзәк өзмәгән,
Күрелмәгән газап михнәтләр дә ...
Гел гизелгән зәңгәр эзләрдән.
Нигә шулар һаман сагындыра,
Ник күңелем шунда тартыла?
Гомернең шул газиз чагын гына
Бер күрәсем килеп,
Әйләнәм дә карыйм артыма”[141].

Бер яктан, автор шигырь юллары белән кеше тормышының тиз үтеп китүен, андагы һәрбер вакыйга, һәр күренешнең күңелдә матур эз калдыруын, үткәндәге сагыш–хәсрәтләрнең бүгенгедә һәм киләчәктә якты моң тудыруын билгеләп үтә. Икенче яктан, бу өлеш әсәрдә барачак вакыйгаларга керешеп китми дә кебек. “Агымсуларга карап” әсәрендә лирик мин хисләренең эчтәлеге – авыр балачактан туган хәсрәт, газап–михнәтләр белән бәйле сагыш. Әсәрнең моңсу нотасын язучының

чордашы К.Хамзин болай нигезли: “Шәйхинең сөйләшүендә дә, әсәрләрендә дә юморга караганда михнәт, авыр кичереш чалымнары күбрәк була иде, яшь чактагы үгилек тә, акчасызлык та, ана җылысыннан мәхрүмлек тә үз тамгасын салган булса кирәк”[142]. Димәк, автор эпиграф ярдәмендә төп эчтәлеккә өстәмә рәвештә яңа эчтәлек тудыра. Әйтергә кирәк, авторның өстәмә эчтәлек кертүе – аның табышы, осталык билгесе. Авыр үткәннәр никадәр олы газап–михнәтләр белән генә билгеләнмәсен, кеше өчен балачагыннан, яшьлегеннән дә матуррак, кадерлерәк, рәхәтрәк чор була алмый дигән нәтиҗә әсәрнең эпиграф өлешендә урын ала. Укучы әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар аша авторның авыр хатирәләрне дә матурлык дип бәяләвен аңлый. Эпиграф эчтәлегендә укучы тормышның гасабилы хасиятен ничек бар, шулай кабул итәргә дигән яңа эчтәлекне күрә. Нинди генә булса да, үз үткәнеңне ихтирам итәргә, сабыр булырга чакыру–өндәү – әсәрнең өстәмә эчтәлегеннән туган яңа фикер. Һичшиксез, эпиграф ярдәмендә укучы авторның үз шәхесенә бәя бирү мөмкинлеген ала.

И.Газинең “Малайлыкта кунакта” әсәрендә эпиграф – “Саламнан тәртә каерып, чикерткә җиккән чаклар” (299) – язучының балачагы образына метафора вазифасын үти. Балачак – олы тормышка аяк басу өчен хәзерлек дәвере. Эпиграф ярдәмендә әсәрдә сүзнең кайгысыз, вафасыз балачак турында барачагы искәртелә кебек. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. И.Гази эпиграф ярдәмендә өстәмә эчтәлек тудырырга тели. Бердән, салам образы аша автор балачакның газап–михнәтле хасиятен билгеләсә, икенчедән, чикерткә җигү вакыйгасы белән балачактагы уеннарның хыялларга бәйле рәвештә барлыкка килүен күрсәтә. Һәр хыял – тормышка ашарга мөмкин булган теләк ул. Аның чынбарлык белән туры килүе тормыш–язмыштагы борылышларга бәйле. Автор балачакта булган хәл–вакыйгаларның киләчәк тормышта җигелеп тартыр өчен нигез булып торуын эпиграфка салынган эчтәлектә искәртә. Шунда ук, чикерткә җигү дип, яшь чактагы бер хыялның да тормышка ашмавын, бары матур бер теләк булып үткәндә – малайлыкта калуын билгели.

Автобиографик әсәрне язганда, автор үз укучысын күз алдында тотып эшли (беренче бүлектә бу элементның Кол Гали әсәрендә урын алуына игътибар иткән идек). Еш кына бу хакта фикер әсәрнең эчтәлегендә яңгыраш ала. Димәк, автор укучы белән диалогның үзенчәлекле моделен төзи, үз фикерләрен аерым бер аудиториягә

[141] Маннур Ш. Агымсуларга карап. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1974. – 3 б. (Алда җәя эчендә бит саннары күрсәтелә барачак)
[142] Хамзин К. Шагыйрьне искә алу // Казан утлары. – 1982. – № 4.– 64 б.

нисбәтли. Ф.Хөснинең укучысы – гади халык, авторны аның күңел кичерешләре, уйлары, көнкүреше борчый. Ул үзенең күңелен тәрәзәләр белән чагыштырып сурәтли. Тәрәзә яктылыкны, чынбарлыкны, хакыйкатьне чагылдыручы саф чиста көзге, кешенең киң дөньяга мөнәсәбәтен билгеләргә, анда үз урынын табарга ярдәм итүче символик образ буларак аңлашыла: “... Һәм ул тәрәзәләр кояшка, халык күңеленә таба һәрвакыт ачык торсын. Калганы – барысы да табыла торган байлык” . (280)

Ә.Еникинең максаты – укучысына чын дөреслекне җиткерү, мөмкин булганча хаклыкны язу. Автор үзенең тормыш вакыйгаларын тәфсилләп бирүен шәхсән үзе өчен, “язучы тарихы өчен” әһәмияткә ия, дип күрсәтә. Язучының үзе белән очрашкач та, ул шул фикерне кабатлады: “Соңгы китап” – минем иң яраткан, иң кадерле әсәрем. Чөнки анда уйдырма юк, бар булганы – хакыйкать”. Моннан аңлашыла: автор истәлекләрне беренче чиратта үзе өчен, үз шәхесе турында укучыда фикер тудырыр өчен, ниһаять, тарих өчен иҗат итә. Бу хакта укучысын әсәрнең эчтәлегендә үк искәртә.

И.Гази “Малайлыкта кунакта” әсәрендә укучысын “яңа кешеләр” дип атый, аудитория белән ачыктан–ачык әңгәмә кора. Шул рәвешле, кайбер автобиографик әсәрдә автор, үз укучысына мөрәҗәгать итеп, аңа әйтергә теләгәнен, дөресрәге, аңарда күрергә теләгән сыйфатларны ачыктан–ачык белдерә.

Автобиографик әсәрнең теле, стиль үзенчәлекләре турыдан–туры хикәяләүче “мин” образына бәйле. Яшь “мин”нең тормыш–көнкүреше турында сүз барганда, язучы күп кенә тарихи вакыйгаларны башка персонажлардан сөйләтә. Малайлар гаилә хәлләрен эти–әниләре, дуслары, укытучылары сөйләвеннән ишетеп беләләр. Димәк, вакыйгаларга бәя бирү өчен, өлкәннәр фикеренә таяналар. Үсә төшкәч, яшь “мин” автор фикерләренә якын килә, аның бүгенге уй–хисләренә теләктәш була башлый. Яшь малайлар телендә “ник? нигә? ни өчен?” кебек сораулар шактый күп. Мисалга Г.Бәшировтан бер өзек китерик: “Шунда миңа Бикә түтинең нindидер зур хәсрәте бардыр шикелле тоела башлады. Нигә олы кешеләр аны яратмыйлар, нигә, ул килә башласа кашларын җыералар? Керәшен булганы өченме?.. Әллә без белмәгән бүтән нәрсә бармы?”. (216) Мондый күренеш И.Газидә аеруча еш күзәтелә: “ Әни кызык кеше:

– Агачларны сындырма, үләннәрне, чәчәкләрне өзмә, алар барысы да аллага зекер әйтеп, дөньяда яшәүләре өчен куанышып утыралар, үсә бирсеннәр, – ди...

Үләнне, чәчәкне өзәргә ярамау белән килешәм. Үлән матур, чәчәк матур. Ә менә таш астында ята торган чабата–чабата бакага ник тияргә ярамый? Һич аңламыйм!” (308–309)

Балачакның мең сораудан торган хасиятен өлкән язучылар әнә шундый үзенчәлекле монологларда сурәтләп бирәләр.

Һәр автобиографик әсәрдә образ композициясен оештыручы, туган җир сурәтен төгәлләштереп бирүче төшенчә образларның бирелеше кызыклы. Мисалга, И.Газинең автобиографик повестенда үткәндәге туган як белән бүгенге туган җир хәтер һәм кабер детальләре белән аерып куела. Үткәндәге Карамалыдагы җил тегермәннәре, кызыл ермаклар бүгенге Карамалыда бүтән манзара белән алышынганнар. Балачакны билгеләүче албасты, бичура, су анасы, чыпчык–каргаларның каберләре, бер яктан, малайчакның матурлыгы юкка чыгуы турында сөйләсә, икенче яктан, гомернең үтүе, бу хәрәкәтнең котылгысызлыгы турында әйтеп бирә. Әсәрнең композицион бөтенен тәшкил итүче тузанлы юл бетем өлешендә кичке дым төшеп, тузаны басылган юл дип кабатлана. Юл образы, сюжетка кереп, повестьның вакыт сызыгын ике төгәл өлешкә бүлә: әсәрнең башламында билгесезлек төсмере белән килә, ахыр өлештә кичке дым вакытында гомернең соңында – бу мәгънә юкка чыга. Мәгънәви эчтәлеге ягыннан бер үк көчкә ия булган кояш, ай, йолдызлар, чишмә образлары, киресенчә, ике вакыт сызыгын берләштереп торучы әдәби детальләр буларак аңлашыла. Автор әсәрнең хис сызыгына бәйле рәвештә кайбер фразеологизмнарны метафорик эпитет буларак файдалана. Мисал өчен, ул мәктәптә белем алуын, рус классикларын укуын алардан авыз иттем дип белдерә, моның белән аның кадерен дә, үзе өчен әһәмиятен дә ассызыклый. Әсәрдә кулланылган чагыштырулар лирик геройның үз күзәтүләренә нигезләнә һәм кабатлана. Мисалга, Гөлнисага дип бакчадан чия җыеп бирүен соңрак чия төсле кып–кызыл кояш баешы тасвирында файдалана. Димәк, чия малайга ниндидер якты хисләр турында искәртүче образ вазифасын үти.

Р.Төхфәтуллин “Җиләкле аланнар” повестенда үткән вакыт белән бәйле сагыш хисен балачакның матурлыгын бермә–бер көчәйтеп бирүче әдәби детальләр ярдәмендә импрессионистик әдәбият рухында аңлата. Әсәрдәге хронотоп алан образында туплана. Ул малайның туган җире символы рәвешендә бирелеп, җиләк исенең тәмлелеге балачакны юксыну хисен көчәйтүгә ярдәм итә. Төсләр гаммасы алышыну әсәрдә вакытка бәйле хисләр үзгәрүне күрсәтә (алсу кояш–балачактагы хыял, зәңгәрсу күк–балачакта гына саклана, кадерле була торган иркенлек, киңлек, сары төс–бүген тормышның ачы хакыйкатен төшенгән өлкән миннең хәсрәте).

Моннан тыш, ике “мин” сөйләмен үзара ялгар өчен яисә үткән белән хәзергене органик бәйләнештә күрсәтү максатында, төрле җөмлә–конструкцияләр файдаланыла. Ә.Еникидә “Хәзергә кадәр онытa алмыйм”, “Тагын бер нәрсә истә калган”, “Әбекайны мин яхшы ук хәтерлим”, “Бабакай белән бәйле бер хатирәм саклана” һ.б.; Ф.Хөснидә “тагын шунысы хәтердә саклана”, “Әле дә хәтеремдә” кебек җөмләләр еш очрый. И.Газинең сөйләме өлкән “мин” һәм яшь “мин”нәрнең сөйләмен чиратлаштырып бирүгә корылган.

Һәр әсәрдә күп нокталар әйтеп бетермәгән фикерне белдерәләр. И.Газидә мондый очраклар шактый: “Әти күмәч апкайта дигәннән, авылда чагымда миңа күмәч эләкмәде. Тик бер тапкыр... Күреп алдым, кыр юлыннан арбалы кеше килә, дугасындагы кыңгыравының чыңгыл–чыңгыл итүе миңа бик ачык ишетелә... Йөгереп бардым да басу капкасын ача башладым. Яман авыр капка”… (318) Язучы бертуктаусыз балачагын югалтудан туган хәсрәт хисе турында кабатлап тора. Моңа аның әсәрендәге интонациянең еш үзгәрүе дә басым ясый.

Ә.Еники һәр вакыйганы фәлсәфи фикер белән җөпләп бара, нәтиҗә ясый, автор һәр мәсьәләгә бүгенге күзлектән карашын белдерә: “Бу юлларны язганда, атакайга җитмеш биш яшь булган. Әйе, үткән шул инде, яшьлекләре генә түгел, заманнары, чорлары да күптән үтеп киткән... Һәм үтәчәк икән ул, кем генә булуыңа да карамастан!” (66). Язучылар теге яисә бу фикри нәтиҗәне, фәлсәфи яшәеш канунын гади тел белән – яшь “мин” теле белән әйтеп бирәләр. Бу очракта фикерләр тагын да көчле яңгыраш ала. Шул ук вакытта укучы һәрвакыт автор белән аралашуын тоеп–сиземләп тора. Моңа нигезләнеп, ул авторга үз мөнәсәбәтен булдыра, аңа бәя бирергә әзерләнә.

Автобиографик әсәр ярым әдәби, ярым документаль характерда булуы белән үзенчәлекле дип билгеләп үтелгән иде. Төрле язучының әсәрендә әдәбилек һәм документальлек дәрәҗәсе төрлечә. Аерым автобиографик әсәрләр информация, мәгълүмат бирү, кыскасы, фактографик төзелешкә корылсалар, башкалары мемуар характердагы материалны әдәби уйдырма, төрле композицион алымнарга мөрәҗәгать итеп тасвирлаулары белән үзенчәлекле. Бу җәһәттән, С.Баттал истәлекләре белән Г.Бәширов повесте шактый аерыла.

Г.Бәширов “Туган ягым– яшел бишек” повестенда тышкы әдәби детальләрне бик төгәл һәм уңышлы файдалана. Әсәрнең моңсу нотасын көчәйтеп бирүдә пейзаж аерым урын тота. Күктәге ай кызының моңсу карашы, яз килү белән кыр казларының моңсу каңгылдашуы әсәрне кабул итәргә әзерләү вазифасын үти: “Шулай да кыз хәзер бик моңсу күренде. Мин аны хәтта кызгана башладым. Теге вакытта, үги анасының

җәберлегенә түзә алмыйча, су алырга төшкән җиреннән айга менеп киткән китүен дә ... Күрәсең, хәзер ямансулыйдыр. Бәлки, аның әле кайтасы да килә торгандыр. Әнә аның җирдәге иптәш кызлары, аулак өйләрдә бер–берсенә җырлар әйтешеп, шыпырт сүзләр сөйләп, уеннар уйнап рәхәтләнгәннән соң, җылы өйләрдә, йомшак урыннарда ничек тәмле итеп йоклап яталар”.(21) Апасы Өммикамалның көчләп кияүгә бирелүе, шуңа бәйле хәсрәте малайның ай кызына кагылышлы уйлары белән тәңгәл бирелә. Кешенең табигать белән гармониясен автор яңа яз килү белән бәйле табигать күренешендә тирәнрәк ача: “Бөтенебез күккә текәлдек. Анда берни дә күренми иде әле. Менә тыңлый торгач, Яурышкан ягыннан моңсу гына, юаш кына каңгылдаган тавыш ишетелде… Әллә ни арада авылның олысы–кечесе капка төпләренә, баскыч алларына чыгып басты. Һәммәсе, кулларын маңгайларына куеп, күктәге матур булып тезелеп килгән өчпочмакка  карыйлар, кадерле кунакларны каршы алгандай, йөзләре шатлык белән балкый”. (44) Саф, йомшак бала күңеле табигатьнең һәр үзгәрешенә карата үтә дә сизгер, ул һәртөрле яңалыктан рәхәтлек таба: “Кыш буе шыгыр–шыгыр кар ерып, борыннарны, колакларны туңдырып иза чикәннән соң, яшел чирәм нинди тансык! Үзенә бертөрле салкынча хуш ис аңкытып яткан йоп–йомшак шул дымсу җир өстендә, әле генә борын төртеп чыга башлаган яшь чирәмдә бер–береңбелән әүмәкләшеп аунау үзе бер рәхәт иде”. (65)

Язучы әсәрдә халыкның күңел җәүһәрләрен бөртекләп туплый, кеше күңеле тудыра алган матурлыкны иң югары дәрәҗәгә күтәреп тасвирлый. Бу максатка пейзаж, портрет, лирик чигенешләр, гореф–гадәтләр белән бәйле вакыйгалар һ.б. хезмәт итә. Мисалга, апасының портреты малайның  хис–тойгылары белән үрелеп тасвирлана: “Менә хәзер апай, тамбур инәләрен шул карандаш эзләреннән йөртеп, дебеттән яшел, зәңгәр, шәмәхә төсле зур–зур чәчәкләр чигә. Апайның кыска гына, кечкенә генә коңгырт  бармаклары, бик килешле булып, тегеләй дә, болай уйнап кына тора, инәсе ситсыга бер батырган саен шарт итә, бармагындагы көмеш балдагы очкын чәчрәткәндәй җелт–җелт итә. Озын кара керфекләре астында күзләре бөтенләй йомылып беткән шикелле. Чебен эзләре тикле генә шул нечкә юлларны ничек күрә икән ул? Дебетнең күзәнәкләре ничек төшеп калмый да, ничек чәчәген бозып бетерми икән”? (16) Әнисе образын язучы аерым бер җылылык, яктылык белән сурәтли. Аның портреты әсәрдә кечкенә миннең хис дәрәҗәсе көчәюе рәвешендә кабатланып килә, һәр күзәтүендә  малай үзе яңа ягы белән ачыла: “Әнинең мичкә төшкән күләгәсен карап утыру китап тыңлауга караганда да кызыграк. Әни үзе мич стенасында әллә нинди озын муенлы сәер хайванга атланган бик дәү кеше булып күренә…Ул шәүләләр бер дә чын түгелдер,

әллә нинди күз буяудыр, йә әкияттәге кебек тылсымдыр, дип уйлый башлыйсың”. (19) Үз анасы белән Җиһан тәтәсен чагыштыруы – әнисенең хәсрәтенә кечкенә малай күзлегеннән автор бәясе: “Ул да Җиһан тәтәй шикелле үк зифа буйлы ( исеме дә Зифа бит!), ул да шундый ук озынча ак битле, төскә–биткә дә шундый ук матур кеше. Ул әле Җиһан тәтәйгә караганда да йомшак күңеллерәк, аннан да кече җанлырак, безнең барыбызны да өзелеп сөя, сеңелесеннән ныграк сөя”. (121)

Автобиографик әсәр өчен автор – герой – укучы мөнәсәбәтләре әһәмияткә ия дип билгеләп үтелде. Авторны әсәр герое белән тиңләштерү мөмкин түгел, ә укучы автор позициясен ала дигән нәтиҗә ясадык. Бу структура (автор – герой – укучы) һәр язучыда үзенчәлекле гәүдәләнеш ала. Г.Бәшировның лирик герое авторның балачактагы бала образын тудыра. Балачакның төп темасы – кешедә теге яисә бу вакыйгага мөнәсәбәттә хис–тойгылар тәрбияләү. Яшь Гумәрнең хисләре төрле төсмерләрдә тасвирлана дип күрсәттек. Шул рәвешле, укучы яшь авторны, ягъни Г.Бәшировның малай чагын күз алдына китерә.

Автобиографик әсәрләрендә Ә.Еники, И.Гази, Ф.Хөсни укучыга турыдан–туры мөрәҗәгать итәләр. Мондый төр диалог – автобиографик жанрның тагын бер үзенчәлеге. Ә.Еники укучыга “Хуш, абзыкаем” дип эндәшә. Ф.Хөснинең әсәрендә автобиографик повестеның журналда басылган вариантына укучы бәясе һәм аңа әдип җавабы кертелә. И.Гази повестьта укучы белән җанлы әңгәмә кора, дөресрәге монолог–әңгәмә алымын үзенчәлекле файдалана. Чагыштыру объекты итеп ул “мин” һәм”сез”, ягъни “мин” һәм хәзерге яшь буынны кертә. Мондый җанлы әңгәмәләр авторны укучыга якынайта, фикерен үтемлерәк җиткерергә ярдәм итә. Икенче яктан, автобиографик әсәр белән танышканнан соң, укучы, автор белән үзен чагыштырып, үз шәхесенә бәя бирү мөмкинлеген ала. Ф.Хөсни “Бер мәсьәлә тирәсендә” дигән мәкаләсендә шул фикерне үткәрә: “Биографик геройны гомумиләштерү нигезендә тудырылган геройдан аера торган, аның укучыга эмоциональ һәм мәгънәви йогынтысын кечерәйтә, икенчерәк планда калдыра торган бер як бар: конкрет шәхес турында булгач, укучы аңарда үзен күрергә – уңай яктан да, кайбер кимчелекләре чагылып китә икән – кимчелекләреннән дә сабак алырга теләми. Ул бик турыдан хөкем чыгара: “Ә бу бит фәлән кеше турында, монда минем ни катнашым бар? Бөтенесе өчен ул җавап бирә.” Биографик әдәбият, кагыйдә буларак, гади кешеләрнең үрелеп буе җитмәслек зур тарихи шәхесләр хакында язылганлыктан, укучының ул геройга гади кызыгудан узмавы, “ә алар шуның өчен дә тарихка кереп калганнар, кая миңа ул ирешкән югарылыкка ирешәм дип көчәнергә”, дип карау тыныч күңел белән читтә калуы да мөмкин. Ә сәнгатьнең чын

бурычы – берәүне дә читтә калдырмау. Биографик әсәр язарга керешкәндә, бу плюсларның һәм минусларның барысын да күз алдында тотарга кирәк”[143].

Әдәбият галимнәре “диалог әдәби жанр булудан бигрәк, публицистик, хәтта фәнни жанр”[144], дигән фикерне дөрес табалар. Димәк, әсәрдә автор–укучы диалогы еш кына публицистик яңгыраш ала. Автобиографик әсәргә диалогларны кертеп, автор үз героен укучыга бөтен барлыгында күрсәтергә омтылыш ясый. Шулай да, алда әйтеп үтелгәнчә, автобиографик әсәр авторны шәхес буларак тулысынча ачуны күздә тотмый. Бу җәһәттән караганда, Г.Бәшировның автопортреты күпмедер басынкы, автор үз героеның бөтен табигатен, күңел дөньясын тасвирлаудан читләшә кебек. Балачак образына мөрәҗәгать итеп, тормышының башка чорын иңләргә омтылмавы укучыда шундый фикер уятырга мөмкин. Ә.Еники, И.Гази, Ш.Маннур чагыштырмача тулы автопортрет иҗат итәләр. Алар шәхси сурәтләренең укучы хөкеменә тәкъдим итәргә мөмкин булган өлешен туплап бирәләр. Билгеләп үтелгәнчә, шәхес үзе яшәгән чор белән бергә тасвир ителә. Гете “Поэзия һәм хакыйкать” әсәренең художестволы максатын түбәндәгечә аңлата: “Думается, что основная задача автобиографии в том и состоит, чтобы изобразить человека в его соотношении с временем, показать в какой мере время было ему враждебно и в какой благоприятствовало, как под воздействием времени сложились его воззрения на мир и на людей и каким образом, будучи художником, поэтом, писателем, он сумел все это воссоздать для внешнего мира. Для этого требуется нечто невозможное, а именно: чтобы индивидуум знал себя и свой век, себя – поскольку он при всех обстоятельствах оставался все тем же, свой век – поскольку время увлекает за собою каждого, хочет он того или нет, определяя и образуя его так что человек, родись он на десять лет раньше или позже, будет совершенно иным в том, что касается его собственного развития и его воздействия на внешний мир”[145].

Һәр автобиография шәхеснең камилләшү көзгесе булып тора. Әсәрдә үз шәхесен өйрәнү, аның турында уйлану, эзләнүләр барышында автор үзе үк үсеш–үзгәреш кичерә. Билгеле, без бары тик олы язучылар, классик әсәрләр турында гына сүз алып барабыз.

Күренгәнчә, автобиографик әсәрләр шактый ирекле формада иҗат ителәләр. Шул нигездә әдәбият теориясендә алар арадаш жанр дип

---

[143] Хөсни Ф. Бер мәсьәлә тирәсендә. –179 б.
[144] Сцепление жанров / Жанровое разнообразие современной прозы Запада. – М.: Изд–во Наукова думка, 1998 – С.18.
[145] Гете Й.–В. Поэзия и правда / Собр.соч. в Х–ти томах. Т. Ш. – М., 1976. – С.493.

исемләнәләр. Аларда әдәби әсәр тудыру чаралары белән документальлек, фактография янәшә килә.

Татар әдәбиятында автобиографик әсәр моделен түбәндәгечә корып булыр иде:

– әсәрдә автор белән лирик герой тиңләшми, ләкин авторның киләчәккә омтылышы, әхлакый–эстетик кануннары лирик герой образы аша гәүдәләндерелә;

– киләчәккә омтылыш язучы үткәргән эстетик концепция ярдәмендә ачыклана;

– геройның рухи үсешенә әти–әнисе, дус–ишләре, беренче укытучылары, үрнәк шәхесләр, язучылар, сөйгән ярлары хәлиткеч йогынты ясыйлар. Еш кына лирик герой аларның иң матур сыйфатларын үзенә өлге буларак кабул итә. Шул сәбәпле әлеге образларга бәя лирик геройның үз–үзенә бәясе белән тиңләшә;

– яшьлекләре 20–30 нчы елларга туры килгән өлкән буынның үткәне, нигездә, матур, тәэсирле тасвирлана. Шул ук вакытта беркадәр үкенечле хатирәләр дә искә алына. Язучылардагы романтик дәртлелек, ихтыяр көче, иҗади куәт үзләре яшәгән чорның идеаллары белән көчәйтелә, бу сыйфатлар аларны гомер буе саклап һәм яклап килә;

– автор–герой бүгенге яшь буынга хәтер турында искәртә. Үткәнне хәтерләү – киләчәккә юл дигән хакыйкать һәр әсәрдә кабатлана. Шул ук вакытта яшь буынның вафасызлыгы, үз чорының кыйммәтләрен кадерли белмәве тәнкыйтьләнә;

– һәр әсәрдә чорга бәйле әхлакый кануннар яктыртыла. Бу исә укучыга авторны бәяләү, аның шәхесенә якын килү өчен күпер булып хезмәт итә.

Йомгаклап, түбәндәге фикерне белдереп үтү зарур: соңгы елларда мемуаристикага игътибарның көчәюе автор–герой мөнәсәбәтләре һәм башка теоретик мәсьәләләр белән кызыксынуны көчәйтте. Яңа фәлсәфи–эстетик концепцияләр нигезендә әдәбиятның мемуар–автобиографик катламы нәзари яктан тагын барлана, өйрәнелә килә.

## Әдәбият

*Текстлар*

Әмир М.М. Без бәләкәй чакларда. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1979.

Баттал С. Баштан үткәннәр / Сайланма әсәрләр. Проза. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1974.

Бәширов Г.Б. Туган ягым – яшел бишек / И язмыш, язмыш. – Казан: Тат.кит.нәшр.,1990.

Гази И. Малайлыкта кунакта / Әсәрләр. Өч томда. Т. I. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1987.

Гафури М. Әсәрләр. 4 томда. Т. IV. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1981.

Думави Н. Тәрҗемәи хәл урынында / Әдәби мирас. 1 китап. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1991.

Еники Ә.Н. Соңгы китап. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1987.

Еники А.Н. Страницы прошлого. – Казань: Тат.кн.издат., 1998.

Исхакый Г. Зиндан. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1991.

Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1983.

Маннур Ш. Агымсуларга карап. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1974.

Сәиф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1999.

Төхфәтуллин Р. Җиләкле аланнар / Сайланма әсәрләр. Ике томда.Т. П. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1983.

Тукай Г. Әсәрләр. Дүрт томда. Т. Ш. – Казан, 1976.

Хөсни Ф.Х. Минем тәрәзәләрем / Сайланма әсәрләр. Өч томда. Т. Ш. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1968

*Фәнни-теоретик әдәбият:*

*а) татар телендә*

*Ахунов Г.* Җир һәм күңел җылысы / Әдәби язмышлар. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1980.

*Ахунов Г.* Бүгенге татар романы // Казан утлары. – 1989. – № 5.

Әдәбият белеме сүзлеге. / Төзүче ред. Әхмәдуллин А.Г. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1990.

*Әшрәфҗанов Х.Ә.* Тарихка әдәби сәяхәт. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000.

*Бәширов Г.Б.* Бүген дә, иртәгә дә. – Казан: Тат.кит.нәшр, 1974.

*Бигиев З.* Мавәраэннәһердә сәяхәт / Зур гөнаһлар. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1991.

*Вәлиев М.* Каһарманнар кирәк. – Казан: Тат.кит.нәшр., 19

*Гайнетдинов М.* Мәгърифәтче әдип // Мирас. – 1995. – № 7.

*Галиуллин Т.Н.* Дәгъва. – Казан: Тат.кит.нәшр., – 1995.

*Ганиева Ф.Ә.* Тарихи романнарда вакыйгалар һәм характерлар бирелеше. – Казан: КДПИ, 1984.

*Гыйззәтуллин Н.* Әдәбият һәм тормыш / Кешенең күңел матурлыгы. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1988.

*Даутов Р.* Заһир Бигиев / З.Бигиев. Зур гөнаһлар. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1991.

*Даутов Р., Нуруллина Н.* Совет Татарстаны язучылары: Библиографик белешмә. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1986.

*Җәләлиева М.* Гомәр Бәширов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1959.

*Заһидуллина Д.* Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). – Казан: Татар.китап нәшр., 2000.

Метод, стиль, жанр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1976.

*Минһаҗева Л.* Ибраһим Салахов. – Казан: Матбугат йорты нәшрияты, 1999.

*Миңнегулов Х.Й.* Котб иҗаты. Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбияты курсыннан студентлар өчен уку ярдәмлеге. – Казан, 1976.

*Миңнуллин Ф.М.* Балта явызлар куланда (Әдәби тәнкыйть мәкаләләре). – Казан: Тат.кит.нәшр., 1994.

*Мөхәммәдиев Р.* Якутлар табыладыр вакыт белән. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1983.

*Мөхәммәтҗанов А.А.* Ш.Мәрҗәнинең “Вафийәтел–әслаф...”ы һәм Р.Фәхретдиновның “Асар”ы / Ш.Марджани: Наследие и современность. Материалы международной научной конференции. – Казань, 1998.

*Мусин Ф.М.* Чор белән аваздаш. – Казан: Тат.кит.нәшр, 1983.

*Мусин Ф.М.* Тормыш үзәненнән. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1987.

*Нигъмәтуллин Э.* Прозабыз турында уйланулар // Казан утлары. – 1978. – № 11.

*Нуруллин И.* Габдулла Тукай. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1979.

*Сәхәпов Ә.* Исхакый иҗаты. – Казан: Мирас, 1997.

*Сверигин Р.* Фатих Хөсни. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1968.

Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т. I–V. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1985–1989.

*Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000.

*Хәйри Х.* Язучы һәм тормыш. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1979.

*Хөсни Ф.* Ни әйтергә? Ничек әйтергә? – Казан: Тат.кит.нәшр., 1974.

*Хөсни Ф.* Бер мәсьәлә тирәсендә / Карурманга керәм. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1985.

*Яхин А.Г.* Әдәбият. 11 сыйныф өчен дәреслек–хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1996.

*Яхин А.Г.* 11 сыйныфта татар әдәбиятын укыту. – Казан: Мәгариф, 1996.

*Яхин А.Г.* Ул дәрья да, бу дәрья: Борынгы әдәбият. – Казан: Мәгариф, 1999.

*Рус телендә*

*Аксаков К.С., Аксаков И.С.* Литературная критика. – М., 1981.

*Аверинцев С.С.* Плутарх и античная биография: к вопросу о месте классика жанра в истории жанра. – М., 1973.

*Андреев Ю.* По законам искусства (О природе документальностей) // Вопросы литературы. – 1979. – № 2.

*Бабаев Э.Г.* Из истории русского романа XIX века. – М.: Изд–во гос.университета, 1984.

*Баишев Ф.Н.* Общественно–политичесикие и нравтсвенно–этические взгляды Ризы Фахретдинова. – Уфа, 1996.

*Бахтин М.М.* Вопросы литературы и эстетики. – М.: Худ.лит–ра, 1979.

*Бахтин М.М.* Эстетика словесного творчества. – М.: Искусство, 1986.

*Бахтин М.М.* Литературно–критические статьи. – М.: Худ.лит–ра, 1986.

*Белинский В.Г.* Полное собрание сочинений в ХШ томах. Т. П. – М.: АН СССР, 1954.

*Белявский И.Г., Пронштейн А.П.* Некоторые психологические аспекты отражения действительности в исторических источниках // История Северокавказского научного центра высшей школы. Серия общественных наук. – 1974. – № 1.

*Богданов А.* Мемуарная литература / Словарь литературоведческих терминов. – М., 1974.

*Борев Ю.Б.* Компьютерный словарь литературоведческих терминов. – М.,1996.

*Гараева Н.* Источник “Вафият ал–аслаф ва тахиат ал–ахлаф” Ш.Марджани / Марджани: ученый, мыслитель, посветитель. – Казань, 1986.

*Гаранин Л.Я.* Мемуарный жанр советской литературы. Историко–теоретический очерк. – Минск, 1986.

*Герцен А.И.* Полное собрание сочинений в 30–ти томах. – Т. Х. – М., 1954–1965.

*Гете Й.В.* Поэзия и правда / Собр.соч. в 10–ти томах. – Т. Ш. – М., 1976.

*Гинзбург Л.Я.* “Былое и думы” А.И.Герцена. – М.: Худ.лит–ра, 1957.

*Гинзбург Л.Я.* О психологической прозе. – Л.: Худ.лит–ра, 1976.

*Головенченко Ф.М.* Введение в литературоведение. – М., 1964.

*Голубцов В.С.* Мемуары как источник по истории современного общества. – М.: МГУ, 1970.

*Грабарь–Пассек М.Е.* Либаний / История греческой литературы. Т. Ш. – М., 1960.

*Деревина Л.И.* О термине “мемуары” и классификация мемуарных источников // Вопросы архивоведения. – 1963. – № 4.

*Елизаветина Г.Г.* Жанровые особенности автобиографического произведения (Герцен, Руссо, Гете) / Герцен – художник и публицист. – М., 1977.

*Елизаветина Г.Г.* Последняя грань в области романа // Вопросы литературы. – 1982. – № 10.

*Елизаветина Г.Г.* Становление жанров автобиографии и мемуаров / Русский и западноевропейский классицизм. Проза. – М., 1982.

*Елизаветина Г.Г.* “Былое и думы” А.И.Герцена. – М,1984.

*Жиркова М.А.* Исповеди в романе Ф.М.Достоевского “Братья Карамазовы”. Дисс. …канд. филол.наук. – Спб., 1997.

*Кабдрахманов Б.Д.* Художественные функции документальных источников в контексте мемуаров Герцена “Былое и думы”. Дисс. … канд.фил.наук. – Алма–Ата, 1985.

*Кадрин В.* Сегодня о вчерашнем. – М.: Воениздат., 1961.

*Корман Б.О.* Проблема автора в художественной литературе. – Устинов, 1985.

*Короленко В.Г.* История моего современника / Собр.соч.Т. V. – М., 1954.

*Костенчик Н.К.* Жанр и сюжет современной писательской художественной автобиографии / Жанр и композиция литературного произведения. Вып. П. – Калининград, 1976.

*Левкович Я.Л.* Автобиографическая проза и письма Пушкина. – Л., 1988.

*Лейдерман Л.Н.* Движение времени и законы жанра. – М., 1989.

*Лотман Ю.М.* Беседы о русской литературе. – СПб, 1994.

*Марахова Г.А.* О жанрах мемуарной литературы // Ученые записки Горьковского пединститута: Вып. 69. – Горький. – 1968.

*Марджани Ш.* Вафиийат ал–аслаф ва тахиийат ал–ахлаф. Т. IV., л. 75 б–76 а. (Рукопись в отделе рукописей и редких книг научной библиотеки КГУ)

*Миллер Г.А.* От поэзии к прозе. Риторическая проза Горгия и Исократа /Античная поэтика. Риторическая теория и практика. – М., 1991.

*Моруа А.* О биографии как о художественном произведении / Писатели Франции о литературе. – М.: Прогресс, 1978.

*Муравьев В.Б.* Кавалерист–девица Надежда Дурова / Дурова Н.А. Избранные сочинения кавалерист–девицы. – М., 1988.

*Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. – Казань: Фэн, 1997.

*Панаев И.И.* Литературные воспоминания. – М.–Л., 1950.

*Петрушина Н.Н.* У истоков автобиографических записок // Русская литература. – 1991. – № 3.

*Печерин В.С.* Замогильные записки / Русское общество 30–х годов XIX века: Люди и идеи. Мемуары современников. – М., 1989.

*Полякова С.* Греческая проза I–IV веков до н.э. / Поздняя греческая проза. – М., 1960.

*Попова Г.А.* Античная биография и Византийская агиография / Античность и Византия. – М., 1975.

*Поспелов Г.Н.* Типология литературных родов и жанров // Вестник МГУ. Серия IX. Филология. – 1978. – № 4.

*Рошаль Л.М.* К методике составления каталогов мемуаров и дневников // Труды МГИАИ. – Т. XVI. – М., 1961.

*Соболевский С.И.* Ранняя латинская проза / История римской литературы. Т. I. – М., 1959.

*Стенник Ю.В.* Система жанров в историко–литературном процессе / Историко–литературный процесс: проблемы и методы изучения. – Л., 1974.

*Сутаева З.Р.* Жанровые особенности автобиографической и мемуарной прозы (На материале творчества А.С.Пушкина, П.А.Вяземского, Н.Г.Чернышевского). Дисс. …канд.филол.наук. – М., 1998.

*Тарле Е.В.* Значение архивных документов для истории // Вопросы архивоведения. – 1961. – № 3.

*Хайруллин А.Н.* Ш.Марджани и Р.Фахрутдинов / Ш.Марджани: ученый, мыслитель, просветитель. – Казань, 1990.

*Хализев Е.В.* Теория литературы. – М.:Наука, 2000.

*Чайковская О.* “... И в прозе глас слышен соловьиный” // Вопросы литературы. – 1980. – № 10.

*Черноморский М.Н.* Мемуары как исторический источник. – М., 1959.

*Шайтанов Н.* “Непроявленный жанр” или литературные заметки о мемуарной форме // Вопросы литературы. – 1979. –№ 2.

*Шарипов Х.* Формирование таджикской литературной теоретической мысли в X–XI веках. Автореф.дисс. … канд.фил.наук. – Душанбе, 1970.

*Юнг К.Г.* О психологии бессознательного. – М., 1984.

*Юсупов А.* Мировоззрение Ш.Марджани и арабо–мусульманская философия / Ш.Марджани: Наследие и современность. Материалы международной научной конференции. – Казань, 1998.

*Юсупов М.Х.* “Вафият ал–аслаф ва тахиат ал–ахлаф” Шихаб–ад–дини–Марджани как источник по истории мусульманского Востока. – М., 1979.

*Янская И., Кардин В.* Объективное и субъективное в мемуарах / Пределы достоверности. – М., 1986.